ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№12 (371)
ДЕКАБРЬ 2022

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

«СӘЙЯР»: ЙОЛДЫЗ ЧИРЕ БЕЗГӘ ЙОКМАДЫ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Олеся Бондаревская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Илдар Кыямов, Зилә Мөбәракшина, Алмаз Хәмзин, Әхмәт Шакиров
Фотографлар: Александр Ефремов, Юлия Кузнецова, Алсу Шакирова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: «Сәйяр» вокаль-инструменталь ансамбле.
Фото язма авторыннан алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О–3628
Басарга кул куелды: 13.12.2022
Басмадан чыкты: 19.12.2022

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

ГАСЫР ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

«Татарстан» журналының дөньяда яшәвенә икенче гасыр китте – декабрь аенда 102 яшь тулды. Басмабызның үткәне бик бай, нинди генә чорлар кичермәгән ул! Абруйлы журналның тарихы дәвам итә: без аның битләренә иртәгә инде хәтергә әйләнәчәк бүгенге иң зур, кызыклы вакыйгаларны барлап, теркәп барабыз.

Мәсәлән, бу санныбызда Татарстан җирендә туган, үскән, ныгыган һәм төбәгебездә генә түгел, аннан читтә дә танылуга ирешкән кайбер вокаль-инструменталь ансамбльләребез тарихына күз салдык. Кичәге көйләр белән бүгенгене бәйләп карарга тырыштык. Кайчандыр татар дөньясын гөрләткән бик күп ансамбльләр арасында иң популярлары саналган «Сәйяр» һәм «Саз» төркемнәренең данлы үткәнен искә төшердек. Хөрмәтле укучылар, сез дә Яңа ел алдыннан, рәхәтләнеп, җыр-моң дөньясына чумыгыз әле. Татар шатлыкта да, борчуда да җырлаган.

...Яңа елдан кешелек гел могҗиза көтә. Хәзер ул бигрәк тә кирәк. Ышаныйк без шул могҗизага. Һәм өметне җуймыйк. Бик авыр заманнарда да кешене өмет яшәткән. Кыштан соң яз килә. Аннан соң тагын ямьле җәйләр... Тормышта барысы да әнә шулай чиратлаша.

Сезнең могҗизалар көтүче редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **963 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 102 ЯШЬ

\# ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

\# бары тик ТАТАРСТАНДА

ЯШЕЛ ЧЫРШЫ, БАСЫП ТОРЫ...

«Кызыл Армия йортының* колонналы залы уртасында төз биек чыршы тора. Аның җәенке ботакларын ялтыравыклы шарлар, муенсалар, куян һәм балыклар бизи, куе яшел ылыслар арасында төсле утлар җемелди…» – газетадагы гади генә текст безнең өчен бик мөһим булган вакыйганы саклап калган. Әлеге мәкалә Казанда совет чорында уздырылган беренче Чыршы бәйрәме хакында сөйли. Бу 1937 елның 1 гыйнвары алдыннан була. СССРда Яңа ел чыршылары озак вакыт буе тыелып тора. 1935 ел азагында Политбюро әгъзалыгына кандидат Павел Постышевның «Правда» газетасында хаты басылгач кына рөхсәт ителә. Мәкаләдә ул совет балалары өчен дә бәйрәм оештырырга тәкъдим итә. Янәсе, революциягә кадәр байлар бизәгән чыршыга эшче балалары тәрәзә аша карап кына соклана алган, хәзер исә бу алар өчен дә бәйрәм булачак. 1935 ел азагында Мәскәүдәге Үзәк мәдәният паркына Яңа ел чыршысы куела. Бер елдан соң исә балалар өчен беренче чыршыны Союзлар йортының Колонналы залында бизиләр. Казан, Куйбышев, Воронеж… – бу елны чыршылар инде бөтен ил буйлап куела.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

* Хәзер Казан Ратушасы.

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Муниципаль парклар
Кече һәм урта эшкуарлык кайда үсәргә тиеш

8. Резидентлар өчен оҗмах
«М-7» мәйданчыгы нәрсә белән җәлеп итә

14. Тәм-томнар дөньясы
Иң яхшы пешекче кем

22. Яхшы сугышчы – тук сугышчы
Мобилизацияләнгәннәрне нинди милли ризыклар белән сыйлыйлар

24. Милли аш-сулар
Татар акцентлы якут ризыгы

игелекле эшләр

34. «Сәйяр» ансамбле:
«Йолдыз» чире безгә йокмады

38. «Саз» ансамбле
Профессиональ дәрәҗәдәге һәвәскәр төркем

42. Татарстан рок-төркемнәре
Рок-н-ролл ни өчен һаман яшь

56. Ветераннарыбыз
Затлы нәсел дәвамчысы Ирек Уразаев

60. Төньякка сәяхәт
Поляр түгәрәк аръягында хәбәрчебез нәрсә эзләде

мәңгелек кыйммәтләр

68. Кырыс заман мөфтие
Сталин Габдрахман Рәсүлигә ни өчен рәхмәт белдергән

72. Тарихи шәхесләр
Хакимиятне тәнкыйтьләгән галим

76. Тәбәнәк Бохара мәчете урынында
Ал мәчетне кем төзеткән

78. Татар авыллары
Яңа Иштирәкнең яңа юлы

82. Афиша

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: Иван Шагин / russiainphoto.ru

Акыллы гамәлләр

25.11

Дмитрий ЧЕРНЫШЕНКО, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – Иннополиста Digital Innopolis Days 2022 форумында:

« – Иннополис Университеты базасындагы белем бирү үзәге мәгариф һәм индустриаль үзәк технологияләрен булдыру һәм өйрәтү максатында «бер тәрәзә» принцибы буенча эшли торган үзәккә әйләнәчәк. Эшли башлаган көненнән анда 34 меңнән артык укытучы белем туплады һәм таныклык алды инде. Хәзер импортны алыштыруга бәйле мәсьәләләрне чишү өчен үзәкне яңартабыз. Төрле тармакларны чит ил программаларыннан Россиянекенә өзеклекләрсез күчерү өчен, хезмәткәрләрне укыту иң беренче бурыч булып тора. Белем бирү программалары яңартылачак, компетенцияләрне бәяләү ысуллары һәм һөнәри үсеш матрицалары булдырылачак.

Игелекле эшләр

23.11

Сергей КОГОГИН, КАМАЗ генераль директоры, – Мәскәүнең «Москвич» автомобиль заводында җитештерү процессын тантаналы рәвештә башлап җибәргәндә:

« – Кама автозаводы кризис вакытында идарә итү буенча бай тәҗрибәгә ия, локальләштерү күләмен арттырып, автомобильләрне күпләп җыю тәҗрибәсе дә бар. Бу партнерыбыз булган «Москвич»ны яңадан эшләтеп җибәрүдә дә ярдәм итәчәк. Илебездә кемдер үз өстенә җаваплылык алып, елына 300–500 мең җиңел автомобиль чыгаруны җайга салырга тиеш бит инде!

Мәңгелек кыйммәтләр



25.11

Олег КОРОБЧЕНКО, Татарстан Республикасының Премьер-министры урынбасары – сәнәгать һәм сәүдә министры:

« – Хәзерге вазгыятьтә Татарстан Көнбатыштан тулысынча йөз чөерде һәм Көнчыгышка таба борылды, дип әйтү ярамас. Әгәр Европа элемтәләрне өзә икән, бу аның проблемасы. Ә без даими сәүдә партнерларыбыз белән бәйләгән һәр җепкә ябышачакбыз. Элемтәләр хәтта дус булмаган илләрдә дә калды, һәм без алар белән эшләү тәртибен җайлыйбыз.

Фото: tatar-inform

игелекле эшләр

акыллы гамәләр/

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Сәнәгать паркларының көче **нәрсәдә**

Татарстан җитештерүчеләренә **нинди** ярдәм күрсәтергә

Республикада **кайсы** ресторан иң яхшысы

Иң шәп пешекчеләрне **кайда** әзерлиләр

Мобилизацияләнгәннәрне **нәрсә** белән сыйлыйлар

Якутлар татарстанлыларны **нәрсә** белән шаккатырды

СӘНӘГАТЬ ПАРКЛАРЫ: РЕЗЕРВ ҺӘМ МӨМКИНЛЕКЛӘР

Яхшы эшли торган сәнәгать парклары тәҗрибәсен күпләп тарату – Татарстан Республикасы Президенты үзенең ТР Дәүләт Советына еллык Юлламасында республика Икътисад министрлыгы, муниципаль район башлыклары, сәнәгать паркларының идарәче компанияләре алдына әнә шундый бурыч куйды. Максат – сәнәгать паркларын сыйфатлы үстерү, аларның мөмкинлекләреннән тулырак файдалану. ТР Икътисад министрлыгы Президент күрсәтмәсен ни рәвешле үтәргә ниятли? «Татарстан» журналы әлеге сорау белән ТР икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтовка мөрәҗәгать итте. Укучыларыбызга министрлыктан алынган җавапларны тәкъдим итәбез.

– Билгеле булганча, ТР Президенты Дәүләт Советына Юлламасында муниципаль сәнәгать парклары – яңа эш урыннары булдыру һәм районнарда кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен төп резерв, дип билгеләде. Әлеге паркларның көче, потенциалы нинди?

– Бүгенге икътисадый вазгыять эшкуарлык климатын яхшыртуга, инвестицион җәлеп итүчәнлекне арттыруга һәм икътисадый үсешне тәэмин итүгә юнәлдерелгән даими нәтиҗәле дәүләт ярдәме чаралары күрүне таләп итә. Бу уңайдан кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мөһим үсеш аспектларының берсе булып тора.

Инвестицияле климатны яхшырту өчен иң реаль юл – махсус бүлеп бирелгән территорияләрдә яңа производстволар оештыру һәм үстерү өчен мөмкин кадәр уңайлырак шартлар тудыру. Шуңа күрә сәнәгать паркларын булдыру бу проблеманы хәл итүнең нәтиҗәле ысулы булып тора.

Сәнәгать паркларының нәтиҗәлелеген, ким дигәндә, түбәндәге күрсәткечләр нигезендә бәялибез. Бу резидентлар саны да, җитештерелгән продукция күләме дә, яңа ачылган эш урыннары саны да, паркның тулу дәрәҗәсе дә, салым түләүләре дә. Бүгенге көндә резидент предприятиеләр саны 1500 дән артык.

2022 елның 9 аенда бу сан – уртача 10,260 берәмлеккә (+24,4%), ә эшләүчеләрнең саны, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 32% ка артты. Бу вакыт эчендә предприятиеләрдә товар әйләнеше 2021 елның шул ук чорына карата 3,9% ка артты һәм 263,3 млрд сумны тәшкил итте. Резидентлар җитештерә торган продукция күләме республика сәнәгать җитештерүенең якынча 10%н тәшкил итә.

– Сәнәгать паркын ачу һәрвакыт шактый чыгымнар (мәйданчык, инфраструктура, салым ташламалары...) таләп итә. Чыгымнар акланачак дип көтеп буламы? Һәм бу бөтен җирдә дә мөмкинме, чөнки территорияләрнең потенциалы төрле бит?

– Сәнәгать паркының уңышлы эшләве нәтиҗәле идарәче компаниянең, резидентларның, яңа производство-

Фото «М-7» индустриаль паркыннан алынды.

лар урнаштыру өчен кирәкле инженер инфраструктурасының булу-булмавына, шулай ук инвесторларны җәлеп итү юнәлешендә район башлыкларының актив позициясенә бәйле.

Инвесторларны үсеш алган инфраструктуралы зур шәһәрләрдәге, әйтик, Казан һәм Чаллыдагы сәнәгать парклары күбрәк кызыктыруы аңлашыла, шуңа күрә муниципаль сәнәгать паркларындагы вазгыятьне яхшырту буенча чаралар да эшләнгән.

Сәнәгать паркларының нәтиҗәлелеген күтәрү, эш урыннары санын арттыру максатында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов тарафыннан территорияләрне комплекслы үстерү максатында Авыл җирлегендә сәнәгать паркларының нәтиҗәлелеген арттыру концепциясе килешенде. Концепция кысаларында аккредитацияләнгән сәнәгать парклары резидентлары һәм идарәче компанияләренә төрле өстенлекләрдән файдаланырга мөмкинлек бирүче берничә закон кабул ителде:

– салымның гадиләштерелгән системасы буенча салым күләмен кимету (керемгә салымны – 1%ка, чыгымнар алынган керемгә – 5%);

– транспорт салымын түләү буенча салым ташламасын алу (0%);

– оешмалар мөлкәтенә салым түләү буенча салым ташламасын алу (0%).

Резидентлар саны аз булган аккредитацияләнгән сәнәгать паркы территориясендә эшчәнлек алып баручы һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килешү төзегән резидентлар һәм идарәче компанияләр салым ташламаларыннан 10 елга кадәр файдалана алачак. Республика икътисады өчен бу яңа эш урыннары ачылу һәм шәхси инвестицияләр керү дигән сүз.

Дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру дәвам итә: ташламалы микрозаймнар, электр энергиясенә чыгымның бер өлешен субсидияләү, ТР Гарантия фонды ярдәме, Эшкуарлыкка ярдәм фонды программасы (күргәзмәләрдә катнашу, маркетплейсларда продукция урнаштыру, сертификатлаштыру һ.б.лар), инженер һәм юл инфраструктурасы төзелешен финанслау.

Кабул ителгән законнар, бу категория сәнәгать парклары өчен дәүләт ярдәме чаралары, алар белән чагыштырганда, зур шәһәрләрдәге сәнәгать паркларының көндәшлекле өстенлеген тигезләргә һәм паркларның тулылык дәрәҗәсен без күздә тоткан 70%ка җиткерергә мөмкинлек бирә, бу исә авылда эш урыннарын арттырырга ярдәм итәчәк.

– Тагын бер кат Юллама текстына күз салыйк. Рөстәм Миңнеханов, нәтиҗәле сәнәгать парклары тәҗрибәсен таратудан тыш, «аларның үсешен тоткарлаучы факторларны кимету эшен дәвам итәргә» кирәклеген дә әйтте. Сүз нәрсәләр турында бара?

– Нәтиҗәле эшләүче идарәче компанияләр муниципаль сәнәгать парклары белән тиешле эш алып бара инде. Мондый сәнәгать паркларында төп проблемалы мәсьәләләргә аудит үткәрелә: кирәкле инженерлык инфраструктурасының булу-булмавы, электр егәрлекләре һәм җитештерү биналарының җитүҗитмәве, җиһазлар, чимал белән тәэмин итүдә, шулай ук продукция сату һәм яңа резидентлар җәлеп итүдә проблемалар ачыклана.

Табылган проблемалар һәм тәҗрибәле идарәче компанияләр тәкъдим иткән карарлар нәтиҗәдә муниципаль сәнәгать парклары үсеше өчен уңайлы шартлар булдыруны тәэмин итәргә тиеш.

– Бүген нинди муниципаль сәнәгать паркларын үрнәк дип атап була?

– Тәҗрибә шуны күрсәтә: сәнәгать паркының идарәче компаниясе муниципаль район җитәкчелеге белән берлектә сәнәгать паркын үстерүнең төгәл концепциясен тизрәк кабул иткән һәм аны гамәлгә ашыруга җитди керешкән урыннарда күркәм нәтиҗәләргә ирешелә. Бу очракта сәнәгать паркларының тулылыгы да, резидентлар тарафыннан продукция җитештерүне оештыру да тәэмин ителә. «Теләче», «Яшел Үзән», «М-7» (Яшел Үзән районы) «Үсеш» (Яр Чаллы), «Саба» (Саба районы), «Алексеевское» һәм башка сәнәгать паркларын уңышлы эшчәнлекнең яхшы үрнәкләре дип атап була.

– Муниципаль сәнәгать парклары ярдәмендә гамәлгә ашырылган уңышлы бизнес-проектларны атап китсәгез иде. Алар безгә нәрсә бирде?

– Иң беренче чиратта, бу – яңа эш урыннары. Муниципаль сәнәгать паркларын үстерү шул исәптән хезмәт миграциясе мәсьәләләрен дә хәл итә, чөнки эш урыннары «йорт янәшәсендә» ачыла. Сәнәгать парклары резидентлары тарафыннан кабельүткәргеч продукциясе, автотранспорт кузовлары, шинүткәргечләр, йорт җиһазлары җитештерү, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү һ.б.лар кебек уңышлы проектлар тормышка ашырыла.

ТАТАРСТАННЫҢ СӘНӘГАТЬ ПАРКЛАРЫ –

«ХИМГРАД» ТЕХНОПОЛИСЫ

Резидентларга аренда һәм/яки сатып алу хокукында мәйданчыклар һәм җир кишәрлекләре бирелә. Комплексны инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин итәлү җитештерү эшен тиз арада башлап җибәрергә мөмкинлек бирә. Технополис белән профессиональ компания идарә итә, эш «бер тәрәзә» принцибы нигезендә оештырылган. Мәйданчык резидентлары – кече тоннажлы химия, полимерлар эшкәртү, нанотехнологияләр, ресурсларны саклау һәм энергия куллану нәтиҗәлелеген арттыру, медицина технологияләре өлкәсендә эшли торган кече һәм урта бизнес компанияләре.
Индустриаль парк М-7 «Волга» федераль автомобиль трассасы ягыннан Казанга керү юлында урнашкан.

131 га – гомуми мәйданы

500000 кв. метрдан артык – бина һәм корылмаларның проектта каралган мәйданы

«САБА» ИНДУСТРИАЛЬ ПАРКЫ

Муниципаль парк санала, Саба муниципаль районы инициативасы буенча оештырылган, җир кишәрлекләре – муниципалитет милкендә.
Байлар Сабасы бистәсенең Завод урамында урнашкан.

60,7 га – гомуми мәйданы

30 дан артык – җитештерү мәйданчыгын урнаштырырга мөмкин

«ҮСЕШ» СӘНӘГАТЬ ПАРКЫ

Чаллы шәһәренең «Үсеш» сәнәгать паркы территориаль яктан аерылып торган комплекстан гыйбарәт.
Ул муниципаль милектәге кишәрлектә урнашкан. Бирелә эшкуарлык өчен уңай шартлар тудырылган. Паркның максаты – Яр Чаллы шәһәре, Татарстан Республикасы территориясен, икътисадның эшкәртү тармакларын үстерү, яңа төр продукция җитештерү, прогрессив технологияләрне һәм производство ысулларын гамәлгә кертү.

«ЯШЕЛ ҮЗӘН» ИНДУСТРИАЛЬ ПАРКЫ

«Яшел Үзән» индустриаль паркы – **Казан (Мәскәү районы) һәм Татарстанның Яшел Үзән районы чигендә, М-7 «Волга» федераль трассасыннан 150 метр ераклыкта**, логистика күзлегеннән һәм Казан агломерациясенең югары квалификацияле кадрлар потенциалын файдалану ягыннан бик уңайлы урында урнашкан перспективалы инвестиция мәйданчыкларының берсе. Участокның гомуми мәйданы 104 гектарны тәшкил итә, парк территориясе Яшел Үзән шәһәренең муниципаль милке булып тора, һәм ул Идарәче компаниягә арендага бирелгән. Мәйданчык тулысынча энергия чыганаклары белән тәэмин ителгән, челтәрләргә тоташу нокталары җир кишәрлеге чикләренә кадәр китерелгән. Инфраструктура челтәрләре «Моношәһәрләрне үстерү фонды» Коммерциячел булмаган оешмасы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең финанс ярдәме белән сузылды.

104 га – гомуми мәйданы

20 – резидент компания

8844 – эш урыны

Фото: president.tatarstan.ru

ЭШКУАРЛАР ӨЧЕН БЕР МӨМКИНЛЕК

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ, ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ:
«Татарстан җитештерүчеләренә, шул исәптән муниципаль сәнәгать парклары мөмкинлекләреннән дә файдаланып ярдәм күрсәтү – безнең бурычыбыз. Бу – районнарда яңа эш урыннары булдыру, урта һәм кече эшкуарлыкны үстерү өчен төп мөмкинлек. Аларны сыйфатлы итеп үстерү бүген зур әһәмият казана».

«МАСТЕР» КАМА ИНДУСТРИАЛЬ ПАРКЫ

Яр Чаллыда барлык кирәкле инфраструктурасы булган җитештерү һәм офис биналарын арендага бирә. Әлеге сәнәгать паркы беренче чиратта икътисадның реаль секторында эш алып бара торган предприятиеләрне туплауны күздә тота. Аренда бәясенең түбәнлегенә карамастан, парк мәйданчыкларының югары сыйфатта әзерлеге һәм яхшы үсеш алган инфраструктурасы белән аерылып тора.
Паркның өстенлекләрен инде 260 тан артык резидент-предприятие югары бәяләде, алар арасында дөньякүләм билгеле брендлар да бар. Дәүләт органнары һәм «КАМАЗ» автоконцерны ярдәме индустриаль парк резидентларына үз мөмкинлекләренә һәм җитештерү процессларын һәм коммерция эшчәнлеген тормышка ашыруда тотрыклылыкка тагын да зуррак ышаныч өсти.

1500000 кв. метрдан артык – «Мастер» КИП» АҖ милкендәге һәм аңа караган мәйдандагы җир

12000 нән артык – эш урыны

«ТЕЛӘЧЕ» СӘНӘГАТЬ ПАРКЫ

Республиканың Казан – Теләче – Байлар Сабасы – Кукмара – Ижевск, Казан – Теләче – Мамадыш – Яр Чаллы – Уфа кебек мөһим транспорт магистральләре чатында урнашкан, федераль трассаларга чыгу юлы көйләнгән. Кишәрлекләр резидентларга тулысынча әзер инженерлык инфраструктурасы белән тәкъдим ителә. Бу – авыл районында урнашкан беренче паркларның берсе, ул билгеле бер тармакка йөз тоту принцибына түгел, икътисадның төрле тармаклары өчен җитештереләчәк продукция чималын сайлау принцибына нигезләнә. «Теләче» сәнәгать паркы эшчәнлегенең төп юнәлеше буларак полимер материаллардан продукция җитештерү сайлап алынган.

«М-7» ИНДУСТРИАЛЬ ПАРКЫ

Казан (Мәскәү районы) һәм Татарстанның Яшел Үзән районы чигендә, М-7 «Волга» федераль трассасыннан 300 метр ераклыкта, «Казан Оргсинтез» ГАҖ янәшәсендә урнашкан заманча сәнәгать мәйданчыгы. Комплекслы инженерлык инфраструктурасы булу җитештерү эшен тиз арада башларга юл ача. Мәйданчык белән идарә итү эшен профессиональ Идарәче компания алып бара. Ул паркның өзеклекләрсез эшләвен тәэмин итә һәм резидентларның бизнес-проектына кулдан килгәнчә ярдәм күрсәтергә әзер тора. Паркның эш тәҗрибәсе Россиянең башка төбәкләрендә (Новосибирск өлкәсе, Төмән өлкәсе, Коми Республикасы) сәнәгать мәйданчыклары булдыруда актив кулланыла.

39,5 га – гомуми мәйданы

«АЛЕКСЕЕВСКОЕ» СӘНӘГАТЬ ПАРКЫ

Яңа җитештерү объектларын урнаштыру өчен махсус әзерләнгән территориядән гыйбарәт. Әзер инфраструктура һәм транспорт белән йөрү өчен уңайлы булуы да бизнесны уңышлы алып барырга ярдәм итәчәк. **Татарстанның Алексеевск районында урнашкан,** сәнәгать өчен тәгаенләнгән җирләрне били.

16 га – гомуми мәйданы

М-7: РЕЗИДЕНТЛАР ӨЧЕН ОҖМАХ, БИЗНЕС ӨЧЕН ҖИҢЕЛ СТАРТ

Татарстанның эре сәнәгать мәйданчыкларының берсе булган «М-7» беренче шәхси индустриаль паркы инде дистә елдан артык республика файдасына уңышлы эшләп килә. Бу вакыт эчендә ул кирәклелеген хаклы рәвештә раслап, төбәкнең социаль-икътисадый үсешен тәэмин итә торган җитештерү компанияләре белән хәзер 100%ка тулып эшли.

УҢЫШ ТАРИХЫ

Полимерлар эшкәртүгә йөз тоткан индустриаль парк булдыру идеясе 2008 елда туа. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның «Казаноргсинтез» ГАҖ акционерларының гомуми җыелышында ясаган чыгышы моңа этәргеч була. Әлеге чыгышта республика территориясендә төбәктә җитештерелгән полимерларны эшкәртү күләмен 30%ка кадәр җиткерү бурычы куела.

Ул чакта «ТАИФ» ААҖ генераль директорының милек һәм инвестицияләр белән корпоратив идарә итү буенча урынбасары булган Руслан Шиһабетдинов полимер эшкәртүчеләрне берләштерә һәм мондый производстволарны оештыру өчен үзенә күрә «теплица» ролен башкара ала торган махсус индустриаль мәйданчык булдыру идеясен әйтә.

Проект идарәче партнер, парк идарәсе рәисе Руслан Хәлилов җитәкчелегендә җентекләп эшләнә һәм Турыдан-туры инвестицияләр фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әнә шулай итеп 2011 елда Татарстанда беренче «М-7» шәхси индустриаль паркы барлыкка килә. Ул Россиянең иң эре нефть химиясе предприятиеләренең берсе булган «Казаноргсинтез» заводына якын урында төзелә. Башта полимерлар эшкәртүне генә күздә тоткан «М-7» алга таба мультипрофильле паркка әйләнә.

Аны булдыруда һәм үстерүдә Татарстанның Икътисад министрлыгы, Инвестицияле үсеш агентлыгы, ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстанның Министрлар Кабинеты зур ярдәм күрсәтә. Әлбәттә, биредә республика башлыгы Рөстәм Миңнехановның шәхсән булышлыгы да зур роль уйный.

«Волжанин» ҖЧҖ һәм «Мультипласт» ҖЧҖ паркның беренче резидентлары була, алар бүген дә бу мәйданчыкта актив эшләп килә. Параллель рәвештә паркның инженерлык инфраструктурасын үстерү юнәлешендә дә зур эш алып барыла: парк тирә-яктан коймага тотыла, паркның эчке юллары, электр челтәрләре, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү, газ һәм телекоммуникация челтәрләре төзелә. Яңа резидентлар да барлыкка килә. Беренче мәлдә эшкуарлар өчен мондый парк ниндидер яңа нәрсә була, алар проектка ниндидер шик-шөбһә белән генә керә. Ләкин парк җитәкчелеге алар белән мөнәсәбәтләрне барлык шикләр эреп югалырлык итеп кора. Биредә эш тәртибе ачык һәм үтә күренмәле, бизнесны башлап һәм корып җибәрүдә генә түгел, кооперация мәсьәләләрендә дә ярдәм күрсәтелә, бу исә мондый сәнәгый мәйданчыклар өчен әһәмиятле үзенчәлек булып тора.

39,5 гектарлы парк хәзер 54 кече һәм урта бизнес компаниясе өчен төп йортка әйләнгән, 11 ел эчендә ул 700 дән артык эш урыны булдырган. Проект шулкадәр уңышлы булды ки, бүгенге көндә «М-7» резидентлар белән тәмам тулып эшли, ә гаризалар килә тора.

БАРЛЫК ХУҖАЛЫК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕН ҮЗ ӨСТЕБЕЗГӘ АЛАБЫЗ!

Парк территориясендә җитештерү эшенең төрле юнәлешләре уңышлы үсеш алган: металл эшкәртү һәм машина төзелеше, агач эшкәртү һәм төзелеш материаллары җитештерү, әмма беренче чиратта – полимерлар эшкәртү (барлык эшчәнлек төрләренең гомуми өлешеннән 40% тәшкил итә). Паркта төрле юнәлештәге эшләрнең бер урында тупланган булуы хисабына резидентлар арасында кооперациягә ирешелә.

Җитештерү предприятиеләрен тиз урнаштыру өчен кирәкле шартлар, яхшы үсеш алган транспорт инфраструктурасы, чимал базасына якынлык, резидентлар белән сизгер һәм оператив рухта үзара мөнәсәбәт кору «М-7» паркының көндәшлектә өстенлекләре булып тора.

Фото «М-7» индустриаль паркыннан алынды.

РЕКЛАМА

«М-7» – 17 елның октябреннән Индустриаль парклар ассоциациясе әгъзасы.

Татарстан – индустриаль һәм сәнәгать мәйданчыклары саны буенча Россиядә алдынгы төбәк. Республикада аларның саны йөздән артык.

Паркның икенче өлеше 2023 елның мартында эшли башлар дип көтелә.

– Индустриаль парклар турында сүз барганда, беренче чиратта кирәкле мәйдан, киловаттлар, газ һәм су күләме турында искә алына, – дип билгеләп үтә «М-7» индустриаль паркы директоры Валерий Бригаднов. – Болар, әлбәттә, продукция җитештергәндә кирәк һәм әлеге параметрларга күп кенә сәнәгать территорияләре туры килә. Без, индустриаль парклар, гадәти җитештерү базаларыннан нәрсә белән аерылып торабыз соң? Үз предприятиеләрен безнең территориядә урнаштыру турында уйланган кешеләрдән мондый сорауны еш ишетәбез.

Бу сорауга җавап «М-7» паркының миссиясендә үк әйтелә, ул исә хуҗалык мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле мәшәкатьләрдән арындырып, предприятиеләр үсеше өчен шартлар тудыруны күздә тота. Идарәче компания төзелешкә рөхсәт алудан алып, коммуникацияләр тоташтыруга, аларга хезмәт күрсәтүгә, предприятие территориясен саклау һәм җыештыруга кадәр барлык мәсьәләләрне дә хәл итү белән үзе шөгыльләнә.

НОН-СТОП РЕЖИМЫНДА

Идарәче компаниянең компетенцияләре һәм «М-7» командасының югары һөнәри осталыгы паркның өзеклекләрсез эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Сүз уңаеннан, шәхси индустриаль паркларның өстенлеге шунда ки, алар, дәүләтнеке саналган күпчелектән аермалы буларак, үз резидентларының ихтыяҗларына карата сизгеррәк эш йөртә һәм аларның таләпләрен оператив рәвештә канәгатьләндерә ала.

«М-7» паркының идарәче компаниясе территориягә хезмәт күрсәтүгә һәм бизнес ачу өчен барлык шартларны булдыруга бәйле төп мәсьәләләрне үз өстенә алган. Юлларга асфальт салу, коммуникацияләр сузу һәм җир кишәрлекләрен бүлү – идарәче компаниянең вазыйфалары моның белән генә чикләнми, аның төп бурычы резидентларга эшне мөмкин кадәр кулайлаштырудан гыйбарәт – резидентлар чүп чыгару яки юлларны чистарту кебек мәсьәләләр турында баш катырырлык булмасын.

Республиканың күпчелек сәнәгать мәйданчыклары белән чагыштырганда, әлеге индустриаль паркның иң отышлы җирдә урнашуы да әһәмиятле роль уйный. Аның «М-7» «Волга» трассасына якынлыгы авыр йөк автомобильләренең парк территориясенә бик җиңел килеп-китеп йөрүен һәм парктан бик тиз чыгып китү мөмкинлеген тәэмин итә. Новониколаевск бистәсенә дә, Казанга да якын булу кадрлар мәсьәләсен тиз хәл итәргә булыша.

Проектка идеяләр белән җан өргән Руслан Шиһабетдиновның ярдәме һәм уртак тырышлык бәрабәренә парк командасы югары профессиональлеккә ирешә, эшчәнлек юнәлешләрен киңәйтә, индустриальләштерү өлкәсендә яңа проектлар булдырып, алга таба үсү мөмкинлеге ала. Хәзер «М-7» паркын, индустриаль парклар арасында иң уңышлы проектларның берсе буларак, республикадан читтә дә яхшы беләләр.

БАРЫ ТИК АЛГА ГЫНА!

Бүген инде «М-7» бренды белән эш итә торган яңа парклар да бар.

– **«М-7 2.0»**. Әлеге мәйданчык «М-7» паркы янында урнашкан. Бу исә инженерлык системаларын тиз эшләтеп җибәрергә һәм яңа предприятиеләр төзергә мөмкинлек ача.

Паркның мәйданы – 17,7 га, төзелеш өчен буш территория – 12 га тирәсе, эш алып бару өчен бирелә торган участокларның минималь мәйданы 40 сутыйдан башлана. Паркта сәнәгатьнең төрле юнәлешендәге 20 ләп резидентны урнаштыру планлаштырыла.

– **«М-7 Ослан»**. Татарстанның Югары Ослан районы Набережные Моркваши авыл җирлеге территориясендә урнашкан. Парк М-7 трассасыннан ерак түгел урнашкан, аның гомуми мәйданы 18,5 га тәшкил итә.

– **«М-7 Шәле»**. Республиканың Питрәч районы Шәле авыл җирлеге административ үзәге карамагындагы участок. Парк М-7 трассасының беренче линиясендә, пландагы М-12 трассасы янында урнашкан. Гомуми мәйданы – 34,5 га.

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы башлыгы:

– Мин «М-7» индустриаль паркы үсешен уңай бәялим. Бу мәйданчык яшәячәк.

Руслан Хәлилов, Турыдан-туры инвестицияләр фонды идарәчесе:

– Асылда, без Татарстан территорияләрен индустриаль яктан үстерү кысаларында беренче шәхси паркны, хәвефле якларын белеп, шикләнү катыш төзедек. Тик бу тәвәккәллек үзен тулысынча аклады: командабыз бәяләп бетергесез тәҗрибә туплады, ә проект табыш китерә башлады һәм хәтта республикадан читтә дә танылды.

Валерий Бригаднов, «М-7» индустриаль паркы директоры:

– Үз производствосын гына түгел, ә бәлки тагын берничә эре предприятиеләрне дә шундый ресурслар белән тәэмин итәргә сәләтле зур завод-фабрика янында сәнәгать паркларының барлыкка килүенә мисаллар күп. Бездә андый җай юк иде һәм идеядән алып аны тормышка ашыруга кадәр бөтен юлны үтәргә туры килде. Бу исә, эшкуарлар үз акчаларын үсешкә салырга әзер булырлык итеп, бизнес өчен кирәкле мохитне формалаштырырга мөмкинлек бирде.

«АЛГА ҺӘМ ЮГАРЫГА!»

Казанның «Эникс» АҖ – дистә еллар элек нигез итеп алынган принципларга тугры калган хәлдә, фәнни-техник алгарышның алгы сафында булуның шәп үрнәге ул.

Акционерное общество ЭНИКС

Ике кечкенә самолет Каинки авылы өстендә бөтерелеп йөри: берсенең койрыгына – яшел, икенчесенекенә кызыл тасма тагылган. Бер борылыш, икенчесе... Ярышны берничә дистә тамашачы күзәтә. Кызыл тасмалы самолет берара көндәшен куып тота да винты белән аның тасмасын кисә. Җиңү!

Авиамодель спорты буенча бу ярышларны «Эникс» АҖ Татарстанның Югары Ослан районындагы үз полигонында инде биш ел үткәрә. Ярышлар төрле категориядәге модельләр өчен уздырыла, анда өлкәннәр дә, балалар да катнаша. Шул рәвешле предприятие авиамодель спортын үстерү турында гына кайгыртып калмыйча, үзенә яңа кадрлар да әзерли: планер белән мавыккан яшүсмерләр соңыннан беренче класслы конструктор, инженер, пилотларга әйләнә. Мондый ярышлар – «Эникс»ның иң яраткан проектларыннан берсе. Чөнки бүген Россиядә пилотсыз аппарат комплексларын серияле җитештерүдә алдынгы урыннарны биләгән компаниянең тарихы 40 ел элек нәкъ әнә шулай – планерлар ясау һәм аларны очыртудан башланган.

ПРОЕКТТАН ОЧЫРТЫП ҖИБӘРҮГӘ КАДӘР – БЕР ПРЕДПРИЯТИЕ

КАИ тәмамлаган талантлы егетләр тарафыннан 1980 нче елларда җыелган, киләчәктә пилотсыз очкычка әйләнәчәк тәүге очу аппаратларының фрагментларын быел «Эникс» ачкан уку-күргәзмә залында күрергә мөмкин. Шушында ук компаниянең иң кирәкле һәм өметле эшләнмәләре: алар арасында оптик-электрон разведка аппаратлары да, һава һөҗүменнән саклану чараларын сынау өчен мишень самолетлар да бар.

– 1980 нче елларда пилотсыз очкычлар нинди булырга тиешлеге турында идеяләребез күп иде. Кемгәдер бу идеяләр чынбарлыктан ерак кебек тоелды, ләкин без хаклы икәнлегебезне киләчәк раслаячагын беләидек. Шулай булды да, – дип искә ала «Эникс» АҖ генераль директоры Валерий Побежимов.

1988 елда аның җитәкчелегендә энтузиастлар берләшмәсе «Эникс» фәнни-тикшеренү үзәге (самолет төзү өчен эксперименталь фәнни-тикшеренү кооперативы) дигән рәсми статус ала. Очкыч аппаратта мәгълүматны кабул итеп, даими рәвештә операторга тапшыра алырлык идарә итү системасын ясау мөһим техник проблемаларның берсен тәшкил итә. Икенче бурыч идарә пультының һәм пилотсыз очкычның зурлыгын киметүдән гыйбарәт була – «Эникс»та стационар җайланмаларны күчереп йөртә торганга алыштырырга телиләр. Бу мәсьәлә дә, башкалары да уңышлы хәл ителә. Хәзерге көндә компания шөгыльләнә торган проектлардан күбесенең көндәшләре бөтенләй юк.

– Бүген без төрледән-төрле заказлар нигезендә пилотсыз очкычларны серияле ясый алабыз. Пилотсыз очкычларның проектын үзебез ясыйбыз, аларны үзебез сыныйбыз һәм җитештерәбез – бу исә эш процессын бик тизләтә,

Фотолар «Эникс» АҖнән алынды. РЕКЛАМА

чөнки тәэмин итүче ширкәтләргә бәйлелегебез бик аз. Бездә әллә ничә ноу-хау бар, мәсәлән, композит материаллардан ясалган җиңел, чыдам корпуслар. Аларны биредә, «Эникс»ның үзендә үк җитештерәләр, – дип сөйли предприятие генераль директорының беренче урынбасары Игорь Нагибин.

Хәзерге вакытта компаниянең иң кирәкле эш юнәлешләренең берсе – һава һөҗүменнән саклану системаларын сынау өчен мишень комплекслар. Е95М мишене сериялəп җитештерелә. Күргәзмә залында аның төрле объектларда төрле бурычларны үтәү өчен чыгарыла торган берничә модификациясе тәкъдим ителә.

Предприятиенең икенче көнүзәк әһәмиятле эш юнәлеше – мәгълүмат җыю һәм тапшыруның оптик-электрон системалары белән җиһазландырылган разведка комплекслары. Алар хәрби шартларда да, барып җитү авыр булган урыннардагы вазгыятьне тикшерү өчен тыныч вакытта да кулланыла ала, мәсәлән, зур янгыннар, техноген һәлакәтләр очрагында яисә коткару эшләрендә.

ЯҢА ЧОРГА АЯК БАСКАНДА

– Технологияләр бик алга китте, хәзер мондый аппарат җитештерүчеләр без генә түгел. Ләкин безнең зур өстенлекләребез җитәрлек. Беренчедән, бөтен техникабыз аккредитацияләнгән үзәкләрдә сынау уза. «Эникс» «Хәрби регистр» ирекле сертификацияләү системасы сертификатларына һәм ГОСТ Р ИСО 9001 (2001), ГОСТ РВ 15.002 – 2000, Хәрби техника ясау һәм җитештерүгә куюсистемасы (СРПП ВТ) таләпләренә туры килүен раслый торган Россия дәүләт стандарты сертификатына ия. Бу стандартлар бик җитди таләпләр куя, һәм без аларны үтибез. Икенчедән, пилотсыз очу аппаратларыбызның барысы да очыш ераклыгы һәм вакыты ягыннан яхшы күрсәткечләргә генә ия булып калмыйча, ниндидер функциональ бурычны да үти. Шулай ук Е95М мишене дә очышта аны зур истребительгә охшатырга мөмкинлек бирә торган җиһазлар белән баетыла. Аның тизлеге дә төрле булырга мөмкин – сәгатенә 400 км га кадәр. Өченчедән, без мишень җитештерүчеләрнең бер проблемасын чишә алдык – җылылык нурларын тарату имитациясенә сәләтле арзанлы двигатель эшләдек. Шул ук вакытта модельләребезнең бәясе – базарда иң түбәннәрнең берсе, – ди Игорь Нагибин.

Технологик үсешнең билгеле бер югарылыгына ирешеп, «Эникс» белгечләре тагын да алгарак китәргә тырыша. Алар заказчыны пилотсыз очу аппаратлары белән тәэмин итү генә түгел, ә бу очкычлар белән нәтиҗәле идарә итәргә мөмкинлек бирәчәк белемнәрне дә алырга була.

– Пилотсыз очкыч куллануда уңышның яртысы – әзерлекле оператор. Без үзебезнең әзерлек үзәген булдырдык һәм бөтен Россиядән инде 400 гә якын кешене укыттык, – дип сөйли Игорь Нагибин.

«Эникс» үз кадрларына гадәттәгечә бик зур игътибар бирә. Предприятиедә аңа нигез салучыларның күбесе генә түгел, аларның балалары һәм оныклары да эшли. Эзлеклелек, буыннарның дәвамчанлыгы проектлау, ясау, җитештерү процесслары белән идарә итү сыйфатын саклап калырга һәм камилләштерергә мөмкинлек тудыра. Ә авиамодельчеләр ярышы авиация тармагында профессионал булу өчен чыннан да күп нәрсә бирергә әзер сәләтле яшьләрне табарга һәм эшкә җәлеп итәргә, илебезнең пилотсыз авиация тармагын киләчәккә алып барырлык, бу эш белән чын-чынлап мавыккан кешеләр берлеген булдырырга булыша.

– Без пилотсыз очкычларны массакүләм куллану чоры бусагасында торабыз. Идарә ителә торган аппаратларның төрле өлкәләрдә – йөк ташудан алып космик тикшеренүләргә кадәр зур мөмкинлекләр ачуы шик уятмый, – ди Игорь Нагибин. – Әлбәттә, без алга таба да үсәргә, хезмәттәшләребез һәм фикердәшләребез белән тәҗрибә уртаклашырга телибез. Яңа кадрларга, «Алга һәм югарыга!» дигән шигаребезне кабул итүчеләргә без бик шат.

Е95М мишене сериялəп җитештерелә. Күргәзмә залында аның берничә модификациясе тәкъдим ителә.

Уку-күргәзмә залын ачу.

ТӘМЛЕ

Пессимистлар күңелсез көзгә зарланып, урамга чыгудан һәм салкын тидерүдән куркып өйләрендә утырганда, оптимистлар Казанга ашыга, чөнки бирелә елның теләсә кайсы фасылында матур гына түгел, бик тәмле дә.

Фото: Александр Ефремов

НОЯБРЬ

Бигрәк тә ноябрь ае тәмлелеге белән аерылып торды – Россиянең гастрономия башкаласы ул айда хәтта ике халыкара кулинария чарасы оештырды: WHERETOEAT ТАТАРСТАН 2022 милли ресторан премиясенә һәм Россиядә Юныс Әхмәтҗанов исемендәге беренче цифрлы халыкара кулинария турнирына йомгак ясалды.

WHERETOEAT – КАЙДА АШАРГА?

3 ноябрьдә Казанда WHERETOEAT Tatarstan 2022 милли ресторан премиясе җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы оештырылды. Исәп буенча бу дүртенче бәйрәм: WHERETOEAT Tatarstan 2019 елдан бирле үткәрелә.

Рейтинг Татарстан Республикасы ресторан бизнесының йөз профессионалы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән төзелә.

Рейтингка барлыгы 147 ресторан керде. Алар Казанда, Яр Чаллыда, Әлмәттә, Түбән Камада һәм Алабугада урнашкан. Шул ук вакытта беренче 50 ресторан арасына республика башкаласыннан читтәге бер генә оешма керә алды – Яр Чаллыдан «Бульвар Дежа Вю».

Республиканың иң яхшы ресторannары рейтингында беренче урынны икенче ел рәттән Казандагы «Артель» гастробистросы (шеф-повары – Булат Ибраһимов) алды. Икенче урында – «Марусовка» рестораны (шеф-повары – Рөстәм Рәхимов), өченчедә – «Сетка» бары (шеф-повары – Денис Фадеев).

WHERETOEAT Tatarstan 2022 Топ-10 исемлеге:

1. «Артель», Казан.
2. «Марусовка», Казан.
3. «Сетка», Казан.
4. «Приют Холостяка», Казан.
5. Zuka, Казан.
6. Dali, Казан.
7. More & More, Казан.
8. «Чирәм», Казан.
9. Cheeseria, Казан.
10. Branch, Казан.

Милли ресторан премиясен оештыручылар фотосы WHERETOEAT Tatarstan 2022

Татарстанның иң яхшы бары – Mr. Willard.

«ММЧ сайлавы» номинациясендә һәм Топ-10 исемлегендә беренче урында – «Артель» бистросы.

«Иң яхшы татар кухнясы рестораны» – «Чирәм»

«Ел шеф-повары» номинациясендә беренче тапкыр **Денис Фадеев** җиңде, **бренд-шеф Cultura Hospitality Group** («Сетка» бары, Manufact, «Культ Бар»).

«Иң яхшы татар кухнясы рестораны» дип, **«Чирәм»** рестораны табылды.

Иван Егоров («Маруcовка», «Сетка») икенче ел рәттән **«Ел сомельесы» номинациясендә җиңде.**

Татарстанның иң яхшы бары дип, Казандагы **Mr. Willard** танылды.

«ММЧ сайлавы» номинациясендә **«Артель»** бистросы җиңүче дип табылды.

Махсус **«Нетмонет» сервисы версиясе буенча ел официанты»** номинациясендә Максат Палванов (Dali, Казан) җиңү яулады.

WHERETOEAT Tatarstan 2022 премиясе Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитеты ярдәме белән оештырылды.

«Ел пешекчесе» Денис Фадеев.

«Ел сомельесы» Иван Егоров.



«Ел официанты» Максат Палванов.

ЮНЫС ӘХМӘТҖАНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОНКУРС: РИЗЫККА ХӨРМӘТ

16 ноябрьдә Иннополиста Юныс Әхмәтҗанов исемендәге халыкара яшь ашчылар турниры тәмамланды. Үзләренең аш-суга осталыгын Татарстан һәм Россиянең төрле почмакларыннан килгән 8 финалчы күрсәтте. Конкурска барлыгы 350 кеше гариза биргән булган.

Турнирда катнашучыларны Юныс Әхмәтҗановның оныгы каршы алды һәм аларга рәхмәтләрен ирештерде:

– Бабам милли татар ашлары традицияләрен яңартты. Безнең кадерле кешебезне онытмыйча, аның эшен дәвам иттерүчеләргә чиксез хөрмәтемне белдерәм, – диде Инсаф Әхмәтҗанов.

– Бу – заманча цифрлы форматы белән аерылып торган үзенчәлекле талантлар фестивале, – дип сәламләде кунакларны Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева. – Үзләре әзерләгән ризыкларда финалчылар безгә киләчәктә милли кулинариянең нинди югарылыкта булырга тиешлеген күрсәтүенә ышанам. Алар үз һөнәрләренең остасы булырга һәм халкыбыз ашлары белән дөньяны таң калдырырга әзер. Изге нәрсә – ризыкка кагылган һәр кеше үз иҗаты һәм тырышлыгының ничек бәяләнәчәгенә һәрвакыт борчыла. Ризык әзерли белү – һәркемгә дә бирелми торган олуг талант ул. Сез, кулинария могҗизасын чынга ашырып, безне берсеннән-берсе үзенчәлеклерәк тәм-томнар белән сөендерә аласыз.

Фото: Александр Ефремов

«Ашчы-кондитер» юнәлеше буенча дүртенче курс студенты, финал бәйгесендә катнашкан **Рафис Җамалетдинов «Фундаменталь белемнәр»** дип аталган махсус номинациядә бүләкләнде.

«Традицияләрне саклаучы» категориясендә **Диләрә Дакукина** иң яхшысы дип табылды.

Аш-су осталарының ризык белән чиста, сак эш итеп, әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итә алуын күрсәткән **«Социаль җаваплылык»** номинациясендә **Денис Раков** җиңүче булды.

Илнур Самархановны белгечләр җирле җитештерүчеләр – фермерлык продуктларын яраткан өчен (**«Трендта – локальлек»**) билгеләп үтте.

«Дизайн» һәм **«Чикләрсез караш»** номинацияләрендә **Григорий Степанов** һәм **Антон Овсянников** беренче урын алды.

Халыкара турнирда Анастасия Михайлова җиңү яулады һәм эшкәртелгән пластиктан уклау рәвешендә ясалган дизайн-кубокка лаек булды. Ул шулай ук **«Киләчәк технологияләре»** номинациясендә дә иң алдынгысы дип табылды. Финалда Анастасия белгечләргә тамыразыклар белән пешерелгән үрдәк ите тәкъдим итте:

– Беренче карашка, мин пешергән ашамлык шактый гади дә кебек. Мин татар халык ашлары традицияләрен һәм үзенчәлеген берләштерергә тырыштым, – дип аңлатты ул.

– Бөтен турнирыбыз ризык әзерләүнең яңа концепциясенә нигезләнде, егетләр һәм кызлар барысы да үз-үзен сынады, аларга төрле кыенлыкларны җиңеп узарга туры килде, – диде жюри рәисе Андрей Саховский бүләкләү тантанасын тәмамлаганда. – Про-

– Без интернет-портал булдырдык һәм кулинария конкурсын илдә беренчеләрдән булып цифрлы форматта уздырдык, – ди Татарстан рестораторлары һәм отельерлары ассоциациясе президенты Зөфәр Гаязов. – Моннан тыш, быел беренче тапкыр бу конкурста без инде азу ярган осталарга түгел, ә кухняда аерым бер эш өчен җаваплы булган, яшь, талантлы ашчыларга игътибар юнәлттек. Алар барысы да бик шәп чыгыш ясады һәм алга таба үсәргә теләгәнлекләрен күрсәтте. Бу бик мөһим.

цессны күзәтү кызыклы булды, финалчылар безгә үзләре – яшьләр карашынча яңа кулинария осталыгын күрсәтте. Аларның перспективалары бик югары, алар – безнең киләчәгебез. Бу турнирда барысы да җиңде!

– Татарстанга бик күп туристлар килә, – дип өстәде республиканың Туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Сергей Иванов. – Нәкъ менә бу егетләр һәм кызлар исә Татарстанны чын гастрономия башкаласына әйләндерә... Без дәрәҗәне югары тотарга, яшьләр арасында бу һөнәрне популярлаштырырга тиеш.

– Без барысын да бәйгедә катнашучылар мөмкин кадәр күбрәк тәэсирләр алып калырлык итеп оештырдык, – дип сөйләде Казан рестораторлары һәм отельерлары ассоциациясенең башкарма директоры Галина Шәрәфетдинова. – Конкурс мәйданчыгы урнашкан Иске Татар бистәсендә дә, бүләкләү тантанасы узган Иннополиска да күпләренең беренче тапкыр килүе иде. Без ярышның катнашучыларда көчле хисләр уятканлыгын күрдек. Һәм алар, безгә искиткеч хезмәт җимешләрен тәкъдим итеп, шул хис-тойгылары белән уртаклашты. Катнашучыларның берсе менә мондый ризык әзерләде: «Ысланган ткемали соуслы гөбәдия гарниры янына бүдәнә, виноград һәм зәңгәр сыр тутырылган катлама». Яраткан җирле ашамлыгыбыз – гөбәдия табынга беренче тапкыр бүдәнә белән бергә бирелде. Ул теләсә кайсы илнең югары кухнясы ризыгыннан бер дә калышмаслык тәмле һәм зәвыклы булды.

1

АШ БАР ҖИРДӘ БӘРӘКӘТ БАР

Мобилизацияләнгән татарстанлыларны «Полигон» хәрби часте территориясендә атна саен төш вакытында төрле милли тәм-томнар һәм, өстәвенә, еш кына концерт белән дә сыйлыйлар. Ватанны саклаучылар өчен «милли кухня» инициаторлары – Татарстан халыклары ассамблеясе, Дуслык йорты һәм республикадагы милли-мәдәни берләшмәләр вәкилләре. Удмурт, үзбәк, таҗик, азәрбайҗан җәмгыятьләре вәкилләре мобилизацияләнгән ир-егетләрне милли ризыклар белән сыйлаган инде.

– Барысы да ТР Иҗтимагый палатасы һәм «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы рәисе Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиеваның телефоннан шалтыратуыннан башланды, – ди Татарстан халыкларының Дуслык йорты директоры Ирек Шәрипов. – Зилә ханым мобилизацияләнүчеләрнең Казан янындагы җыелу урынына барганнан соң алган тәэсирләре белән уртаклашты. Алар татар милли ашлары, бүләкләр алып барган, концерт программасы да күрсәткән. Шундый җылы очрашудан соң, аның янына Удмурт Республикасыннан чакырылган хәрбиләр килеп, Татарстандагы милләттәшләре белән очрашу оештырып, аларның да милли ашларын китертеп булмыймы икән, дип сорашкан. Мин Татарстан удмуртлары милли-мәдәни автономиясе рәисе Андрей Герасимов белән сөйләштем, һәм ул, шундук «Печь-перепеч» мобиль удмурт кухнясына заказ биреп, акчасын да түләде, көнен дә билгеләде. Шул ук көнне берничә казан пылаулары белән Абдуманоб Абдусаттаров җитәкчелегендә үзбәк ашчылары да килде.

Мобилизацияләнүчеләр арасында Чувашия һәм Мари Элдан килүчеләр дә күп булып чыкты. Бу турыда Татарстан халыклары ассамблеясендә сөйләгәч, безгә башка иҗтимагый оешмалар да кушылды. Татарстан халыклары ассамблеясе башкарма комитеты җитәкчесе Константин Яковлев әлеге хәрәкәтне туктаусыз агымга әйләндерә алды: милли оешмалар вәкилләре үзләренең милли аш-сулары һәм музыкаль номерлары, җылы кием-салым

Фото: addnt.ru

һәм хәрбиләрнең көнкүрешендә кирәкле предметлар белән атнасына берничә тапкыр хәрби частькә килә башлады. Нәтиҗәдә хәрбиләр белән очрашуда Рус милли-мәдәни берләшмәсе рәисе Ирина Александровская да, таҗиклар җәмгыяте җитәкчесе Сабриддин Тоиров та булып кайтты, ә азәрбайҗан җәмгыяте бөтенләй рекорд куйды – алар 2000 порция пылау әзерләде! Чеченнар җәмгыяте дистәдән артык мобиль мич комплекты ясады, казаннар сатып алды. Ассамблея башкарма комитеты хезмәткәрләре, Дуслык йорты белгечләре, милли берләшмәләр активистлары җылы кием-салым алу өчен акча җыюда катнашты.

Мондый очрашулар вакытында бик күп тәэсирле мизгелләр дә була, хәрбиләр үзләренең яраткан артистлары белән очраша, танышлары белән күрешә...

«Мобилизацияләнүчеләргә ярдәм» акциясендә катнашучылар:

1. «ТР ҮЗБӘКЛӘРЕ МММ» ТИО
2. «ТР ТАҖИКЛАРЫ МММ» ТИО
3. ТР АЗӘРБАЙҖАННАРЫ ТИО
4. «ВАЙНАХ» ТР ЧЕЧЕННАРЫ МММ» ТИО
5. «ТР РУСЛАРЫ МММ» ТИО
6. «МАНТ» ТИО (Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясе)
7. «ТР ЧУВАШЛАРЫ МММ» ТИО
8. «АНАДОЛУ» ТР ТӨРЕКЛӘРЕ МММ» ТИО
9. «ҖИЛӘК-ҖИМЕШ-ЯШЕЛЧӘ БАЗАСЫ» ҖЧҖ
10. «ДОАНКЕТ» ТР ВЬЕТНАМНАРЫ ҖӘМГЫЯТЕ» ТИО
11. «ТР БАШКОРТЛАРЫ МММ – БАШКОРТ КОРЫЛТАЕ» ТИО
12. «ДАГЫСТАН» ТР ДАГЫСТАН ХАЛЫКЛАРЫ БЕРЛӘШМӘСЕ» ТИО
13. «ДЕМОС» ТР ГРЕКЛАРЫ МММ» ТИО
14. «КАЗАН ШӘҺӘРЕ КОРЕЯЛЕЛӘРЕ МММ» ҖИО
15. «ТР ЯКУТЛАРЫ МММ» ТИО
16. «СПАДЧИНА» КАЗАН ШӘҺӘРЕ БЕЛОРУСЛАРЫ» ҖИО
17. «ТАТАРСТАН НЕМЕЦЛАРЫ МММ» ТИО
18. «ТР КЕРӘШЕННӘРЕ» ИО
19. Татарстан халыклары ассамблеясе
20. Татарстан халыклары Дуслык йорты

1 Пылау Таҗикстанның традицион рецептлары буенча учакта пешерелгән.

2 Мобилизацияләнүчеләргә Казандагы ике мәйданчыкта ике меңләп порция пылау таратылган. Акциядә Казан һәм Әлмәтнең азәрбайҗан җәмгыятьләре, шулай ук Татарстан халыклары ассамблеясе җитәкчелеге катнашкан.

3 «Печь-перепеч» мобиль удмурт кухнясы килешенгән көнне, безнең хәрбиләр янына килеп, пәрәпәч пешергән.

4 Чеченнар җәмгыяте кыр шартларында ризык әзерләү өчен казанлы мичләр ясаган.

PRESSA

редакухнясы

МӘҢГЕЛЕК ТУҢЛЫК ИЛЕННӘН КАЙНАР СӘЛАМӘТ – СӘЛАМ!

Татьяна Вафина

Ел саен, 31 декабрьдә, мунча кереп чыккач ук, «Татарстан» нинди дә булса гайре табигый урынга Яңа ел мәҗлесенә кунакка бара. Бу юлы да, Яңа ел кәефенә иң туры китереп, карлы-буранлы салкын якка юнәлдек. Якутиягә. Анда безне бүгенге көнебезнең баш ашчысы сыйфатында «Сахамедиа» Республика мәгълүмат-нәшрият холдингы» АҖ генераль директоры Виктор Колесов каршы алды. Ул безгә «сәламәт» дип аталган якут халык ризыгын әзерләячәк.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

1 өлешкә:
- Сөт – 5–7 аш кашыгы;
- Он – 3 аш кашыгы;
- Атланмай – 1 аш кашыгы;
- Тәменчә тоз.

– Мин бу ризыкны, әзерләве бик гади булса да, бик туклыклы һәм файдалы булганга сайладым. Һәм бик тиз әзерләнә ул – иртән 5–7 минутта пешереп була. Минем ишетүемчә, сәламәт – төрки сүз һәм ул татар телендә «сау» мәгънәсендә кулланыла. Безнең халыкларны берләштерә торган ризык исеме булып чыга шуңа күрә.

– Барысы да бик гади эшләнә, – ди Виктор Джамаханович, – сөткә атланмай кушабыз да кайнатып чыгара язабыз. Аннары агач кашык (бездә ул «ытык» дип атала) белән даими болгата-болгата, иләнгән он һәм тоз өстибез да, сары май пәйда булганчы, сүрән утта пешерәбез. Сәламәт әзерләү өчен эре итеп тарттырылган арыш яки арпа оны яхшырак, тик бодай оны да ярый... Сәламәтне табынга кайнар килеш һәркемгә аерым савытта яки агач касәдә (кытыйа) бирәләр.

Ә ул әзерләнгән арада ашчы белән сөйләшеп алырга була...

Фото: М. Васильев

Сәламәтне табынга кайнар килеш һәркемгә аерым савытта яки агач касәдә (кытыйа) бирәләр.

ТӨП КОНСЕРВАНТ – СУЫК

– Рус кухнясы бездә ботка һәм щи, грузиннарныкы – шашлык, Себернеке – пилмән, татар халык ашлары исә өчпочмак һәм чәкчәк белән ассоциацияләнә... Ә менә Якутиянең милли кухнясы нинди? Мәсәлән, совет чорындагы «Оливье» салаты кебек, Яңа елны каршылаганда һичшиксез әзерләнә торган якут ризыгы бармы?

– Якут ашлары көньяктарак урнашкан төбәкләрдәге кебек бик төрле түгел. Мәсәлән, безнең Якутиядә тәмләткечләрнең әллә ни кирәге юк, чөнки биредә төп консервант – суык. XX гасырда бездә бик күп яңа ризыклар пәйда булган. Ә иң гадәтиләре – бик гади, бер өлеше бурят ризыкларына, бер өлеше чечен тәгамнәренә охшаган. Бу – пешкән ит, казыкка тезелгән ит, итле яки эч-бавырлы шулпалар, онлы шулпалар, керчэх (күпертелгән татлы сөт өсте) белән якут кабартмасы.

Яңа ел табынына килгәндә исә, строганина – юнылган туң акбалык (чир, нельма) бөтен бәйрәмдә дә төп ризык санала. Ул бездә кышын тотылган балыктан гына әзерләнә. Беркайчан да туңдырылган яки туңдырып эретелгән балыктан ясалмый. Строганина өчен балыкны 30–40 градус суыкта боз астыннан ятьмә белән тоталар, ул шундук бик каты туңа һәм бозланмый.

Тай итеннән строганина да деликатес булып тора.

Гомумән, бездә нәкъ менә строганина Яңа ел табынының күрке санала. Әлбәттә инде, табында һичшиксез оливье һәм мандарин да була.

ТАТАР АКЦЕНТЛЫ ЯКУТ РИЗЫГЫ

– Сез үзегез ашарга әзерлисезме?

– Бик сирәк. Якут милли ашларын гына түгел, Азия, Европа ризыкларын да пешерәм. Сталик Ханкишиевны еш карыйм, ул бик кызык әзерли. Соңгы вакытта татар милли ашлары белән дә таныштым. Казанда бик тәмле бер ризыктан авыз иттем, кызганычка, исемен оныттым... Ул кызыл эремчек – корт, бал, йөзем белән иде...

– Гөбәдияме?

– Шулдыр, мөгаен. Бик тәмле. Бәлеш белән дә сыйланганым бар. Миңа «Татар халык ашлары» дигән китап бүләк иттеләр – анда үзенчәлекле ризыклар бик күп. Балачакта әбием пешерә торганга охшаш бер рецепт та очраттым әле анда. Без аны бик яратып ашый идек. Бездә генә түгел, татарларда да бар икән андый сый.

Безнең Якутиядә нигездә аш-су янында хатын-кызлар кайнаша. Ир-атлар кырысрак шартларда, мәсәлән, ауда ашарга әзерләргә мөмкин. Ау – чын ирләр эше, анда рецептлар да ирләрчә – ботка, кыргый хайван яки кош ите.

БАСМА МАТБУГАТНЫ УКУЧЫГА ИЛТЕП ҖИТКЕРҮЕ КЫЕН

– Ә якут массакүләм мәгълүмат чараларының «кухнясы» нинди? Нинди проблемалары бар?

– Безнең медиахолдингка өч төп матбугат чарасы керә: «Саха Сирэ» газетасы, совет чорында ул «Кым» дип аталган, быелтыр 100 еллыгын бәйрәм иттек; 1917 елда оештырылган «Якутия» (элек «Социалистик Якутия» дип аталган) газетасы һәм 1990 нчы еллар башында төзелгән «Якут-Саха» мәгълүмат агентлыгы, сезнең «Татмедиа»дагы «Татар-информ»ның аналогы. Һәр газетаның үзенең электрон версияләре бар. «Якутия»неке – «Якутия Daily», «Саха Сирэ»ныкы – «Саха Сирэ» һәм «Эдэр Саас» сайтлары. «Эдер Саас» «яшьлек еллары» дип тәрҗемә ителә. Моннан тыш, без телеграм-каналларда да, Россиядәге барлык диярлек пабликларда, социаль челтәрләрдә дә эшлибез.

Журналларга килгәндә исә, алар бездә даими нигездә чыгарылмый. Ниндидер чара, бәйрәм, ярышка багышланган тематик журналларыбыз чыккалый. Чөнки безнең республика бик еракта урнашкан һәм басма матбугатны укучыга илтеп җиткерү бик кыен. Кызганыч ки, «Россия почтасы» безнең басма матбугатны теләсә кайчан һәм теләсә кайсы җиргә илтеп җиткерә алмый, шуңа күрә кайбер үзәк районнарда үз каналларыбыз, үз челтәребез аша тарату белән шөгыльләнәбез: басмаларыбызны кибетләрдә сатабыз. Аңлату өчен: безнең республиканың мәйданы якынча Һиндстанныкы кадәр. Һәм бирегә миллионга якын кеше яши. Нинди торак пунктлар һәм алар арасында нинди аралар булуын күз алдына китерә аласызмы? Шунлыктан, сүз дә юк, газеталарны укучыга илтеп җиткерү – бик катлаулы хезмәт. Нәкъ менә шуңа күрә үз вакытында цифр белән эшләүгә күчәргә карар кылдык, без интернет-форматка, социаль челтәрләргә, мессенджерларга күчтек.

БАСМА ВЕРСИЯ – ДОКУМЕНТ УЛ

– Ягъни, кайберәүләр инде күптән фаразлаганча, басма матбугат чаралары чыннан да бетүгә таба барамы?

– Басма матбугат чараларының бетүгә таба баруы белән мин килешмәс идем. Минемчә, моңа мисаллар шактый. Мәсәлән, кино пәйда булгач, театрның көне санаулы, телевидение пәйда булгач исә кинотеатрлар бетәчәк, дип гөманлаганнар иде... Әмма бүгенге көнгә кадәр барысы да бар, барысы да эшли, шуңа күрә басма матбугат чараларының да үз укучысы һәрвакыт булачак. Әйе, алар, ихтимал, моннан 50–70 ел элеккеге кебек үк күп булмас та. Әмма алар булачак. Шунлыктан без басма матбугатны барыбер саклап калачакбыз. Хәзер һәр газета редакциясе цифрлы мохиттә дә, басма матбугат кырында да эшли – без укучыларыбызга сайлап алу мөмкинлеге бирәбез. Минемчә, без дәүләт массакүләм мәгълүмат чаралары буларак эшләгән дәвердә укучыларыбыз да булачак. Тираж күләме кимергә мөмкин – бу бөтен дөньяга хас тенденция, әмма басма версия барыбер нәшер ителәчәк. Чөнки басма версия – документ ул. Истәлеккә кала торган документ. Һәм газетага язучылар, аннан үзләре турында укучылар, актив укучылар, билгеле ки, басма версиягә өстенлек бирә – аны киләчәк буын өчен саклап калырга тырыша. Шуңа күрә мин, басма версия һәрвакыт булачак, дип уйлыйм.

ТӨНЬЯКТАГЫ АЗ САНЛЫ ХАЛЫКЛАР ӨЧЕН

– Татарстанда «Татмедиа» массакүләм мәгълүмат чараларын «дәүләтнекеләр» дип йөртәләр. Сездә «Сахамедиа» матбугат чараларын халыкта ничек атыйлар? Аларның нинди дә булса махсус миссиясе бармы?

– Безне дә кыска гына итеп «ГосСМИ» дип йөртәләр. Минемчә, туксанынчы елларда шау-шу, ызгыш-талашны яктырту артыннан куган сары пресса фонында без үзебезне башкачарак тоттык. Мин беркемне дә гаепләмим – бу шактый күп укучының, тамашачының нормаль ихтыяҗы. Мөгаен, моннан башка барысы да бик төче булыр иде. Әмма безнең миссиябез – чынбарлыкны дөрес чагылдыру. Без укучыбызны ниндидер мәгънәсез шау-шулар белән җәлеп итәргә омтылмыйча, дәүләт ММЧ буларак аңа оператив, чын һәм файдалы мәгълүмат җиткерергә тиеш. Бу – дөрес мәгълүматны, мәдәният традицияләре турында мәгълүматны, төбәктә яшәүче төрле милләт халыклары телендәге мәгълүматны таратуга юнәлтелгән бөек миссия.

Безнең «Сахамедиа» холдингына кергән матбугат чаралары якут һәм рус телләрендә чыга. Төньякта яшәүче башка аз санлы халыкларга килгәндә исә, «Элькен» дигән журнал чыгарыла. Руслар һәм якутлардан тыш, республика территориясендә тагын эвенклар, юкагирлар, долганнар, чукчалар да яши бит әле... Һәм менә «Элькен» журналы алар белән эшли. Аның өчен белгечләрне нигездә университетның филология факультеты әзерли. Мондый кадрлар Арктика дәүләт мәдәният институтында да әзерләнә.

СЫЙФАТЛЫ АНАЛИТИКА ЯРАТАМ

– Сез, күп төрле ММЧ җитештерә торган холдинг башлыгы буларак, нинди мәгълүмати «азыкка» өстенлек бирәсез? Нинди жанрлар күңелегезгә аеруча якын: кайнар яңалыкларны, табадан гына төшкән аналитиканы, репортажларны, әллә инде тыныч кына укый торган материалларны?

– Мин үзем тарихи документаль мәгълүматка өстенлек бирәм, шул исәптән видеоларга да. Һәм, әлбәттә инде, яңалыклар җәлеп итә. Безнең Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясендәге коллегаларыбыз тапшыруларын кызыксынып карыйм. Хәрби корреспондентларны күзәтеп барам. Сыйфатлы аналитика яратам, ул кешеләрне яңа фикер һәм идеяләргә баета.

– Быелның төп вакыйгаларына бәйле рәвештә яңалыклар кебек мондый «азык» белән кызыксыну күп тапкырга артты. Кулланучы кайнаррак яңалыкларны – атыш-сугыш, үтерешләрне бик еш карый... Яңалыклар контентын кулланучы социаль челтәрләрдәге комментарийларда кабынып киткән бәхәсләрдә үзе дә рәхәтләнеп катнаша. Сүз дә юк, бу укылыш, каралыш җәһәтеннән барлык яңалыклар агентлыкларына плюс булып тора. Ә менә кешелеклелек, гуманизм ягыннан караганда ничегрәк дип саный-



1 Кушабыз

2 Кайнатабыз

3 Илибез

4 Салабыз

5 Пешерәбез

6 Табынга бирәбез

- Теләсә кайда ял итәргә мөмкин, әмма яшәвен һичшиксез биредә яшәү зарур. Бездә чын кыш, чын яз, чын җәй була. Һәм чын Яңа ел. Иркен сулап яшисең.

сыз – халыкка гел шундый «азыкны» биреп торырга кирәкме? Аны башка төрле – иҗади, мәдәни, спорт яңалыкларын яратырга мәҗбүр итеп буламы?

– Төрле низаглар яктыртылган кайнар, сары мәгълүматка ихтыяҗ зур шул. Халыкка криминаль хроника ошый, аларга нигәдер шундый кадрлар кирәк. Болар барысы да күпмедер дәрәҗәдә булырга тиеш, әмма, алдарак әйткәнемчә, дәүләт гаммәви мәгълүмат чараларының төп миссиясе – халыкны яктылыкка һәм игелеккә өндәү ул. Әгәр дәүләт ММЧ моны эшләмәсә, бөтен журналистика сез әйткән караңгылыкка кереп чумар иде. Хәзер шуны сизәм: соңгы вакытта күп кенә укучы-тамашачы-тыңлаучы гаугалы тикшеренүләрдән муеннан гарык инде, чөнки алар артык күп. Хәтта телеграм-каналлардан да сизелә – кирәкле, файдалы, тыныч мәгълүмат булган җирдә язылучылар саны шундук арта башлый.

КӨЧ - ХАКЫЙКАТЬТӘ, УЛ БАРЫБЕР ҖИҢӘЧӘК

– Блогерлар, фейклар һәм «диван сугышлары» турында сезнең һөнәри фикерегез нинди? «Сахамедиа», профессиональ ММЧ үз канаты астына җыеп, мондый мәгълүмат тапшыручыларга каршы көрәшәме, яки алар белән хезмәттәшлек итәме, әллә инде күрмәмешкә салышамы?

– Блогерлар төрле була бит. Җаваплылары да бар, җавапсызлары да җитәрлек. Блогерга әйләнгән журналистлар бар. Фейк таратучылар да шактый. Алар бигрәк тә махсус хәрби операция башлангач артты. Без бу фронтта күптән бит инде. Һәм алар белән эшлибез. Безнең бурыч – аларның чын йөзен күрсәтү, фаш итү. Һаман да бер үк кеше яки канал даими рәвештә фейк тарата икән, халык аңа ышанмый башлый. Ничек фаш итәбезме? Гадәти көндәлек эшебез белән. Журналистлар махсус операция урыннарына, хәрби округларга бара, мобилизацияләнүчеләр, үзләре теләп китүчеләр белән аралаша. Без моның чынлыкта ничек булуын күрсәтәбез, һәм халык фейк яңалыкларга ышанудан туктый. Чөнки көч – хакыйкатьтә, ул барыбер җиңәчәк.

ЛЕНА ЯРЫНДА

– Якутиядә сезнең яраткан урыннарыгыз нинди? Кайда тынычланасыз? Кайда көч туплыйсыз?

– Лена елгасы ярында Еланка дигән урын бар. Шундагы урманда, күлләр янәшәсендә, печән өстендә яки көзге аудa ял итәргә яратам. Нерюнгри янында Нахот, Лена кыялары кебек искиткеч урыннар бар – безнең республика шундый гүзәл табигать күренешләренә бик бай. Минемчә, бөтен кеше дә табигать кочагында көч-куәт туплый торгандыр.

ҖИР ПЛАНЕТАСЫНДАГЫ ЧЫН ЭКСТРИМ

– Әгәр сезнең янга башка төбәктән моңарчы беркайчан да Якутиядә булмаган кеше кунакка килә икән, аны иң беренче булып кая алып барыр, нәрсә күрсәтер идегез?

– Якутиягә йә җәен, эссе чакта – июнь азагы – июльдә, йә кышын, декабрь – гыйнварда килергә кирәк. 50 градус суыкта чын экстримны татырга һәм Җир планетасындагы иң кырыс климатның нинди булуын тоярга була. Җәен исә беркайчан да эреми торган бозлыклар сокландыра, 30 градус эсседә коену костюмыннан гына боз өстендә йөрергә мөмкин. Тауларда кар бәреш уйнарга да була. Мәңгелек туңлык шахтасына керү дә мавыктыргыч, урамда 35 градус эссе чагында, анда 17 градус суыкта йөрисең. Шахта эчендә таудан шуарга, боз сыннар белән хозурланырга мөмкин... «Лена кыялары» табигать паркы – Якутиядәге иң данлыклы урыннардан берсе. Әлеге табигать һәйкәле ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән. Биредә галимнәр Кембрия периодын өйрәнә. Мин Якутск шәһәренә якын урыннарны гына атадым әле. Самолетта Лаптевлар диңгезенә кадәр барып җитәргә, изге Кисилях тауларын күреп сокланырга, Салкынлык полюсында туңарга була. Якутиядә табигать гүзәллекләре һәм могҗизалары белән хозурланыр урыннар бик күп.

ЯКУТ – ТУҢМАУЧЫ ТҮГЕЛ, БӘЛКИ ДӨРЕС КИЕНӘ БЕЛҮЧЕ УЛ

– Кайвакыт Якутиядә бик-бик салкын була. 80 градус суыкта йөреп барган җирдән туңып үлгән хайваннарның фотолары былтыр бөтен Җир шары халкын шаккатырды. Ә бит шундый температурада аларны кемдер фотога да төшергән, телефон (фотокамера) төймәләренә баскан... Якут халкы һәм якут техникасы мондый температура рекордларына ничек чыдый? Сезнең җылырак төбәккә күченәсегез килмиме?

– Үзәк Якутиядә 80 градуслы суыклар бик еш булмый ул үзе. Иң төньякта, диңгез якын булганга, кышын һава температурасы 25–30 градустан артмый. Әмма анда бик каты кар бураннары котыра. Якутскида гадәттә 50–60 градус суык була. Техникадан файдалануның үз үзенчәлекләре бар. Кышын бездә машиналар гаражга кергәч кенә сүндерелә. Туңмасын өчен, махсус материалдан тегелгән портатив җылы гаражлар белән парковкалардагы машиналарны «төреп» куялар.

Безнең журналистлар техникадан аеруча сак файдаланырга тиеш – 40-50 градус суыкта видеокамерага төшерергә киңәш ителми. Алар өчен махсус кышкы кофрлар бар, тик шулай да озак эшләп булмый. Әмма якутлар – салкынга чыдам халык, алар техникадан дөрес файдалану серләрен яхшы белә. Бездә шундый бер әйтем бар: якут – туңмаучы түгел, бәлки дөрес киенә белүче ул. Безнең үзебезнең киенү культурасы формалашкан, халык аны яхшы белә. Безнең халык бу җирдә гасырлар буе яши, чөнки безнең табигатебез бик күркәм, аны ташлап китеп булмый. Советлар чорындагы программалар буенча Ерак Төньяк районнарыннан күченүчеләр ватаннарын бик сагынып яши. Күп кеше хәзер кире кайта, биредә яши башлый, гаилә кора, бала үстерә. Якутия бик төрле ул, биредә температуралар диапазоны 40 тан 70 градус суыкка кадәр тирбәлә, биредә искиткеч табигатьле тундра, тайга, катнаш урманнар бар. Балык тотарга, ауга йөрергә яратучы ир-атлар моннан башка яши алмый. Шунлыктан минем беркайчан да каядыр күченү хакында уйланганым да булмады. Таиландта яши алмаучыларны беләм. Минемчә, теләсә кайда ял итәргә мөмкин, әмма яшәвен һичшиксез биредә яшәү зарур. Бездә чын кыш, чын яз, чын җәй була. Һәм чын Яңа ел. Иркен сулап яшисең.

СУЫК САКЧЫЛАРЫ

– Якутиядә Яңа елны ничек бәйрәм итәләр? Суык хакиме Чысхаан Кыш бабайга ничек туган? Аның Кар кызы бармы? Һәм биредә нишләп бер генә болан да күренми?

– Якутларның Яңа елы – Ысыах бәйрәме июньнең егермеләрендә билгеләп үтелә. Борын-борын заманнан бирле ул печән өсте алдыннан бәйрәм ителгән. Озын кыштан соң яшел чирәмне күргән кешеләр яңа елга сөенгән. Бәйрәмдә алар ярышкан, осталыкларын күрсәткән, гореф-гадәтләрне искә алган. Кияү-кәләшләр сайланган, гаиләләр туй үткәрү турында килешкән. Ысыах хәзер дә якутларның Яңа елы санала. Совет чорыннан калган традиция буенча 31 декабрьдә билгеләп үтелгән Яңа елны да, бөтен ил кебек үк, шатланып бәйрәм итәбез. Безнең Якутиядә суык хакиме Чысхаан бар, тик аның Кар кызы юк. Әмма илдә Яңа ел Якутиядән башланганга, ел саен декабрьдә бирегә Великий Устюг каласыннан Кыш бабай килә, аңа Чысхаан суык символы булган таягын тапшыра, Кыш бабай аны бөтен Россия буйлап үзе белән йөртә. Чысхаан гел биредә, Якутиядә, мәңгелек туңлыкта яши һәм суык сакчысы санала.

Якутскидан 800 чакрым ераклыктагы Нерюнгри бистәсендә исә болан үрчетүче эвенклар яши. Мөгаен, совет чорында шулай җәйлангандыр – геологик эзләнүләр бик күп булган, геологлар болан үрчетүчеләр яшәгән районнарда эшләгән. Алар геологларга ярдәм иткән. Шуңа күрә Якутия боланнар белән ассоциацияләнә дә. Әмма Үзәк Якутиядә борын-борын заманнардан бирле терлек һәм ат үрчетүчеләр яшәгән. Якут мәдәнияте якут атына бик нык бәйле. Ат биредә – транспорт та, азык та, спорт та, көнкүреш тә. Хәзер бездә төп хайван – ат ул.

Чысхаан гел биредә, Якутиядә, мәңгелек туңлыкта яши һәм суык сакчысы санала.

ТАТМЕДИА

ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРГА ЯЗЫЛГАН ӨЧЕН КАР КӨРИ ТОРГАН ҖАЙЛАНМА, ТЕЛЕВИЗОР ҺӘМ БАШКА БҮЛӘКЛӘР

Бүләкләр 2023 елның 9 февралендә уйнатылачак

1 язып

«ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына язып (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 җибәр

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә 21 гыйнварга кадәр җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз!). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 от

телевизор, электр иттарткыч, электрогриль һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – кар көри торган җайланма!

Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru. сайтында белә аласыз. Акция 2022 елның 22 октябреннән 2023 елның 20 мартына кадәр уздырыла.

Реклама. Яшь чикләве 16+

акыллы гамәлләр
игелекле эшләр
мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

«Сәйяр» ансамбленә исемне **кем** кушкан

«Саз» ансамбле **нигә** филармониягә күчмәгән

Алмаз Хәмзин «Саз» төркеменә **кайчан** гашыйк булган

Татарстан рок-музыкантлары **нәрсә** турында җырлый

Төньяк балкышын **кайчан** күрергә мөмкин

PRESSA

«Саз» ансамбле. «Радуга» телефестивалендә. Мәскәү, 1977 ел.

Алмаз Хәмзин. «Звени, мой «Саз»! фильм-концертын төшерү вакытында.

«Сәйяр» ансамбле.

Фотолар Алмаз Хәмзиннең шәхси архивыннан, «Сәйяр» төркемендә катнашучылардан алынды.

ҺӘР ЗАМАННЫҢ – ҮЗ ҖЫРЫ

Егерменче гасырның 60 нчы елларында Казанда беренче рок-төркемнәр һәм вокаль-инструменталь ансамбльләр пәйда була. ТАССРда татар телендә «чын» рок-музыка турында сөйләргә иртәрәк булса да, вокаль-инструменталь ансамбльләр шактый: «Орфей», «Идел», «Казан утлары» һәм «Сәйяр» ансамбленең беренче составы. Татар җырлары совет эстрадасы көйләренә һәм ритмнарына торган саен күбрәк иярә бара, шуңа күрә ул чакта популяр булган көйләрдә твист, фокстрот, хәтта ки арт-рок элементларын ишетергә мөмкин. Бүген без үткәннәргә күз салып, бик күп җырчы һәм музыкантларга сәнгать дөньясына юл ачкан ике иң популяр ансамбль турында сөйләргә булдык.

«ТАТАРЧА ДА, ЯҢГЫРАШЫ ДА ШӘП»

«Сириннәр хуш исләр тарата» дип җырлап йөргән яшь егетләрне өлкән буын әле хәтерлидер... 1970–1983 еллар. «Сәйяр» беренче татар эстрада вокаль-инструменталь ансамбленең республика буйлап шаулап-гөрләп йөргән чагы. Меңләгән кыз аларга үлеп гашыйк! Әйдәгез шул чакларга әйләнеп кайтыйк әле!

Фотолар геройларыбызның шәхси архивларыннан; «Татар-Информ» МА.

Элекке Советлар Союзында уздырылган күпсанлы профессиональ җыр конкурслары, югары уку йортларының җыр фестивальләре җиңүчесе һәм дипломанты «Сәйяр» вокаль-инструменталь ансамбле татар совет эстрадасына яңа дулкын булып килеп керә. Дөнья җимереп дисәм, арттыру булыр, ләкин ул егетләр заманында кимен куймый. Татарның «The Beatles»лары...

Ансамбльнең җитәкчесе – композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССР комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Рәшит Абдуллин.

«Сәйяр» төркеме составы белән дә таныштырыйк: Рәшит Абдуллин (көйләр авторы, аранжировка, вокал), Фәрит Сабирҗанов (бит-барабан), Рөстәм Җәләй (вокал, гитара), Фоат Зарипов (вокал), Владимир Земсков (бас-гитара). Бераз соңрак ансамбльгә Мансур Зарипов (җыр, КАИның «Узоры» төркеменнән күчә), Рөстәм Зарипов (вокал, фортепиано), Марат Зарипов (вокал), Рафаэль Мәҗитов (администратор), Альфред Камелевский (вокал) кушыла.

«НӘҖИП ҖИҺАНОВНЫҢ «СИРИННӘР»ЕН АСТЫН ӨСКӘ КИТЕРДЕК»

Рөстәм Җәләй,
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе

– Рәшит Абдуллин белән Казан музыка училищесының халык уен кораллары факультетында 1 нче курста укыганда таныштык. **Ул чорда вокаль-инструменталь ансамбльләр барлыкка килә башлаган иде.** Шуларның иң танылганнарыннан берсе – «Орфей» ансамбле. 1966–1970 нче елларда училищеда укыганда күңелле студент тормышы белән яшәдек. Аннан соң безне армиягә алдылар. Бу вакытта ансамбль оеша башлаган гына иде. Казанда Эчке эшләр министрлыгының эчке гаскәрләрендә Рәшит Абдуллин, барабанчыбыз Фәрит Сабирҗанов белән бергә хезмәт иттем.

Без хәрби частьләрдә бик еш чыгыш ясый башладык, республика буйлап гастрольләрдә булдык. Дуслыгыбыз ныгыды. **Армиядән соң, 1972 елда Казан дәүләт консерваториясенә укырга кердек. Нәкъ шушы елларда «Сәйяр» ансамбле формалашты.** Ул вакытта Чаллыдагы «Энергетик» мәдәният йорты директоры Шамил Закиров белән дус идек без. «Сәйяр» дип исемләү аның тәкъдиме булды. «Сәйяр» – беренче татар профессиональ театр труппасы исеме. Бу сүзнең мәгънәсе – сәяхәт итүче, мосафир. «Татарча да, яңгырашы да шәп», – диде ул. **Исем ансамбльнең репертуарын да билгеләде – татар халык, татар совет композиторларының җырларын, шул чордагы популяр җырларны эшкәртеп башкару.**

Консерваториядә Рәшит – композиторлык факультетында, Рөстәм Зарипов белән мин хор дирижерлыгы факультетында укыдык. Шул елларда «Сәйяр» бер-бер артлы зур уңышларга ирешә башлады. Вокаль ансамбльләр санап бетергесез күп булса да, татар коллективы бер генә иде. **1972 елда «Кышкы эстрада» («Зимняя эстрада») шәһәр фестивалендә җиңеп, төркемебез танылуга иреште.**

Без татарча җырларга тырыштык, үзенчәлегебез дә шунда булгандыр. Рәшит җырларны эшкәртә, үзгәртә иде. Һәм, кагыйдә буларак, без бәйгеләрдә гел беренче урыннар алдык. Милли коллектив булганга, безгә теләктәшлек күрсәткәнгә күрә дә түгел, сере бик гади – безнең башкару дәрәҗәсе бик югары иде. **«Сәйяр» Татарстанның мәдәни мохитендә саф җил булып исте. Безгә кадәр чит ил һәм совет композиторларының җырларын кабатлап башкарган музыкантлар бар иде. Без исә яңа идея – үзебезнең иҗатны тәкъдим иттек.**

Тора-бара «Сәйяр» шулкадәр популярлыкка иреште ки, безне таный, белә башладылар. Бервакыт трамвайда барганда, кешеләрнең миңа борылып-борылып карауларын сизәм, үзләре: «Әнә «Сәйяр» бара», – дип пышылдаша. Безне белмәүче кеше булмагандыр, чөнки без төрле уку йортларында чыгышлар ясап йөрдек. Студентлар белгәч, бөтен кеше белә, дигән сүз.

Рәшиткә Казан мех берләшмәсенең мәдәният сараенда вокаль-инструменталь ансамбль җитәкчесе урынын тәкъдим иттеләр. Репетицияләребезне шунда үткәрә идек. Концертлар алдыннан һәр көн җыелыштык. Үз-үзебезгә шундый «җәза» уйлап таптык: кем репетициягә соңга кала – кесәсеннән 5 сум чыгарып бирә. Шуңа күрә репетицияләргә соңга калмаска тырыштык.

Студент билетын тапшырганда, зур мыегымны күреп, ректор Нәҗип Җиһанов кулымны кысты да: «Үзебезнең «Песняры» да бар икән», – диде. Аннары ул безгә тагын бер кат игътибар итте, әмма бу юлы инде җитди төстә. «Сәйяр» белән без халык җырларын гына түгел, татар композиторларыннан Рөстәм Яхин, Заһит Хәбибуллин, Александр Ключарев һәм башкаларның җырларын да эшкәртеп башкардык. Шулар арасында Җиһановның сириннәр турындагы романсы да бар иде.

Оригиналда җыр уртача темпта яңгырый, сузып башкарыла. Ә без аны бөтенләй башкача – заманча итеп яздырдык. Көе сакланып калды, әмма темпы, ритмы нык үзгәрде. **«Сириннәр хуш исләр тарата» безнең башкаруда хит булып чыкты, без аны татар һәм рус телләрендә җырладык. Татарстанда гармун һәм халык биюләре генә түгел, ә сәнгатьнең башка төре дә барлыгын белсеннәр өчен, рәсми концертларда кунакларга шул җырны башкарырга кушалар иде.** Җиһановның үзенә «тотылганчы» шулай дәвам итте.

Кемдер Җиһановка: «Сәйяр» сезнең җырның астын өскә китергән, танымаслык дәрәҗәгә җиткергән», – дип әйткән. Кыскасы, көннәрдән бер көнне Рәшит Абдуллин белән мине ректор кабинетына чакырдылар.

Шулай итеп, без Рәшит белән сүзсез генә Нәҗип Гаяз улының кабинетына кердек. Сулыш алырга да куркып басып торабыз. «Сириннәр»не нишләттегез?» – дип сорады ректорыбыз. Рәшит аңлата башлады: «Вакыт алга бара, хәзер музыкада ритмнар үзгә, сезнең иҗатка мөрәҗәгать итәргә булдык», – ди. «Ләкин мин бит алай язмадым!» – дип бүлдерде аны Җиһанов.

Без композиторның нәрсә әйтергә теләгәнен аңламадык. Аннан соң ул, көтмәгәндә: «Егетләр, ә яшьләр моны кабул итәме?» – дип сорады. «Ярар, ярар. Минем музыка белән тагын нәрсәдер эшләргә җыенсагыз, баштан миңа керегез!» – дип тынычландырды.

Җиһановның тавышында бер тамчы ачу да, мактауга ишарә дә юк иде. Кыскасы, бу сөйләшүне безнең белән бер үк цехта эшләүче кешенең, хезмәттәшнең кызыксынуы буларак кабул иттек. Күпме вакыт сөйләшкәнбездер – хәтерләмим. Шунысы мөһим: «Сириннәр» дә, «Сәйяр» дә, аның җитәкчесе Рәшит Абдуллин да Җиһанов хуплавында музыкаль мәйданда эшләвен дәвам итте.

Ренат Ибраһимов та карьерасын «Сәйяр»дән башлады. Шулай ук консерватория студенты иде, бездә солист булды. Ренат белән бик дуслаштык. Соңрак та: «Теләсә кайчан шалтырат. Төнлә шалтыратсаң да сөйләшә алам, намаз укыйм, йокламыйм», – дия иде. Кызганыч, ул да китеп барды...

Төркемебез егетләре белән аралашып торабыз. Мансур Зарипов Казан авиация институтында укыды, «Сәйяр»дә җырлады, кубызда уйный иде. Министрлар Кабинетында эшләде, хәзер пенсиядә. Барабанчы Фәрит Сабирҗанов хәзер тегүче булып эшли. Гитарачы Владимир Земсков Казан авиация институтын тәмамлады. Ригада гаилә корды, хәзерге вакытта Американың Лос-Анджелес шәһәрендә яши. Җырчыбыз Альфред Камелевский хәзер «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында оператор булып эшли. Рафаэль Мәҗитов – «Казан егетләре» төркеме администраторы.

Татар музыкасы традициясендә зур мәйданнарда, стадионнарда концерт кую гадәткә кермәгән. Хәер, безгә ачык һавада, Түбән Каманың бер стадионында концерт куярга туры килде. **Концерт залларыбыз һәрчак тулы булды, һәм бу безне илһамландырды, канатландырды. Безнең йолдыз чире белән авырырга вакыт булмады.** Уңышка ирешүебез иҗат итәргә стимул гына бирде. Җырларыбызны радио студиясендә яздыра идек. Без бик дус булдык, берберебезне ярты сүздән аңлап иҗат иттек.

«Сәйяр» эшчәнлеген дәвам итсен өчен, югарыларның җитди теләктәшлек белдерүе кирәк иде, минемчә. Эш шунда: вокаль-инструменталь ансамбль аппаратурага, яңа җиһазларга, музыка уен коралларына мохтаҗ булды. Итальян, немец аппаратуралары кирәк иде безгә. Хәзер аларны табуы җиңел. Ә безнең заманда бернәрсә дә юк, уен коралларын үзебезнең акчага сатып ала идек.

«ПРОФЕССИОНАЛЬ АНСАМБЛЬ ИДЕК БЕЗ»

Рөстәм Зарипов,
композитор,
ТР атказанган сәнгать эшлеклесе

– Берара Рафаэль Мәҗитов ансамбльнең администраторы булып алды. Рафаэль чорында «Сәйяр» дан казанды. Мин дә шул чорда килеп кушылдым. Ул вакытта, болай гына, күңел кушканга уйнап йөрүчеләр күп иде. Рәшитнең алдан күрү сәләте булган, күрәсең. Ул чит илдәге төрле төркемнәрнең форматы белән танышып, бөтен йөкне үзе генә тарта алмаячагын аңлагандыр. Төркемне таныту, оештыру эшләре белән дә аерым кеше шөгыльләнергә тиеш иде: афишалар тарату, гастрольләргә йөрү, бәйгеләрдә катнашу, кунакханәләр белән сөйләшү һ.б. Ул кешенең музыкант булуы мөһим түгел. Һәм Рафаэль боларны башкарды да.

1974 ел. Беркөнне Рөстәм миңа: «Эш бар иде, бүген минем өйгә кил әле», – диде. Килеп керсәм, 5–6 кеше җыелган: башта таныштык, каһвә эчтек. Аннан соң Рәшит: «Егетләр, безгә эшчәнлегебезне дәвам итәсе иде. Зариповны клавишлыларга утыртасыбыз килә», – диде. Минем инде бу вакытка инструменталь ансамбльләрдә уйнаганым, хәтта җитәкчелек иткәнем бар иде. Уен коралында да уйныйм, аппаратураны да җайлый беләм.

Сөйләшеп, максат-ниятләр корып алганнан соң, Рәшит: «Егетләр, бүгенге датаны гомерлеккә истә калдырыгыз!» – диде. Кызганыч, истә калдырмаганбыз... Сентябрь икәнен генә хәтерлим. Шуннан соң бик җитди эш башланды. **Профессиональ ансамбль идек без. «Сәйяр»нең башкалардан аермасы да шунда: бездә бер фальшь нота да юк, бездә бернинди артык әсәр дә юк иде.**

Хәтта репертуар сайлауны да Рәшит идеаль дәрәҗәдә алып барды. Теге яки бу вакытта кайсы әсәрне башкарырга, теге яки бу бәйге, концертка кайсы әсәрне әзерләргә кирәклеген белә, тоемлый иде. Программаны һәрвакыт үзе төзеде.

Ул вакытта халык та күпкә зәвыклырак булган, дип нәтиҗә ясарга була. Алар безне үзешчән төркемнән аера иде. Безнең сәхнәдә үз-үзебезне тотышыбыз да зур роль уйнады. Без бит хәтта шуны да уйлап эшли идек: аякны кая куярга, кайда басып торырга, кайчан елмаерга – бөтенесе уйланылган, кат-кат кабатланган иде! **Республика буйлап концертлар куеп йөргәндә, тамашачы икегә бүленде: «Сәйяр» ансамблен яратучыларга һәм үлеп яратучыларга. Безне хөрмәт итмәүчеләр юк иде, яратмаучылар, бәлки, булгандыр.**

Без – кешеләр, бер урында таптанып тора алмыйбыз. Гомер буе «Сәйяр» белән йөри алмаячак идек. Һәркем үз юлын сайлады. «Сәйяр» – Рәшит Абдуллин тудырган «бала», аның казанышы. Без киткәннән соң, ул яңа кешеләрне чакырып карады, составны яңартты. Ләкин бу элекке «Сәйяр» түгел иде, ансамбль элекке уңышларга ирешә алмады.

Шулай да Рәшит Абдуллин белән концертларда күрешә идек. Һәрвакыт бер-беребезне хөрмәт иттек. Чөнки яшьлегебез бергә үткән. Юлларыбыз аерылды дип, дуслыкны болай гына өзү дөрес булмас иде. «Сәйяр» таркалганнан соң, Рәшит вокал белән шөгыльләнә башлады. Ул искиткеч баритон тембрлы тавышка ия иде. Концертларда Европа композиторлары Россини, Доницетти, Верди һәм рус композиторлары Глинка, Чайковский, Рахманинов операларыннан арияләр, романслар, халык җырларын башкарды. «Скрипка һәм оркестр өчен концерт» (1981), «Кыллы оркестр өчен музыка» (1983), Нәкый Исәнбәт әкияте буенча балалар өчен «Мырау Батыр» мюзиклы (1990) һәм 200 ләп популяр эстрада җыры авторы ул, җырларның күбесен Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев белән иҗат итте.

Рәшитнең «Сәйяре» нигә сүнеп калды, дигән темага озак уйландым. Рәшитнең үзенә дә үсеш кирәк булган, ә ул башкалардан бераз калышты. Ул вакытта профессионаллар зуррак коллективларга урнашты. Хәзер мин аңлыйм: теләктәшлек белдерәсе булган икән.

XX гасырның 60–70 нче еллары Советлар Союзында үзешчән сәнгатьнең гөрләгән чоры була. Завод-фабрикаларда, уку йортларында төрле драма түгәрәкләре һәм халык театрлары, хор һәм ансамбльләр, инструменталь коллектив һәм бию төркемнәре гөрләп эшли, үзешчәннәрнең зона смотрлары, бөтенсоюз фестивальләре даими уздырылып килә, аларга иң мәртәбәле сәхнәләрдә чыгыш ясау хокукы бирелә.


«Саз» ансамбле Румыниядә. 1977 ел.

ДӨНЬЯНЫ ШАУЛАТКАН «САЗ»

Илдар Кыямов,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

ҖЫРДАН КҮЧКӘН ИСЕМ

«Саз» хатын-кызлар халык вокаль ансамбле дә, һәвәскәрләргә күрсәткән игътибарны тоеп, шул җирлектә үсә, ныгый һәм, бүтән коллективлардан аермалы буларак, профессиональлеккә дәгъва кыла.

Бу мәшһүр ансамбльне 1968 елны «Тасма» заводы клубы каршында берничә кешелек хор нигезендә музыкант Рифкать Гомәров оештырып җибәрә. Төрле тулай торакларга бара, игъланнар элә, үзе укый торган училищедан кызларны чакыра, әллә кайсы заводларга йөреп бетә. Кызларны тыңлый, сәләтләрен тикшерә, партияләр өйрәтә. Ансамбль үсеп таныла барган саен, яңа җырчылар үзләре килә башлый. Берничә ай тир түккәннән соң, әле исеме дә уйлап табылмаган коллектив, «Тасма» заводының үзешчән сәнгать смотрында катнашып, үзенә игътибарны җәлеп итә. Заводның «Куйбышевец» дип аталган күптиражлы газетасының 1969 елның 29 апрелендәге санында мондый юлларны укырга мөмкин: «Смотрның икенче бүлеге татар вокаль ансамбле чыгышы белән ачылып китте. Ансамбль, яшь булуына карамастан, куәтләнә бара. Кызлар үзләрен сәхнәдә иркен тота, татар көйләрен, аеруча халык җырларын җанга үтәрлек җылылык белән башкара. «Син сазыңны уйнадың» җыры һәм баянчы Рифкать Гомәровның гүзәл аккомпанементы аеруча хәтердә калды». Шул җырны җырлый торгач, коллектив үзенә исем эзләү мәшәкатеннән дә котыла. Кайда гына чыгыш ясасалар да, аларны: «Әнә «Саз»лар җырлый», – дип каршылый башлыйлар.

БЕРЕНЧЕ УҢЫШЛАР

Җитәкче белән ансамбль бер-берсен тулыландырып яши. Аларны бер-берсеннән аерып карап та булмый шикелле. Инде танылган музыкант булуына карамастан, Рифкать Гомәров, Казан музыка училищесына укырга кереп, профессиональ белем ала. Ансамбль исә уңышлы чыгышларын дәвам итә. Гомәровча җитди куелган тәртип, атнасына ике репетиция (дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көнне кичке 7дән 11 гә хәтле), иренмичә «бер кадакка суга тору» күтелгән татлы җимешләрне бирә: 1969 елда «Саз» республиканың үзешчән сәнгать коллективлары ярышында беренче урын яулый, ә тагын бер елдан «Халык ансамбле» исеменә лаек була! 1971 һәм 1972 елларда ансамбль, Германиягә барып, татар моңнарын Европа тамашачысына ишеттереп кайта. Чын сәнгатьне бәяли белгән алман тама-

Фотолар Алмаз Хәмзиннең шәхси архивыннан һәм язма авторыннан алынды.

шачысы әлегәчә колагына чалынмаган моңнардан тәмам һушсыз кала. «Остзей цайтунг» немец газетасының 1972 елның 9 ноябрендәге санында чыккан рецензиягә күз салыйк: «Советлар Союзының безнең округта чыгыш ясаган халык ансамбльләре күз иярмәс биюләре, күңелле музыка һәм соклангыч җырлары белән Доберан мәдәният йортында тамашачыларны сөендерде. В.Куйбышев клубының «Саз» халык вокаль ансамблендә катнашучыларның үзешчәннәр булуын да өстәсәк, аларның казанышы тагын да югарырак бәягә лаек икәнне күрербез».

ҖЫРЛА, ГӨРЛӘ, «САЗ»!

1978 елда «Саз» ТАССР комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясенә, сәнгать җитәкчесе исә «ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исемгә лаек була.

«Комсомол җыры» конкурсында ансамбль сигез мәртәбә (!) лауреат исеменә ирешә. «Алло, мы ищем таланты!», «Товарищ песня!» конкурсларында да бөтен Союз киңлегеннән җыелган һәвәскәрләр: «Саз» катнашса, безгә беренчелек юк икән инде!» – дип әйтә торган була. Берсендә Кремльнең Съездлар сараенда чыгыш ясаганда, аларны КПСС Үзәк комитеты генераль секретаре Леонид Брежнев тыңлый. 1979 елда ансамбль «Салават күпере» халыкара телевизион фестивалендә катнаша. «Саз» турында һәм алар катнашында биш музыкаль фильм төшерелә. Алар арасында «Снежные узоры», «Звени, мой «Саз!», «Родные напевы» фильмнары Казан телевидениесе фондында саклана. Ленинград кино документалистлары Россия Федерациясенең утызга якын һәвәскәр артисты һәм коллективлары турында киң экранлы төсле музыкаль фильм төшергәндә «Саз» ансамбленә дә зур игътибар бирә.

ХӘТЕРГӘ УЕЛГАН МИЗГЕЛЛӘР

1980 нче еллардан соң, кызлар, кайсы кая эшкә урнашып, кияүгә чыгып таралыша башлый. Җәмгыять тә үзгәрү ягына борыла. Акрынлап «Саз» да яшәүдән туктый.

«Саз»ның шаулаган, гөрләгән чаклары хакында хәтта легендалар йөри! Татар ансамбль музыкасын, һәвәскәр исеме күтәргән тәкъдирдә дә кайбер профессионалларның төшенә дә кермәс дәрәҗәдә шәп итеп, тагын Болгария, Венгрия, Чехословакия тамашачысына ишеттереп кайтулар... Союзны иңгә-буйга гизеп чыгу... Мәскәү Кремленең Съездлар сараенда 7 мәртәбә чыгыш ясау, «Саз» кызлары «Ай, былбылым»ны башкаргач, Людмила Зыкинаның аларны «татарские соловушки» дип аркаларыннан сөюләре... Үзәк телевидениедә, газета-журнал битләрендә балкулар... Җәлил премиясен алган мәлләрдә урамда очраган һәр кешенең диярлек Рифкать ага белән күрешеп китүе... Ленинградның (хәзерге Санкт-Петербург) консерватория залында кызларның чыгышын аягүрә алкышлау, шул уңыштан биһуш булып, «Саз» гүзәлләренең бер-берсен кочып, илереп елаулары... Мондый канатлы-илһамлы мизгелләр Рифкать Гомәров тормышында аз булмагандыр. Ни кызганыч, үзе генә кыска гомерле була...

«Саз»ны яхшы белгән, аралашкан замандашларының «Кара Чишмә карьясе» китабына кергән кайбер истәлекләрендә дә чор сулышы, заман аһәңе, данлыклы ансамбльнең олпатлыгы тоемлана. Аларны да барлап үтик.

ЗИЛӘ ИБРАҺИМОВА,
«САЗ» АНСАМБЛЕ СОЛИСТЫ (ЯР ЧАЛЛЫ):

– Камал театры директоры булып озак еллар эшләгән Шамил Зиннур улы Закиров безне Ленинградта җырлатты. «Саз»ны шунда чакыртып алды. Ул үзе анда Н.Крупская исемендәге мәдәният институтында укый иде. Бу 1970–1973 еллар тирәсе. Ул безнең чыгышларны бик ярата, һәрчак иҗатыбыз белән кызыксына иде. Полтавцев дигән профессор белән шушы институтта очраштык. Студентлар безнең концертны нык кул чабып, гөрләтеп кабул итте. Мәскәүдә берничә кат булдык. Германиягә 2 мәртәбә барып кайттык.

ХӘМЗӘ АРСЛАНОВ,
МӘДӘНИЯТ ҺӘМ ПРОФСОЮЗ ХЕЗМӘТКӘРЕ:

– Татарстан җирендә 2 миллиард тонна нефть чыгаруга багышланган тантанада катнашу өчен мин «Саз» җыр коллективын, «Юность» халык

«Саз» төркеме «Халык ансамбле» исеменә лаек була.

«Саз» ансамбле коллективы.

бию ансамблен 1981 елда Әлмәт шәһәренә алып бардым. Юл буе Рифкать автобуста баянда уйнап, кызларны җырлатып, аларны шаяртып, уен-көлке сөйләп барды. Концерт башланып, аны алып баручы «Саз» һәм «Юность» ансамбльләренең нинди чит илләрдә (ул чагында үзешчән сәнгать коллективлары чит илгә чыгу өчен бик югары дәрәҗәгә менәргә тиеш, аннан соң да Мәскәү рөхсәте кирәк иде), СССРның кайсы төбәкләрендә булуларын, соңгы 15–20 ел дәвамында үткәрелгән үзешчәннәрнең барлык бөтенсоюз, бөтенроссия, республика, Казан шәһәре смотр-конкурслары лауреатлары, ТАССР комсомолының Муса Җәлил исемендәге бүләге ияләре икәнлекләрен, башка күпсанлы исем һәм бүләкләрен санаганда, тамашачылар тел шартлатып, башларын чайкап утырды. Алар «Саз»ның башкару осталыгына, тавышларның күплегенә, аларның гармоник яңгырашына, саф, чиста, аһәңле агышына таң калды. Сәхнәдә кызларның үзләрен нәзакәтле тотышына, Рифкатьнең тыйнаклыгына сокландылар, шул турыда үзара пышылдаштылар. Мин шуңа шаһит булдым, чөнки тамаша залында мактаулы кунаклар арасында утырдым. Концерттан соң кунакханәгә кайткач, без Рифкать белән бик озак сөйләшеп утырдык. Мин аннан: «Ни өчен ансамблең белән эшкә филармониягә күчмисең? Коллективың бит профессиональ дәрәҗәдә, танылган, тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителә», – дип сорадым. Ул бераз уйланып утырды да, кыска гына итеп җавап бирде: «Кызларның тормышларын җимерәсем, язмышларын ялгыштырасым килми», – диде.

ӘЛФИЯ ГАРИПОВА, «САЗ» АНСАМБЛЕ СОЛИСТЫ, ПЕДАГОГ:

– Рифкатьнең җырны эшләүдә, номерның режиссурасын тәгаенләүдә бер үзенчәлеге бар иде: ул беркайчан да озын җырны 2 куплеттан уздырмый. Тыңлаучы ялыкмасын! Бу очракта җырның тәэсир көче зур була, аны кабул итү хисенең куәте, сафлыгы, җитеелеге югалмый. Бертөрлелекне һай яратмады да соң. Ахры шуңадыр да, аның әсәрләрендә һәрчак яңадан-яңа борылышлар, көтелмәгән нюанслар, сөендергеч детальләр балкып куя. Ул гел эзләнде. Бу – чын оста гадәте. Үзе баянында уйный, хор яки ансамбль җырлап тора: бу артка чыга да уйнаудан туктамаган көе генә, терсәк белән төртеп, кызларны турайттыра: ягъни күкрәкне киерергә, гәүдәне төз тотарга! Сәхнә – изге урын, анда кеше матур булырга тиеш. Бу хакыйкать Рифкать өчен дә гомер бакый аксиома иде.

ФАРИС ФӘСХИ, СКУЛЬПТОР, ШАГЫЙРЬ:

– «Тасма»ның Куйбышев клубында үткән «Звени, мой «Саз»! фильмын тәкъдир итүне һич онытасым юк. И горур иде Рифкать ул көннәрдә! Алмаз Хәмзиннең атта чабуын бу фильмда дублёр буларак биюче Мәхмүт Корбанов башкарды.

«Мәхәббәтле кеше иде Рифкать, – дип сүзгә кушыла рәссамның җәмәгате Рәшидә ханым Фәсхетдинова. – Телгә оста, кыяфәт шәп, төс килгән – бөтен хатын-кыз аның алдында эреп китә торган иде».

Республикабызның музыкаль сәнгате тарихында энә шундый данлыклы «Саз» халык вокаль ансамбленең дә үз урыны бар. Мәшһүр җитәкчеләренең 1996 елда вафат булуы барлык кызларны да сискәндерә. Алар, янә җыелып, тупланып, тагын берничә ел иҗат итә. Татарстанның халык артисты Рамил Курамшин баянына кушылып моң тудыралар. Әмма бу талпыну да озакка бармый. Инде кызлар ханымнар булып җитешкән, «Саз» гөрләгән дәвердән байтак сулар аккан, байтак җилләр искән була шул...

БЕЛЕШМӘ

Рифкать Гомәров Чирмешән районы Кара Чишмә авылында 1942 елның 20 гыйнварында туа. Әтисе ул туганчы ук Бөек Ватан сугышында һәлак була, әнисе исә, бердәнбер улына җиде яшь тулып килгәндә, үпкә чиреннән үлеп китә. Әнисе ягыннан бабасы Минхәер Хөсәенов өч сугыш узган, фикерлезиһенле, җитди карт була, оныгының күңелен төшермәскә, җае чыккан саен үсендерергә омтыла. Бабай да дөнья куйгач, малайны әнисенең туганнары тәрбияләп үстерә.

1956 елда Казан музыка училищесына укырга керсә дә, ятим бала, акчасы булмау аркасында, укуын дәвам иттерә алмый, һөнәр училищесына күчә. 1959 елдан филармониядә Әлфия Афзалова, Илһам Шакировларга баянда уйный, «Идел» ансамбле составында чыгыш ясый. Бик күп иҗади сәфәрләрдә йөри.

1976 елда Казан мәдәният институтының хор дирижёрлары бүлеген тәмамлый. «Саз» ансамбле таркалганнан соң, 1986 елдан Казанның 2 нче педучилищесында (хәзер педколледж) баян, музыка дәресләре алып бара.

1996 елның 15 мартында вафат була.

Татарның танылган сәнгать әһелләреннән шактыеның иҗатка юлы «Саз» ансамбле белән бәйле. Атаклы коллективта чыныгу алган, үскән, ныгыган, танылган алар. Шундый шәхесләрнең берсе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Алмаз Хәмзин безгә үзенең «Саз» ансамбленә килү тарихы турында сөйләде.

«САЗ» ЕГЕТЕ

– Армия. 1969–1971 еллар. Алты километрлы марш-бросок ярышы. Финишка килеп җитәрәк, багана башындагы динамиктан бөтен Грузиягә татар җыры яңгырый – үзәкләрне өзәрдәй итеп. «Айныдым да, сөенеп туялмыйча, тагын сине искә төшердем», – дип кызлар җырлый. Кемнәр бу? Кайдан? Йөгереп килүдәнме, әллә татар җырының «Маяк» радиосыннан яңгыравыннанмы – йөрәк ярсып-ярсып тибә. Кая ашкынасың, йөрәгем, мине ташлап китәрдәй булып? Ниһаять, кемнәр җырлаганын әйттеләр: Казан шәһәренең кинопленка заводы каршындагы клубта оешкан «Саз» ансамбле кызлары икән. Җитәкчеләренең Гомәров Рифкать Әхәт улы булуын да мәгълүм иттеләр.

Армиядән кайттым. Менә клуб залында аларны карап утырам. Репетиция үткәрәләр. Рәхәтләнеп тыңлыйм, бер мин генә бәхетлеме дип, як-ягыма каранам. Әйе шул – үзем генә. Бер көн киләм, бер атна, бер ай чамасы киләм. Ну, җырлап та карыйлар инде! Ул «Әдрән диңгез», «Ай, былбылым», «Көймә килә...» һәм башка искиткеч җырлар, моңнар!

Шул чама йөргәч, җитәкчеләре Рифкать кызлардан сорый икән: «Бу егет кайсыгызны озатырга килеп йөри соң?» – дип. Алар, иңнәрен сикертеп, белмәгән кыяфәттә: «Ул репетиция саен кереп утыра да репетиция тәмамлангач кайтып китә. Белмибез, бәлки, җыр яратадыр?» – диләр.

Бер кичне Рифкать залга төште дә исемемне сорап:

– Син җырларга яратасыңмы әллә? – дип сүз катты. Мин ни әйтергә белми аптырап торганда:

– Әйдә, сәхнәгә мен әле, җырлап күрсәт, – диде.

– Кызлар алдындамы? – дим.

– Ә нәрсәсе бар аның? – диде Рифкать. – Оялып торма!

Мин беткән баш беткән дип, Илһам Шакировчарак итеп, «Гел елмай!» дигән җырны сузып җибәрдем. Икенче куплетны белми идем, шуңа туктадым да белмәгәнемне әйттем.

Рифкать шунда:

– Иртәгә җитен комбинатында концертыбыз, калган куплетларны өйрәнеп кил, җырларсың, – диде.

Беләсезме, өч тапкыр чакырып чыгарып кабатлаттылар! Ул алкышларны күрсәгез! Менә шуннан соң, 13 ел буе атаклы «Саз» ансамбле солисты булып йөрергә насыйп булды! Бәхет дими, нәрсә дисең инде моны!

ТАТАРСКИЙ ОБЛАСТНОЙ КОМИТЕТ ВЛКСМ
ТАТАРСКИЙ ОБЛАСТНОЙ СОВЕТ ПРОФСОЮЗОВ
МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ ТАССР

Присваивается звание Лауреата республиканского фестиваля художественной самодеятельности, посвященного XI Всемирному фестивалю молодежи и студентов на Кубе, 60-летию Ленинского комсомола Алмазу Хамзину – солисту вокально-инструментального ансамбля „Саз"

Председатель жюри –

ТАТАРСТАНДА РОК ЯРАТУЧЫЛАР ӨЧЕН ОНЛАЙН-БӘЙРӘМ

Быел 25 яшен каршылаган «Волга-Волга» ВИА ел азагында гастрольләр белән бөтен Россияне диярлек йөреп чыкты. Ә әлеге юбилей туры Казанда «Волга-Волга» студиясендә кечкенә генә онлайн-концерт белән башланып китте. Бәйрәмдә төркемнең сәнгать җитәкчесе һәм алыштыргысыз солисты Антон Салакаев Татарстанның төрле буынга караган атаклы музыкаль төркемнәрне чакырган иде. Вакыт ягы чикләнмәсә, алар шактый күбрәк булыр иде, дип билгеләп үтте ул.

Ә «КуЛай» төркеме солисты Эдуард Фазылҗановның «Рок-н-роллда пенсия яше юк!» дигән сүзләре бу очрашуның девизына әйләнде. Бу шигарь төрле буын татарстанлылар өчен яңгыраган җырларны туплады. Үз тарихында җирле вокаль-инструменталь ансамбльләрнең бөтенесен дә күргән «Татарстан» журналы, әлбәттә инде, мондый вакыйганы күрмәмешкә салышып узып китә алмады һәм аның үзәгендә кайнады. Музыкантлар җырлап кына калмады, редакция сорауларына җавап бирә-бирә, журнал укучыларына үз иҗатлары турында да сөйләде.

1 **Сезнең төркем ничек һәм кайда барлыкка килде?**

2 Нәрсә турында җырладыгыз һәм җырлыйсыз?

3 **Тирә-яктагы нинди вакыйгалар иҗатыгызга йогынты ясады?**

4 Татарстан рок-музыкасы нинди ул?

5 **Сез нәрсә турында хыялланасыз?**

ДОМ
КУКОЛ
#Красота будет вокруг меня
ДОМ
КУКОЛ
#Красота будет вокруг меня
ДОМ
КУКОЛ
#Красота будет вокруг меня

«ДОМ КУКОЛ» ТӨРКЕМЕ:

– ИҖАТТА ГРАФИК ЯКИ ПЛАН ДИГӘН НӘРСӘ ЮК

1

– Төркемебез Казанда оешты, – ди Олег Бурилов. – **Башта идея туды, аннары үзеннән-үзе бөтереп алып кереп китте**.

2

– **Өлкәнәя барган саен, репертуар да үзгәреп, тагын да мәгънәлерәк була бара.** Гомумән алганда, җырларыбыз стиль ягыннан да, мәгънә ягыннан да шактый төрле – мәхәббәт, тормыш, хис-кичерешләр, үзара мөнәсәбәтләр, мистика турында, хәтта абстракт һәм фантастик сюжетлылары да бар.

3

– **Без һәрвакыт хис-кичерешләребез турында җырлыйбыз.** Иҗатта график яки план дигән нәрсә юк, ничек килеп чыга, шулай килеп чыга. Иң мөһиме: без принципиаль рәвештә «сату өчен» җырлар язмыйбыз һәм эшләмибез, бернәрсәгә дә бәйле, беркем каршында да бурычлы түгел.

4

– **Татарстан музыкасы шактый үзенчәлекле, мин аны игелекле, якты, дип әйтер идем төшенкелек рухында түгел ул.** 2000 нче елларда аның күтәрелеше булды, аннары сүлпәнәю күзәтелде, хәзер исә кабат үсеш чорыдыр дип уйлыйм.

5

– **Музыка аны тыңлаучыларга шатлык китерсен иде дип хыялланам.**

«КуЛай» ТӨРКЕМЕ:

– МУЗЫКА – СПОРТ ТҮГЕЛ УЛ, ИҢ БЕРЕНЧЕ БУЛЫРГА КИРӘКМИ, БАШКАЛАРГА ОХШАМАУ ЗАРУР

1 – Безнең төркем 1991–1992 елларда... Казан энергетика институтында оешты, – дип сөйли Эдуард Фазылҗанов. – Бу состав 1997 елга кадәр эшләде. Концертлар белән йөрдек, Земфира, «АукцЫон» белән таныштык. **Төркем башта «КуКуКиКиЛай» дип атала иде. Хәзерге вакытта без бишәү – «КуЛай» төркеме менә шул инде.** Без атнага бер тапкыр очрашабыз, бу бер хобби кебек.

2 – Хәзер романтикага, Жанна Агузарова стилендәге җырларга тартыла башладык. **Гомумән, барлык шигырьләребез кәефкә бәйле, баштан кичкәннәр, хис-тойгыларыбыз турында алар.** «Ела» дип исемләнгән соңгы җырыбыз, мәсәлән, гаилә турында.

3 – **Безгә кораб бортының теге ягындагы вакыйгалар түгел, аның эчендәге хәлләр йогынты ясый.**

4 – Татарстанның хәзерге рок-музыкасын бераз аңлап бетермим. Ул ниндидер стандартлыга әйләнде. **Иҗатта төп принцип – бөтен кеше кебек эшләмәскә кирәк. Бу спорт түгел, монда иң беренче булырга кирәк түгел, башкаларга охшамау зарур.** Мин яшьләргә оригинальрәк булырга киңәш итәр идем.

5 – **Иҗатымны аңлый торган кешеләр күбрәк булсын иде дип хыялланам.**

ВОЛГА-ВОЛГА
СТУДИЯ
CRAFTER

«ВОЛГА-ВОЛГА» ТӨРКЕМЕ:

– БЕЗ ТАМАШАЧЫ, КЫЗЛАР ӨЧЕН ИҖАТ ИТӘБЕЗ

1

– Музыка укытучыбыз безне гитара тугәрәгенә җыя иде, мин шунда эләктем дә, – дип искә ала Антон Салакаев. – Бу 80 нче еллар ахыры – 90 нчы еллар башы иде. **Бер репетиция вакытында югары сыйныфтагыларның мәктәп ансамблен тыңладым һәм үз төркемемне булдыру идеясе белән янып йөри башладым.** Коллективның беренче составы тулысынча дуслардан торды. Берәү дә бернәрсәдә дә уйный белми, гитара, бас-гитара, барабан серләренә үзебез төшендек. Акрынлап состав үзгәрде, һәм без профессиональ музыкантларны чакыра башладык.

2

– **Без һәрвакыт мәхәббәт турында җырладык. 8–9 нчы сыйныфларда укучы малайлар тагын нәрсә турында җырлый алсын инде?** Репетицияләрдә очрашып, ул чорның танылган рок-коллективлары («Аквариум», «ДДТ», «АукцЫон») турында фикер алышканда, аларның иҗатында мәхәббәттән тыш, социаль протест, бәйсезлек кебек башка темалар да барлыгын аңлый идек. Без дә андый җырларга алынып карадык... Ләкин, гомумән алганда, егетләр ни өчен оештыра соң ул төркемнәрне? Әлбәттә, кызлар һәм мәхәббәт дип.

3

– Әгәр дә кеше җыр яза икән, бу еш кына бик көчле тетрәнүләр вакытында була. Беренчесе – мәхәббәт. Үсә төшкәч, син ил, дуслар тормышының йогынтысын күбрәк тоя башлыйсың. **Иҗат кешесе өчен бу тетрәнүләр һәрвакыт хәлиткеч әһәмияткә ия, һәм алар иҗатта чагылыш тапмый кала алмый.**

4

– **Советлар Союзыныкы, Россиянеке һәм чит илнеке кебек ук.** Кемдер безне нindидер югарылыкка ирешә алырлык түгел дип саный, янәсе, әнә кайдадыр Ленинградта яки Екатеринбургта шундый-шундый төркемнәр бар иде, ә бездә мондый гына. Уңыш факторы дигән нәрсә, шулай ук теге яки бу төбәктә яшәүче халыкның менталитеты бар. Бездә 70 нче еллар башыннан шәп төркемнәр («ЗМЧ», «Поролон») оешты һәм аларның һәркайсы «Наутилус Помпилиус» һәм «Аквариум» дәрәҗәсендә була алыр иде, тик кайдадыр ни дә булса килеп чыкмады. Күпчелек шәһәрләрнең үз рок-клублары һәм рок-лабораторияләре эшләп торды, бу, әлбәттә, бөтен илгә танылырга ярдәм итә иде. **Шулай да Казанда туган коллективлар шактый яхшы дәрәҗәгә ирешеп килде**.

5

– Без тамашачы, кызлар өчен иҗат итәбез. **Җырларыбызны мөмкин кадәр күбрәк кеше белсен, аларны тыңласын һәм концертларга килсен иде, дип хыялланабыз.** Моннан тыш, «Волга-Волга»ның концертлардан кала да проектлары шактый: үз фестивалебез, дисеңме, яшь төркемнәр белән продюсерлык эше, музыка студиясе, альбомнар, саундтреклар язу, кино төшерү, дисеңме – планнарыбыз бер елга алдан язып куелган.

Ирек Уразаев җитәкләгән Бигеш балалар йортында уку алдынгыларына багышланган пионер сборы. 1966 ел.


Көнчыгыш Оренбургның металлургия гиганты тарихы нәкъ менә 1 нче домна мичен эшләтеп җибәрүдән башлана.

Фото: Алексей Клок, Инесса Белованың шәхси архивыннан.

Аклы-каралы фотодан грек алиһәләре – студент-спортчы-комсомол кызлар карап тора. Бишенче номерлысы – сары чәчле чибәркәй Инесса.

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп, бу буын кешеләре алга атлаган, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылган. Алар юллар төзегән, күперләр сузган, электростанцияләр, заводлар салган, яу кырларында ватанны саклаган, сугыштан соңгы хәрабәләрне, җимерекләрне күтәргән.

«Татарстан», үзенең каһарман якташлары белән очрашып, сезне әлеге фидакарь буынның маҗаралар тулы тормыш юлы белән таныштыруны дәвам итә.

Моннан алдагы тарихларны басмабызның 10,11 нче саннарында укый аласыз.

7 НЧЕ ТАРИХ

Ирек Уразаев ничек балалар йорты директоры булган.

8 НЧЕ ТАРИХ

Инесса Белова баскетболда ничек үзенең язмышын тапкан.

9 НЧЫ ТАРИХ

Ни өчен Фәрит Гайнуллин үз тормышы белән горурлана.

7 НЧЕ ТАРИХ

ЗАТЛЫ НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫСЫ

– Иртәнге алтыда тордым, сезне көтәм. Инде борчыла башлаган идем, Казан белән Чаллы якын юл түгел бит, – дип каршы алды безне Ирек Уразаев. Кул биреп күрешкәч тә, беренче килгән уй: «Чәчен буяган, ахры...»

Хәер, кара чәче генә түгел, көр тавышы, солдат кебек төз гәүдәсе дә игътибарны җәлеп итте. Ирек абыйга 91 яшь икәнен алдан белмәсәм, аңа җитмештән дә артыкны бирмәс идем. РСФСРның атказанган укытучысы Ирек Уразаевның узган юлы турында китап язарлык.

«БӘХИЛ БУЛЫГЫЗ...»

Һәм ул китап язылган да. «Үткән гомер: хәтердә калганнар» исемле китабын укыганда күздән яшь кипмәде. Өстәвенә, матур тел белән язылган – әдәби әсәр укыган кебек, аерым урыннары бигрәк тә күңелгә үтеп керде.

Ирек Уразаев укытучы гаиләсендә туа. Бабалары да морзалар, муллалар нәселеннән. Аның архивында хәтта 19 нчы гасыр азагында төшкән сурәт тә саклана. Анда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре җыелган, араларында Ирек абыйның бабасы да бар...

Әтисе Таһир мөгаллим Актаныш районының төрле авылларында балалар укыта. Аның белән бергә гаиләсе дә күчеп йөргән. Ирек абый исә Усы авылында дөньяга килә. Аннан гаилә Чишмәбаш авылына күченә. Беренче сыйныфка укырга шунда бара.

– Безнең өйдә һәрвакыт китаплар күп булды, – дип искә алды балачагын укытучы. – Бик иртә укырга, язарга өйрәндем. Әтинең, укымышлы кеше буларак, үз фикере, кыйбласы булды. Сугыш башлангач безнең өйдә радио бар иде. Шуннан җырлар тыңлап, кич утыра идек. Безнең нәселдә барысы да җырчы. Сугышта һәлак булган Рөстәм абыйга 1941 елны хәтта җырлаган өчен штраф салдылар. Ул чорда бит, дошман күрмәсен өчен, кичен ут та кабызмадык. Әтәчләрне суеп, этләрне атып бетердек. Абый кич белән эштән кайтканда урамнан җырлап узган. Шул вакытта авыл

кешеләре тиешле органга барып, абыйны әләкләгән...

Сугыш башланганда Ирек абыйга ун яшь була. Тарихтан белгәнебезчә, авылда ирләр калмау сәбәпле, бөтен физик эшне ул чорда үсмерләр белән хатын-кызлар тарта. Үгез җигеп кырда ашлык сугу, чүмәлә тарттырулар... Чандыр гәүдәле Ирек әнә шулай үсә. Шуның өстенә этисезлек, ачлык... Сугыш елларының фаҗигасен Ирек Уразаев «Үткән гомер: хәтердә калганнар» китабында болай тасвирлый:

«Авыл укытучысы булгач, этигә сугыштан азат ителүен раслап бронь бирәләр. Ләкин авылның бөтен ир-аты фронтка китеп беткәч, Таһир мөгаллим үзе, хәрби комиссариатка барып, сугышка җибәрүләрен сорый. Хәрби комиссариатка шул гозер белән өч тапкыр бара ул...

1942 елның март аенда эти район үзәгеннән кулына повестка тотып кайтты. Иртәгәсен иртүк, кешеләр җыелышканчы, күрше егете Әдиф абый, ат җигеп, этине Камбарга станциясенә кадәр илтә китте. Этине озату хәзер дә күңелдә: «Җылашмагыз, исән-имин яшәгез, җиңеп кайтырбыз», – диде. Тиз генә саубуллашып, әнине һәм сигез баласын калдырып китеп барды һәм кире әйләнеп кайтмады.

Шул ук елның августында бертуганым Рөстәм абыйга 18 яшь тулгач, аның берүзен авыл капкасына кадәр озата бардык. Аерылышканда Рөстәм абый: «Бәхил булыгыз, безгә әйләнеп кайтулар насыйп булмас инде», – диде. Күңеле сизгәндер – шул ук елны Калинин фронтында, Ржев-Вязьма тирәләрендә сугыша һәм геройларча һәлак була.

...1945 елның 9 мае. Безне мәктәп ишегалдына тезеп, районнан җибәрелгән капитан Жуков исемле кеше көр тавышы белән: «Сугыш бетте, без җиңдек!» – дип белдерде. Кемнәрдер шатлыктан елап та алгандыр инде, хәтердә түгел. Без, бер төркем 7 класс малайлары, Ахун янындагы яланга җуа ашарга киттек. Сугыштан исән кайтасы кешеләребез юк, өйгә дә ашыкмыйбыз, шатланып утырырлык сәбәп таба алмадык...»

«МАКСАТКА ТАБА...»

Сугыш тәмамланганнан соң, 1946 елда, егет булып җитешкән Ирек Минзәләгә – педагогика училищесына укырга барырга була. Алар күрше кызы белән икәүләп 60 чакрым араны җәяүләп уза. Нәтиҗәдә, керү имтиханнарын уңышлы тапшырып, студент булу бәхетенә ирешәләр. Тик ике ай укыганнан соң, егет укуын ташлый.

– Ачлы-туклы йөреп, ябыгып беттем, – дип искә алды ул чорны Ирек абый. – Октябрь бәйрәменә авылга кайткач, яңадан бармаска булдым. Әни каршы килмәде. Өйдә сыер асрагач, бәрәңге утырткач, яшәргә була әле. Тик ач-ялангач укып булмый – шуны аңладым.

Шул вакыттан егетнең чын хезмәт чоры башлана. Байсар хастаханәсенә дезинфектор булып эшкә урнаша. Баш табибны йөртер өчен кучер хезмәтен дә үти, кырда да эшли. Тагын хастаханәне җылыту өчен утын кисү, тегермәндә он тартулар... Тамак хакына дип әнә шулай йөри. Тик егетнең күңелендә гел уку була. Өйгә кайткач та, китаптан аерылмый ул. Нәтиҗәдә, 1948 елны янә Минзәлә педагогика училищесына китә. Монысында егет чигенми – максатына туры бара. Әйе, тамак ягы һаман да такы-токы, өс-баш та мактанырлык түгел. Тик теге чактан аермалы буларак, Ирек Уразаев аңлый: ул ничек тә укырга, ата-бабасының һөнәрен дәвам итәргә тиеш.

– Ике катлы тулай торакның беренче катында яшәдек, – ди Ирек абый. – Бер бүлмәдә дүртәү – мин, Алмаз, Әслах, Марсель. Ә хәллерәк гаиләдән булган балалар фатирда акча түләп торды. Аларның ашаулары да бүтән – итле шулпа пешерәләр. Ә безгә мичтә пешкән бәрәңге дә ярады. Аның каравы бик тырышып, яхшы укыдык. Бүлмәдәшләрдән беребез дә югалып калмадык – кайсы укытучы, кайсы директор булып эшләде. Россиянең, Татарстанның атказанган укытучысы исемнәренә лаек булдылар.

1951 елның мартында педучилищеның Актлар залына 25 егетне җыялар. Арада фельдшерлык мәктәбе, авыл хуҗалыгы техникумы егетләре дә була. Баксаң, яхшы

Фото: Юлия Кузнецова

Уразаевлар гаиләсе.

укыган, физик яктан әзерлекле егетләрдән радиомеханиклар төркеме җыярга ниятләгәннәр икән. Алар шушы исемлектә. Әлбәттә, башта өйрәнү узарга кирәк, анда инде хәрбиләр кемнең туры килү-килмәвен үзләре карый...

Әзерлек курсларын узу өчен егетләрне Көнбатыш Украинага җибәрәләр. Сүзне озынга сузмыйча шуны әйтим: Ирек Уразаев теория һәм практика буенча имтиханнарның барысын да «5»легә тапшыра. «Механик по радиооборудованию самолетов» белгечлеге буенча таныклык ала. Иң гаҗәбе – теге 25 егет арасыннан ул моңа берүзе ирешә. Өлкән сержант исемен алып, Мәскәү янындагы Кубинка шәһәренә китә. Озакламый аны 3 нче эскадрильяның баш радиомеханигы итеп билгелиләр.

– Штаб командирыбыз КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы әгъзасы Анастас Микоянның улы Алексей Микоян иде, – дип дәвам итте Ирек абый. – Ягымлы, ниндидер затлылык, зыялылык сизелеп тора иде үзеннән. Хәрби хезмәт дәверендә нинди генә атаклы кешеләр белән очрашмадык. Чын тормыш мәктәбен уздым анда. Һәм 1955 елның октябрендә, солдат хезмәтен тутырып, туган якка юл тоттым.

ЯТИМ БАЛАЛАР ӘТИСЕ...

Мәктәптә эшләү тәҗрибәсе алган Ирек Уразаевны 1963 елда Зәй районының Бигеш балалар йортына директор итеп куялар. Юк, алай дип әйтү генә дөрес түгел – аны үзе ача. Ул чактагы ТАССРның мәгариф министры Мирза Мәхмүтов яшь мөгаллимне бу урынга үзе кодалый. Яңа салынган өч катлы бинага җан өрү өчен яхшы җитәкче кирәк була.

Әнә шулай итеп республиканың бердәнбер татар балалар йорты төрле районнардан 150 баланы кабул итә. Зурлыгы ягыннан Россиядә мондый урыннар берничә генә була.

– Балаларны хезмәт тәрбиясе белән үстердек, – ди Ирек Таһирович. – 15 гектар җир, ике ат, ун дуңгыз – барысын да тәрбиячеләр белән балалар карады. Үндүрт ел эчендә балаларга бер тапкыр да дуңгыз ите ашатмадык. Без аларны симертеп сата идек. Бер елны шул акчага Ленинградтан тынлы музыка уен кораллары кайтарттык. Зәй мәдәният йортыннан килеп балаларны шуларда уйнарга өйрәттеләр. Шөкер, тәртипле булды балаларыбыз, үндүрт ел эшләү дәверендә бер генә балабыз да колониягә, милициягә озатылмады. Коллективыбыз бер дигән иде, монда аларның хезмәте әйтеп бетергесез.

Ирек Уразаев Бигеш балалар йортын 1977 елга кадәр җитәкли. Аннары үз теләге белән Чаллыга күченә. Иң кызганычы, ул киткәннән соң балалар йорты ике генә ел эшли, ишегенә йозак элenә, ә балаларны Казандагы 10 нчы интернат-мәктәпкә озаталар...

Үндүрт ел гомерен Бигеш балалар йортына биргән Ирек абыйларын биредә тәрбияләнгән малай-кызлар гомерләре буе онытмый яши. Инде алар бүген үзләре әби-бабай, ләкин яраткан Ирек абыйларын игътибарсыз калдырмыйлар. Шалтыраталар, килеп хәлен беләләр, очрашулар уздыралар. Хәер, Ирек абый үзе дә аларны телдән төшерми. Нинди генә темага кереп китсәк тә, сүз һаман Бигеш балалар йортына кайтып кала...

ЯҢА ТОРМЫШ

Ни өчен Бигешне калдырып киткән? Ирек Таһировичка бу сорауны күпләр бирә. Халык мәгарифе отличнигы әлеге сорауга төгәл генә җавап бирә алмый. Улы Рамил 10 нчы классны тәмамлап, Казанга укырга китә. Ә кызлары Резидә беренче сыйныфка барырга әзерләнә. Авылда төпләнеп калсалар, балаларны күрергә интизар булырбыз дип тә уйлый ата-ана. Аннары Ирек Таһирович һәр нәрсәнең чиге бар дигән карарга килә. Гел бер урында эшләү, кайсыдыр этапка җиткәч, кешене үсүдән туктата. Ә энергиясе ташып торган мөгаллимнең үзен башка җирдә дә сыныйсы килә.

Тиздән андый форсат чыга – тәҗрибәле директорга Чаллының Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче татар-рус мәктәбен җитәкләргә тәкъдим итәләр. Зур мәктәп –

1650 укучы. Ирек Таһирович яңа урында җиң сызганып эшкә керешә. Нәтиҗәдә мәктәпнең исеме бөтен җирдә яңгырый башлый. Республика күләмендәге фәнни-гамәли конференцияләр биредә уза. Районнан килгән мәгариф җитәкчеләре гел монда була, Татарстанның төрле мәктәпләре исә тәҗрибә уртаклашырга килә. Алай гына да түгел, 1984 елда 2 нче мәктәпне тулысынча татар мәктәбенә әйләндерүгә ирешә ул! Барлык фәннәрне ана телендә укыта башлыйлар. Шуның белән ата-бабалардан калган тәрбияне алга сөрүне максат итеп куя.

– Шул юнәлештә уңышлы гына эшли башлаган идек, хыялларыбыз чәлпәрәмә килде, – дип искә алды ул көннәрне Ирек Таһирович. – Шәһәрдәге илле рус мәктәбе арасыннан бер безнең татар мәктәбенең бинасын тартып алдылар. Аны Волгоград физкультура институтының Чаллы филиалына бирделәр. Ә безнең татар мәктәбен 44 нче рус мәктәбенең бер почмагына урнаштырдылар. Бу хәбәр миңа аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте. Шулкадәр явызлыкны үзебезнең манкорт татар җитәкчеләре генә эшләде!

Ирек Таһирович ул мәктәпкә барудан баш тарта һәм үз теләге белән директорлыктан китә. Әлбәттә, тәҗрибәле җитәкче өйдә утырмый. Орловка бистәсендә урнашкан акылга зәгыйфь балалар интернат-мәктәбе, Чаллының 54 нче татар гимназиясе, 4 нче мәктәбе... Җитмеш яшенә кадәр балаларга белем, тәрбия бирә ул. Лаеклы ялга чыкканнан соң, яраткан җәмәгате – Розалиясе белән бер-берсе өчен яши башлыйлар. Ни аяныч, узган ел шушы бәхет кителгән: Розалия апа кисәк кенә бакыйлыкка күчкән. Бүген Ирек абый ялгызы гомер итә. Хәер, якында гына яшәүче кызы Резидә килеп тора, улы Рамил дә эзне суытмый, балалар йортында тәрбияләнүчеләр һәрвакыт хәл белешеп тора.

– Ирек абый, сез бүген дә хатын-кызлар күзе төшәрлек ир-ат. Яшь чагында хатын-кызлар сезгә еш гашыйк була идеме? – дигән идем гаилә архивын караганда. Тугыз дистәсен тутырган ир, һич уйлап тормыйча:

– Розалиядән башка берәүгә дә өйләнеп карамадым. Алай гына түгел, хезмәттәшләремә дә еш киңәш бирә идем: «Хыянәт ул – юлдан яздыра, аның азагы хәерле булмый». Бүген дә шул фикердә торам. Розалия күп еллар балаларга белем бирде. Җаны-тәне белән эшенә бирелгән мөгаллимә иде. Аның белән гомер уза алуыма чиксез бәхетлемен. Гомумән, тормышымда начар кешеләргә караганда яхшылары күбрәк очрады. Моның өчен күкләргә мең рәхмәтлемен...

...Бик кызганыч, лаеклы ялгач киткәч күпләрне оныталар. Юк, бу кеше эшендә начар хезмәт куйган дигән сүз түгел. Вакыт юклык, бүтән сәбәп... Ә менә Чаллының мактаулы гражданины исемен йөртүче Ирек Таһирович Уразаев бүген дә игътибар үзәгендә. Коллегалары,ә иң мөһиме үзе укыткан, тәрбияләгән балалары аны бер көн дә истән чыгармый: хәлен белеп шалтыратталар, киләләр. Бу шәхес белән очрашкан һәркем Ирек абыйны тирән хөрмәт, ярату белән искә ала. Әйе, бөтен кешегә мондый бәхет тәтеми. Ирек Таһирович әнә шундый сирәк бәхетлеләрнең берсе.

ИРЕК УРАЗАЕВНЫҢ «ҮТКӘН ГОМЕР: ХӘТЕРДӘ КАЛГАННАР» КИТАБЫННАН:

«Балалар йортындагы кайбер малай-кызларны якын туганнары кунакка алып китә иде. Тиешле справкаларны тикшергәч, 15–20 көнгә биреп җибәрә идем. Берсендә Рафаэль исемле бер малаем әбиләреннән үзе белән иптәшен ияртеп килгән. Фамилиясе Хәсәнов (кызганыч, исемен хәтерләмим). Шулкадәр ябык, кечкенә, начар киенгән – карарга да кызганыч. Үзе белән бер документы да юк. Алып калдым инде. Районнарына, авыл советына шалтыратып, хатлар җыйдым. Мәгариф министрлыгына барып, безнең балалар йортына юллама алдым.

Ике ай чамасы узгач, Хәсәнов югалды. Сәяхәткә чыгып киткән – Мәскәүдән шалтыраттылар, детприемникка эләккән. Ике-өч көн үтмәгәндер, Волгоградтан шалтыраттылар. Шөкер, безгә аны үзләре китереп тапшырдылар. Җиңел сулап куйдым.

Баланы ачуланып торуның файдасы юк иде, бик дустанә сөйләштек. Күлмәк эченә яшеренгән СССР картасын чыгарып күрсәтте ул миңа. Илебезнең әллә нинди шәһәрләрен, үзе ишетеп белгән тарихи урыннарны күрәсе килгән аның. Мәскәүдә Кызыл мәйданны карап йөргән, мавзолейда Ленин бабай янында булган. Шунда эләктереп алганнар, сукбай балалар тәрбияләнә торган приемникка озатканнар. Кухняга бәрәңге әрчергә җибәргәч, форточкадан чыгып качкан. Шуннан тимер юл вокзалын эзләп табып, Волгоград поездына утырып киткән. Мамай курганын карыйсы килгән...

Еллар үтте. Мин инде Чаллыга күченеп килгән идем. Берзаман, төнге сәгать берләрдә, ишектә кыңгырау. Ачып җибәрсәм, матрос киемендә бер егет басып тора – Хәсәнов! Ерак туганнарына килгән икән. Рәхмәт төшкере, минем хәлне дә белергә булган... «Мин матрос дальнего плавания. Кубадан кайттым, башка чит илләргә дә сәяхәт итәм», – диде ул».

8 НЧЕ ТАРИХ

«ДИНАМО»ДАН 10 ЯШЬКӘ ЯШЬ

Аклы-каралы фотодан грек алиһәләре – студент-спортчы-комсомол кызлар карап тора. Бишенче номерлысы – сары чәчле чибәркәй Инесса. Шул чакта, Мәскәү университетында укыган 1950 нче елларда, кыз үзенең язмышын баскетбол белән бәйли, гомерлек мәхәббәтен дә очрата.

Инессага өч яшь. Ул, баш астына этисенең портфелен салып, костел баскычында йоклап ята, үзен эзләп тапкан эти-энисенең сөенүен әле ишетми. Кыз иртән алып чыгып киткән портфельдә исә – мөһим документлар. Инессаның этисенең эше куркынычсызлык хезмәте белән бәйле. Аның эше буенча гаилә вакытлыча Бобруйск шәһәрендә яши, Инесса да шунда туа. Аларның ишегалдындагы бөтен бала да мәктәпкә йөри, шуңа Инессаның да укырга барасы килә. Шунлыктан ул иртән, шыпырт кына этисенең портфелен алып, мәктәпкә юнәлә. Әмма мәктәп укучыларыннан артта калып, озак кына уйнап йөри, аннары костел янында ял итеп алырга була. Чиркәү болдырында йоклаганда, үзенең зур, акыллы һәм көчле булып үсәчәге төшенә керә. Шулай булып чыга да.

Инессага сигез яшь. Җәй көнне әбисенә кунакка кайткан, тик алар хәзер барысы бергә Идрица бистәсендәге агач йортлары янында землянка казыйлар. 1941 елның 23 июне бу. Немецлар Идрицага килеп җитмәс, диләр. Әмма әбисе көн саен: «Совет властена ышанма», – дип кабатлый. Бер айдан чыннан да бистәне дошман басып ала. Ул вакытка инде әбисе Инессаны өенә – Мәскәүгә кайтарып җибәрәчәк. Сугыш чоры шәһәренә кайтып төшкән җәйге кичне кыз бик озакка хәтеренә сеңдерәчәк. Талчыккан энисенең кайтуын көтеп, хәрби шәһәрчектәге йортлары баскычында аңа берничә сәгать утырырга туры килә, чөнки бөтен хатын-кызлар диярлек көне буе окоп казуда. Немецлар инде шәһәргә бик якын була.

Инессага тугыз яшь. Әнисе елый, аңа карап, Инессаның игезәк сеңелкәшләре дә елый. Әле генә «кара кәгазь» китергәннәр. Этиләре, ерак авиация полкларыннан берсенең штаб башлыгы подполковник Григорий

Филимонов, 30 полкташы белән бергә, Тверь янындагы авиаһәлакәттә фаҗигале төстә һәлак булган. Идел ярындагы чирәм каплаган туганнар каберлеген Инесса дистәләрчә еллар үткәч эзләп табачак әле.

Инессага 16 яшь. Ул документларын Мәскәү китапханә институтына тапшырырга бара. Ә кая булсын тагын? Инессаның иң яраткан шөгыле китап уку бит. Хәрби шәһәрчектәге фатирларында аларга кадәр яшәүчеләрдән гаять зур китапханә кала. Гёте, Шиллер, Шекспир, Пушкин, Толстой, Достоевский – бу зур-зур томнарны Инесса йотлыгып укып чыккан инде, китап дөньясы – аныкы.

– Сәлам, Инесса! Кая барасың? – дип туктата кызны сыйныфташы. Инесса аңлата.

– Син нәрсә, акылдан яздыңмы әллә! Синең бит алтын медаль, минеке дә, безне МДУга имтихансыз алачаклар. Әйдә икәү бергә керәбез! – дип, сыйныфташ кызы Инессаны сөйрәп диярлек үзе белән алып китә. Кабул итү комиссиясендә Инессага карап аптыраштa калалар: алар сайлаган юридик факультетка 18 яшьтән генә алалар бит. Кыз нәүмизләнеп елый башлый. Әтием һәлак булды, дип аңлата ул, тизрәк укып чыгарга да эшли башларга, гаиләгә ярдәм итәргә кирәк. Инессаның документларын кабул итәләр.

Инессага 17 яшь. Аның курсташлары – барысы да бик талантлы яшьләр. 1932–1933 елларда туганнар аеруча сәләтле, диләр. Алар курсында киләчәктә дәүләт куркынычсызлыгы хезмәткәрләре, дипломат, сәясәтче булачак егет-кызлар укый. Араларында – бик җитди егет Миша Горбачев. Ул башкалардан берничә яшькә өлкәнрәк, аның инде дәүләт ордены да бар. Көннәрдән бер көнне кызны өлкән курс студентлары туктата.

– Синең буең күпме? Метр җитмеш? Озын буйлы син, безгә шундыйлар кирәк! Баскетбол секциясенә кил, – диләр алар Инессага. Кызны спорт белән шөгыльләнү уе билэп ала. Спорт бирәчәк энергия һәм көч үзенә тарта. Ул ишегалдында уйнауларын һәм шул вакытта иң җитез һәм тиз булуының үзенә бик ошавын исенә төшерә. Инесса тренировкага килә. Һәм тиз арада хатын-кызларның университет җыелма командасы составында пәйда була. Югарыда аталган фотосурәт тә шул вакытта төшелгән.

Инессага 21 яшь. Ул – командада иң шәп һөҗүмче, мәйданчык принцессасы. Баскетбол – аның тормышы. Һәр уенда җанатарлар тулы зал җыела. Һәр көн саен спортчыларга ресторанда ашау өчен талон бирәләр. Инесса матур көлмәкләр кия, ирегетләр аңа сокланып карый. Курсташлары күптән кияүдә инде, әмма кызны бу куркытмый. Ул бары тик уйнарга гына тели.

– Менә ыргытты ичмаса! Беләсеңме аны? Володя Белов ул, химик, тик беркем белән дә очрашмый, мөгаен, өйләнгәндер, – дип сокланып пышылдый дус кызы. Ул Инессадан үзен университетның ирләр командасы тренировкасына алып килүен үтенгән була. Баскетбол үлчәмнәре буенча әллә ни озын буйлы булмаган Володя, гаять зур осталык һәм җитезлек күрсәтеп, тупны нәкъ кирәкле урынга чөя. Инесса белән Володяның күзләре очраша.

Инессага 22 яшь. Һәр якшәмбедәгечә, бүген дә Володя Казанда яшәүче әтиәнисенә шалтырата. Әтисе – куркынычсызлык хезмәте органнары хезмәткәре, әнисе – ниндидер һөнәри берлекнең өлкә комитеты рәисе. Егет МДУда укый, университетны тәмамлагач, ул яңа яшерен корал сыналачак ерак полигонга китәчәк. Гаилә дусларының кызы да аның белән китәргә әзер – Беловлар аны күптән инде улларының кәләше дип саный. Володя телефоннан әти-әнисенә укудагы яңалыклар турында сөйли, аларның сәламәтлеге, хәлләре белән кызыксына.

– Сезнең вакытыгыз бетте, – ди телефончы кыз. – Сөйләшү тәмам.

– Әнием, мин өйләндем! – дип әйтергә өлгерә телефон өзелгәнче Володя. Ул елмая һәм янәшәсендәге Инессасын үбә.

> 2023 ЕЛДА ИНЕССА БЕЛОВАГА – 90 ЯШЬ, Ә ТАТАРСТАННЫҢ «ДИНАМО» ҖӘМГЫЯТЕНӘ 100 ТУЛА. **ӘЛЕГЕ ЮБИЛЕЙЛАРНЫ БАСКЕТБОЛЧЫ ҺӘМ АНЫҢ КЛУБЫ БЕРГӘЛӘП КАРШЫЛАРГА НИЯТЛӘП ТОРА**.

Инессага 89 яшь. Аның меңнәрчә фотосурәт сыйган альбомнары бихисап, аларда – аның бәхетле спорт һәм гаилә тормышы. Володяның Кустанайга командировкасыннан соң Беловлар Казанга кайта, ул институтта химия укыта һәм «Динамо» ирләр баскетбол җыелма командасы тренеры булып эшли. Инесса исә озак еллар буе «Динамо» кызлар командасының иң шәп һөҗүмчеләреннән берсе була. Беловлар гомерләре буе әлеге клубка тугры кала, гәрчә аларны Казандагы башка командаларга да чакырсалар да. «Динамо» секциясенә кызлары һәм уллары йөри, оныклары да спорт белән мавыга. 2023 елда Инесса Беловага – 90 яшь, ә Татарстанның «Динамо» җәмгыятенә 100 тула. Әлеге юбилейларны баскетболчы һәм аның клубы бергәләп каршыларга ниятләп тора.

Фото: Алсу Шакирова

9 нчы тарих

Аның хәтер ярлары

Фәрит Гайнуллин – Орск-Хәлил металлургия комбинаты (хәзер «Урал корычы» АҖ) ветераны, күп сынаулар кичергән буын вәкиле. Сугыштан соңгы авыр елларда вакытыннан алда өлкәнәйгән һәм ныгыган, күп кыенлыклар күргән, әмма һәр кеше Җирдә үзеннән соң игелекле эз калдырырга тиеш, дип инанган малайлар кавеменнән ул.

ВАТАННАН ЧИТТӘ

Балачагы күпмилләтле мохиттә узган Фәрит, барлык кеше дә бертөрле, бер-берсеннән берничек тә аерылмый, тик төрле телдә сөйләшә генә, дип саный. Һәм үзен нигәдер татар дип үртәүләрен берничек тә аңлый алмый. Бервакыт исә, сыйныф җитәкчесе журнал тутырганда, татарлыгыннан оялып, үзен чуваш дип яздыра. Табигый ки, әлеге ялган тиз арада ачыла. Әмма укытучы сыйныфтагы балаларга: «Әгәр без шундый тату гаилә булмасак, фашизм кебек көчле дошманны җиңә алмас идек. Халыклар бердәмлегә генә илебезгә җиңү китерде...», – дип аңлата һәм Муса Җәлилнең батырлыгы хакында сөйли, Фәритне бүтән беркайчан да үртәүче булмый.

Язмыш юллары катлаулы бит, еллар узгач, Гайнуллиннарга легендар татар шагыйренең варислары белән туганлашырга да насыйп була. Муса Җәлилнең бертуган сеңлесе Хәдичә бервакыт Новотроицкига кунакка килә. «Безнең фатирда ул абыйсының шигырьләрен яттан укыды... Күзенә ирексездән яшь тулды, ул аны күрсәтмәскә тырышты. Тик миллионлаган кешенең сугыш имгәткән язмышын белә торып, хискичерешләрне тыеп буламыни?!»

Фәрит Гайнуллин үзенең «Минем хәтерем ярлары...» дигән китабында Муса Җәлил турында: «Оренбург төбәге Мостафа авылы белән горурлана ала – анда безнең

үз халкын җаны-тәне белән соңгы сулышынача яраткан даһиебез туып үскән», – дип яза.

Фәрит Татарстанны беренче тапкыр 15 яшендә күрә, ул чактагы Чкалов (хәзерге Оренбург) өлкәсенә Идел буе шәһәрләре буйлап экскурсиягә бүлеп бирелгән 11 юлламаның берсе аңа элэгә. Ул Бөгелмәдә була. «Биредә вакытның башкача агышы сизелә, татар моңы агыла, татарча сөйләшү колакны иркәли. Миңа биредәге кешеләр дә бөтенләй башка төрле булып күренде – шат күңелле, көләч, тормыш сөючән кебек иде алар», – дип яза аннары китабында.

БЕРЕНЧЕ ЭШ ХАКЫ

Табигый ки, сугыштан соңгы еллардагы бик күп гаиләдәге кебек үк, Гайнуллиннарның да гаилә бюджеты ярлы була. Фәритнең исә ничек тә эти-энисенә ярдәм итәсе килә. Яшүсмер, беркемгә дә әйтмичә, җәен эшкә урнаша һәм беренче хезмәт хакыннан барысына да бүләк алып кайта. Әтисенең мактавына җавабы кыска була: «...Мин зур инде, менә тиздән паспорт алырмын да, җәйгә генә түгел, чынлап эшкә урнаширмын, шуннан соң тормышыбыз җиңелрәк булыр», – ди.

АРМИЯДӘН СОҢГЫ ГОМЕР

Хәрби-диңгез флотында дүрт ел хезмәт иткәннән соң, Фәрит Новотроицкига кайта һәм яңа төзелеп яткан хром кушылмалары заводына эшкә урнаша. Бик күп һөнәр алыштыра – электромонтер, сменаның кизү электригы, мастер булып эшли. Аның хезмәт биографиясендә Орск-Хәлил металлургия комбинатында, «Востокэнергочермет», силикат заводларында эшләү дә бар...

Гайнуллин пар-энергия хуҗалыгы башлыгы булып билгеләнгәндә, яңа төзелгән силикат заводы үзенең ярты куәтенә генә эшли торган була. Автоклав бүлегендә редукцияләштергеч суыту җайланмасының (РОУ) булмавы тулы куәткә эшләп китәргә ирек бирми.

– Әлеге проблеманы хәл итүгә ике елга якын вакыт китте, – дип искә ала ветеран. – Мәскәүдәге киңәшмәдән соң безнең силикат заводы җитәкчелеге әлеге суыту җайланмасын ничек тә табарга карар кылды. Аларны Барнаулдагы казан заводы җитештерә. Оператив киңәшмәләрнең берсендә завод директоры: «Йә, нишлибез, бер урында таптану туйдырды бит, силикат кирпеч җитештерү буенча проект куәтенә чыгасы иде... Илдә зур төзелешләр бара, кирпеч һава кебек кирәк», – диде.

Һәм шунда барысы да миңа төбәлде... Минем каршы килүемә беркемнең дә исе китмәде. Һәм директорның: «Иртәгә үк кичке поезд белән китәсең», – диюеннән соң мин командировкага әзерләнергә кайтып киттем.

Гайнуллин кирәкле җиһазны таба. Алай гына да түгел, форсаттан файдаланып, ул вакытта дефицит саналган арматурага заказны да икеләтә арттыра. Барнаулдагылар: «Директорың кемне җибәрәсен белеп җибәргән... Рәхәтләнеп эшләгез инде!.. Сезгә дигән җиһазларыгызны «КАМАЗ»лар белән җибәрербез. Борчылмагыз. Син поездда кайтып җиткәнче, җиһазлар заводта булачак», – дип ышандыра.

Әмма Гайнуллин өчен җиңел генә тәмамланмый әле бу суыткыч кыйссасы. Ул эшкә чыга, ә вәгъдә ителгән җиһазлар һаман юк. Берничә тапкыр Барнаулга шалтырата. Җавап бер генә: машиналар китте, әле кире кайтмады. Инде кабат барырга җыена. Кинәт директор шалтырата: «Нәбиуллыч, командировкага бармыйсың, эшкә чык, җиһазларны кабул итеп ал», – ди.

Оренбургка килеп җитә язганда, машиналарның юлын кар көртләре бүлгән икән, шунлыктан алар башта Молдавиягә киткән. Новотроицкига исә кире кайтканда гына кергәннәр.

Иң мөһиме – нәтиҗәдә җиһазлар бик тиз арада урнаштырыла, һәм завод проект куәтенә чыга.

> УЛ ИНДЕ КҮПТӘН ЛАЕКЛЫ ЯЛДА, ӘММА ХӘЗЕР ДӘ, ШӘҺӘРДӘ ЙӨРГӘНДӘ, ЭЛЕККЕ ШӘКЕРТЛӘРЕ КИЛЕП ИСӘНЛӘШӘ, ХӘЛЛӘРЕН БЕЛЕШӘ, **ҮЗЛӘРЕНЕҢ УҢЫШЛАРЫ ХАКЫНДА СӨЙЛИ.**

«МИН ТОРМЫШЫМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ...»

Фәрит Нәбиулла улы Гайнуллин гел яңа җиһаз һәм технологияләр кертү белән генә шөгыльләнми, әлбәттә. Ул заводның партбюро секретаре дә була, төзәтү колониясендә пар казаннары бинасы башлыгы, металлургия комбинатында ведомстводан тыш сак идарәсендә һәм баш энергетик бүлегендә, шәһәр халык мәгарифе идарәсендә, төзелеш техникумында да эшли...

Ул инде күптән лаеклы ялда, әмма хәзер дә, шәһәрдә йөргәндә, элекке шәкертләре килеп исәнләшә, хәлләрен белешә, үзләренең уңышлары хакында сөйли.

Һәм ул, әлбәттә инде, үз шәкертләре өчен бик сөенә: «Чөнки урамдагы шундый бер генә очраклы очрашу да (ә алар берике генә түгел) – минем тырыш хезмәтем, үземнең аларга биргән белемем һәм тәрбиям өчен иң яхшы ихтирам билгесе бит. Мин моның белән горурланам», – ди абруйлы остаз.

Фото Гайнуллиннарның гаилә архивыннан

Фото: Максим Малютин, Олеся Бондаревская

Төньякка, Поляр түгәрәк аръягына командировка – кайсы гына журналист ул якларны күреп кайтырга хыялланмый икән. Еш кына чынга ашмаслык бу хыял. «Татарстан» журналы мөхәррире Олеся Бондаревская исә, язмышның хәерхаһлыгын көтмичә, мондый мөмкинлек бирә торган федераль конкурста катнашып җиңүче булды. Төп бүләк – Баренц диңгезе буена сәяхәт. Поляр түгәрәк аръягы турында язма – хәбәрчебезнең бу кызыклы сәяхәткә багышланган иҗади хисабы.

БЕЗ БУЙСЫНДЫРГАН ТӨНЬЯК

Казаннан самолет безне Арктикага нибары 3–5 сәгатьтә илтеп җиткерә. Ә менә анда барып җиткәч хәрәкәт итү бу якка очудан күпкә катлаулырак икән.

Очкыч биеклеген киметә, мин иллюминатордан түбәндә җемелдәгән шәһәр утларын күрергә телим, әмма аста караңгылык. Без самолет туктаганчыга кадәр дөм караңгыда очабыз. Беренче якты тап – аэропортның саран гына яктыртылган парковкасы өстендә үк янып тора торган зур хәрефләр белән: «Мурманск – Арктика башкаласы» дип язылган язу.

Кичке сигезләр тирәсендә шәһәргә барып җитәбез, әмма, урамнар яктыртылуга карамастан, монда да шундый ук караңгылык хөкем сөрә. Караңгылык – көз, кыш һәм яз айларында Кола ярымутравына хас халәт. Әйтерсең лә Мурманск өстенә гаять зур аю җәелеп яткан да тирә-яктагы бөтен яктылыкны каплап алган.

Ләкин фонарьларның сүрән яктысында да шәһәр үзәгенә хас конструктив архитектураның геометрик төзлеген, бөтенлеген шәйләргә була. Безгә дип билгеләнгән кунакханә аның үзәгендә – Биш почмак мәйданында урнашкан икән. Тәрәзәнең берсеннән башка зур шәһәрләрнекенә охшаган үзәк күренеп тора. Икенчесеннән – порт һәм аның уты яктылыгында җемелдәгән карлы тауларның озын-озын рәтләре. Болар барысы да безнең Россиянең урта полосасында түгел, Поляр аръягында икәнлекне искәртә һәм биредә бөтенләй башка тормыш рәвеше алып барулары турында сөйли.

ТОРМЫШ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ

– Сез әйбәт чакка туры килдегез – көн яктылыгын күрәчәксез. Ә без поляр төнгә әзерләнәбез – 2 декабрьдән 17 гыйнварга кадәр, ай ярым вакыт эчендә беренче тапкыр кояш 20 минутка калкып алачак, – ди туган якны өйрәнүче һәм шәһәр буенча экскурсоводыбыз Елена Зелезинская. Елена Павловна – Мурманскида туып үскән кыз. Ул үзенең шәһәре – Россия империясендә оешкан соңгы кала турында бик яратып сөйли. Ул вакытта Мурмандагы Романов дип аталган шәһәр Төньяк боз океанына чыгу өчен стратегик максатларда төзелгән. Беренче тапкыр 1920 нче елларда биредә тормыш яхшырып китә. Бөек Ватан сугышы чорында союздаш илләрдән йөк төялгән судноларнәкъ менә биргә килә, һәм фашистларның максаты ничек тә булса шәһәрне яулап алу була. Дошман ике һөҗүм операциясе оештыра. Мурманскины көлгә калганчы диярлек яндыра, тик буйсындыра алмый. Шәһәрнең икенче мәртәбә яңарышы 1950 нче елларга туры килә. Ул тулысынча диярлек яңадан торгызыла, һәм төзелеш 1990 нчы елларга кадәр дәвам итә. Заманында үзәктә пәйда булган Сталин ампиры өслүбендәге йортлар, периферияләге биш һәм тугыз катлы өйләр әле һаман да шул чорларда катып калган кебек тоела.

Катып калган кебек, чөнки мондагы тормыш – өстенә боз яңгыры яудырырга, өшетергә, диңгездә батырырга тырышкан табигать көрәшләре белән даими көрәш. Экскурсовод безне шәһәрнең төп һәйкәлләренең берсе – тыныч вакытта һәлак булган диңгезчеләр мемориалына алып бара. Маяк-мемориал янындагы диварга Мурманскидан 200 км ераклыкта Баренц диңгезендә баткан «Курск» атом су асты көймәсе рубкасының бер өлеше урнаштырылган. Маяк эчендә диңгезчеләр – авиаторлар, су өсте, су асты көймәләре, сәүдә, бозваткыч, балыкчылык флоты хезмәткәрләре истәлеген үзенә сеңдергән хәтер китаплары саклана. Кайбер яңа язмалар 2020, 2021 елларга карый. Маяктан ерак түгел генә 2000 нче елларда төзелгән Судагы Спас храмы урнашкан, ә храм түбәсе астында – диңгез давылларыннан саклана торган җиңел һәм чыдам җилкәнле көймә...

ДӨНЬЯДА БЕРЕНЧЕ БОЗВАТКЫЧ

Без – 1989 елдан мәңгелек тынычлыкка куелган «Ленин» атом бозваткычы идарәсе пульты урнаштырылган бүлмәдә.

– Hey, chineses, if you will touch anything else, you will go out! (Әй, кытайлар, сез тагын берәр нәрсәгә кагылсагыз, чыгып китәсез! – инг. тәрҗемә; ред. иск.), – ди, безгә һәм башка туристларга Мурманскига кагылышлы төп диңгез легендасы – дөньяда беренче атом бозваткычы буенча экскурсия үткәрүче егет кинәт инглизчәгә күчеп.

Йөз чалымнары азиялеләргә тартым бер егет каршында торган төймәләрнең берсенә кагылган икән. Экскурсия үткәрүченең сүзләрен ишетүгә, аның дуслары читкәрәк кагылды. Гидның интонациясен һәм сөйләү рәвешен ишетеп, мин дә үземне экскурсиядә

төгел, менә-менә имтиханнан куып чыгарылачак студент кебегрәк хис иттем.

Кызганыч вакыт тиз үтә, ә монда кызыклы әйберләр шактый. Чын капитан кабинасында әйләнеп тора торган компаслы рубка, кәнәфи аркасына эленгән костюм. Әгәр Казан портында шундыйрак нәрсә булса, анда инде күптән балалар һәм өлкәннәр өчен берәр квест-маршрут оештырырлар һәм судно белән идарә итү симуляторларын урнаштырырлар иде, дип уйлап куям мин. Тик бередә без кырык минут дәвамында «Ленин» бозваткычының гадәти эш көннәре турында хикәя тыңлыйбыз. Иң кызыгын безне озатып йөрүче Елена Зелезинская сөйли.

– Проекторны күрәсезме? Айлар буе йөзеп йөргәндә кают-компаниядә кинофильмнар күрсәтәләр. Фильмнар бик аз була, шуңа күрә тиздән аларны яттан белә башлыйлар, – дип сөйли Елена Павловна. – Аптыраганнан ике судно, кагыйдә буенча туктап очрашулар тыелса да, тукталыш турында килешә. Шул рәвешле үзара кинофильмнар алмашалар.

САAMНАРНЫ ЭЗЛӘҮ ЮЛЫНДА



Төньяк кыюларны ярата – уңайлы автобус тәрәзәсеннән тирә-юньне күзәтеп барганда без шуны аңлыйбыз. Ләкин төп сынау кырыс климат түгел, бәлки озын поляр төн, кыска поляр көн һәм кояшның бөтенләй күренмәведер. Кайвакыт җәй дә шулкадәр кыска һәм салкын була ки, фатирда җылыткычлар май аеннан октябрьгә кадәр эшли.

– Болан ашатырга уйласагыз, икмәк тоткан кулыгызны күтәрмәгез. Болан үзеннән-үзе арткы тоякларына күтәрелачәк, ә төшкәндә алгылары белән башыгызга туры килергә мөмкин. Икмәкне учыгызга куегыз, кырыеннан тотмагыз – болан акча кабул итә торган аппарат түгел! – дип аңлата безгә Ловозеро бистәсе янындагы Самь-Сыйт этнография музее экскурсоводы Владимир.

Ловозеро – Кола ярымутравында җирле халык – саамнар яшәгән урыннарның берсе. Болан үрчетү, аучылык белән шөгыльләнүче, урман һәм тере табигать рухларына табынучы саамнар монда X–XII гасырда рус дәүләтеннән көченүчеләргә кадәр үк яшәгән. Без Самь-Сыйтка уникаль һәм аз санлы җирле халык белән танышырга килдек (Кола ярымутравында саамнар – нибары 1,6 меңгә якын кеше икән), ләкин аның бер генә вәкилен дә очратмадык.

– Сез барыбер саамны саам булмаган кешедән аера алмаячаксыз, – ди Владимир. Ул үзен рус, дип раслый, ләкин кем белә, бәлки аңа безнең этнография белән кызыксынуыбыз бик ошап та бетмәгәндер. Инде гадәтләнергә өлгергән караңгылыкта Владимир безне табигать, мәхәббәт, язмыш кебек төрле көчләрне аңлаткан тотем баганалары янына алып бара. Ул безгә теләк теләргә куша һәм мин, уңайсызлану, курку, аптырау кебек хисләр кичереп, эчтән генә үз теләкләремне телим. Аннары шулай ук караңгылыкта безнең янда боланнар пәйда була, аларны берниди маҗараларга тап булмыйча гына ашатабыз. Алга таба программа буенча – болан җигелгән чаналарда йөрү, тик кар булмау сәбәпле, безне квадроциклларга утырталар. Без кечкенә кенә территорияне периметры буенча берничә мәртәбә урыйбыз. Ә тирә-якта – саамнарның тылсымлы һәм шомлы мифларын тудырган кырыс, кеше кулы тимәгән тундра.

БӘХЕТ ЭЗЛӘҮЧЕЛӘР

Йөзләрчә ел элек Ловозеро тундраларында карак һәм кеше үтерүче Куйва дигән алып яшәгән, ди. Көннәрдән бер көнне аллалар, саамнарны яклап, «күл яшене» ярдәмендә Куйваны яндырган. Риваятькә караганда, бу хәл Сейдозеро ярында, Самь-Сыйттан кырык километр ераклыкта булган. Күл буендагы кыяда аның 70 метрлы силуэты гына калган. Аның килеп чыгышы турында фаразлар бик күп, ләкин Сейдозеро бүгенге көнгә кадәр җирле «Бермуд өчпочмагы» булып кала бирә. Монда техника җимерелә, туристлар югала, кешеләрнең күзләренә төрле нәрсәләр күренә.

– Мин үзем анда озак тора алмыйм, баш авырта башлый, – ди безнең яңа гидыбыз Максим Малютин. Ул безнең белән Кола ярымутравының иң популяр нокталарының берсе – Териберка авылына бара. Элек Максим хокук саклау органнарында эшләгән һәм «Левиафан» фильмында Звягинцев тарафыннан шактый кырыс сурәтләнгән диңгез албастысы турында яхшы белә. Фильмны нәкъ менә биредә төшергәннәр.

Безнең автобус зур таулар арасындагы ике полосалы юлдан элдерә. Тау очларында кечерәк ташларга утыртылган зур ташлар – серле сейдлар күренә. Саамнар өчен сейдлар – хөрмәт, табыну объектлары, дип аңлата

Максим. Ул саам шаманнары – нойдларның ни рәвешле гипноз транслары үткәрүләре, 1930 нчы елларда Кола ярымутравында Гипербореяны ничек эзләүләре турында ярым легендага әйләнгән хикәяне сөйли. Аны ария расасының илаһи килеп чыгышын расларга теләгән Гитлер да эзләгән, ди.

Кола ярымутравы хәзер дә чит ил туристларын үзенә магнит кебек тартып тора. Соңгы елларда Мурманск өлкәсенә кытайлар күпләп килә икән: алар Aurora Borealis – Төньяк балкышын күрүне бәхеткә юрыйлар, ә инде ул вакытта балага узсаң, һичшиксез, бик акыллы малай туачак, ди.

Териберкада уздырган төндә Максим безне Төньяк балкышын күрергә алып бара. Юл кырыенда төркем-төркем кытай һәм рус егет-кызлары, күрәсең, шашлык кыздыра-кыздыра Төньяк балкышын көтә. Без дә көтәбез, муеныбыз каерылганчы күкне күзәтәбез. Тик томан һаман таралмый, безне үзенең яшькелт пәрдәсе белән котыртып кына тора. Арып-талып, салкыннан күшегеп, без автобуска таба борылабыз.

– Әнә карагыз! – дип кычкыра кинәт кемдер. Болыт арасыннан зөбәрҗәт төсендәге нур пәйда була, аннан тагын берсе, икенчесе... Бераздан балкыш ничек барлыкка килсә, шулай бик тиз юкка да чыга. Табигатьтән бу бүләкне алуыбызны бүген телефоныбыздагы фотолар гына раслый.

ДИҢГЕЗ ҺӘМ АНЫҢ КЕШЕЛӘРЕ

Териберка – гаҗәеп гүзәл һәм гаҗәеп ташландык урын. Без аны 150 метр биеклектән – авыл өстеннән күтәрелгән тау башыннан күзәтәбез. Артыбызда кояш күтәрелә, һәм Баренц диңгезенең комлы ермагы, ресторан, балыкчылар йортлары, гасыр башына караган агач корылмалар – барысы да алсу нур яктылыгында күренә.

Ләкин түбәнгә төшүгә, Териберкада таралган диңгез, балык һәм күгәрек исе борынны ярып керә. Бу ниндидер шаккату, чиркану, сагыш һәм кабат гаҗәпләнү кебек капма-каршы хисләр уята. Күрәсең, монда 2016 елда «Териберка. Яңа тормыш» фестиваленә килгән рәссам-граффистлар да шундыйрак хисләр кичергәндер. All I had, I gave (Үземдә булган бар нәрсәне бирдем) – ташландык йортларның берсенә шулай дип язылган.

Шау-шу куптарган «Левиафан»ны төшерү вакытыннан Териберкада берни дә сакланып калмаган. Фильм буенча төп герой йорты урынында төзелгән чиркәүне законсыз салынган бина дип сүткәннәр. Максим чиркәүнең кайда торганын күрсәтә. Шулчакта кылт итеп «Зөләйха» фильмын төшергәннән соң Лаеш районында сакланып калган «Семрук» исемә төшә. Мин үзем яшәгән төбәкнең нинди генә чорга һәм контекстка карамастан, үзенең мәдәни кодларын яклауга һәм саклауга да, килгән кунакларны каршы алуга да никадәр юмарт булуына, аларны һәрвакыт кайнар өчпочмагы, якты йөзе белән көтеп торуына шатланып куям.

– Без Кола ярымутравының туристлык объектларын барлау һәм үстерү белән күптән түгел генә системалы рәвештә шөгыльләнә башладык. «Ростуризм» безгә бик ярдәм итә иде. Кызганыч, хәзер аны таркаттылар, – ди Максим. Ул безне Териберка белән күрше Лодейный бистәсеннән башланган җәяүле маршрут белән Баренц диңгезе ярына алып бара. Килеп җиткәч, диңгез ярына каккан ярсу дулкыннарны күзәтәбез: әйтерсең лә алар безне диңгез кочагына тартып алырга тели. Менә шулчакта без гидыбыз һәм аның хезмәттәшләренең ни өчен бирелә, дөнья читендә, Арктика бусагасында мөмкин кадәр күбрәк кеше басып тора алсын өчен кулдан килгәннең барысын да эшләргә әзер икәнлеген аңлыйбыз.

КҮП БАЛАЛЫ АНА: «БАЛАНЫ МЕДАЛЬ ӨЧЕН ТАПМАДЫМ»

Руфия Фазылова

Югары Ослан районының Берек авылында яшәүче Ләлә Галләмова җиде бала үстергән. Ноябрьнең соңгы якшәмбесендә – Әниләр көнендә Ләлә апага шалтыраттым. Бәйрәм белән котлагач, ана кеше елап җибәрде. Хәлнең нидә икәнен аңламыйча, уңайсызланыбрак калдым. «Әниләр көне белән моңа кадәр бер генә кешенең дә котлаганы булмады, күңелем тулып китте. Зур рәхмәт сезгә», – диде ул.

Фото: Алсу Шакирова

АЛТЫ КЫЗ, БЕР МАЛАЙ

Икенче көнне Ләлә апа белән аның өендә очраштык. Вазада тере чәчәкләр утыра, бер түгел, ике букет. Әниләр көненә балалары бүләге икән. Димәк, ананы бәйрәм белән тәбрикләгәннәр.

– Чит кешеләрнең котлаганы юк дип әйтүем иде, – диде Ләлә апа.

Ана кешегә октябрь аенда 65 яшь тулган. Әнәс абый белән никахлашып яши башлауларына кырык елдан артык вакыт узган. Ир белән хатынның бүген инде унике оныгы бар, тиздән унөченчесе дөньяга киләчәк икән.

Ләлә апаның алты кызы, бер улы бар. Иң олы кызы кырык, иң кечесе егерме өч яшендә. Алты баласының инде үз гаиләләре бар. Балаларның дүртесе авылда төпләнеп калган.

– Ике кызым, улым районга йөреп эшли, «Дивный Берег» компаниясендә хезмәт куялар, – диде Ләлә Галләмова. – Әле башта дүртесе дә шунда иде, аннары өченче кызым ул эшеннән китте.

Ләлә апа тумышы белән Берек авылыннан. Җәмәгате Әнәс абый күрше Болгар авылыныкы. Яшьлектә кавышып, шулай гаилә корганнар. Дөрес, рәсми рәвештә языльшмаган алар, никах белән генә яшиләр. Моның сәбәбен сорагач, Ләлә апа болай диде:

– И, башта языльшырга җай булмады. Аннары инде калды. Бала тугач, аерылып тормасын дип, кызымны үземнең фамилиямә яздырдым. Аннары икенчесен дә. Соңрак инде документлар алмаштырып йөрисе килмәде. Әнә шулай итеп Галләмовлар булып калдык.

Берек яңа авыллар рәтендә йөри. Дүрт ел элек аның 100 еллыгын билгеләп узганнар. Бу якларда егерменче гасыр башында оешкан шундый берничә татар авылы бар. (Шундыйларның берсе – Бакчасарай турында аерым язган да идек.) Авылда кышын унбишләп кенә йортта кеше яши, җәен исә шәһәрдән кайтучылар күп. Ике урамлы әлеге бәләкәй авылда яңа йортлар шактый. Ләлә апаның күршесендә генә кызлары яңа йорт салып ята.

– Балаларым авылны ярата, үзебез кебек, – диде ана кеше. – Эштән дә курыкмыйлар. Әйе, балалар үстерергә авылда мөмкинлекләр юк инде, бакча, мәктәп тә юк, Шеланга авылына йөртәләр. Ә без үскәндә авылда башлангыч мәктәп бар иде. Мин шунда белем алдым. Аннан инде Шелангага барып укыдык. Аның интернаты бар иде, шунда яшәдек тә. Берек ул чакта гөрләп тора иде: мәктәп, клуб, кибет, фельдшерлык пункты, фермалар, тегермәннәр. Ни аяныч, бүген аларның берсе дә юк.

ЭШЛЕ БӘХЕТ

Ләлә апа әтисез үскән бала. Аңа алты яшь чагында мәрхүм була. Әнисе дүрт бала белән тол кала. Кечкенәдән эшләп үсә ул. Гаиләле булгач та, эштән туктамый. Хәтта балалары тугач та, дүртәр айдан эшкә чыга.

– Егерме биш ел фермада сыер саудым,- диде Ләлә апа. – Безнең монда зур совхоз иде. Атлар, дуңгызлар да асрадылар. Аннары фермалар бетте, мин дә лаеклы ялга киттем. Күп балалы әни буларак пенсияне 50 яшемдә ала башладым.

– Сез эштә булганда балаларны кем карады? – дим.

– Бездән ерак түгел әни яшәде, ул карады. Әни унбер ел элек мәрхүм булды. Бик булышты ул безгә, сөйләп бетерә торган түгел. Берсеннән-берсе кечкенә балаларны алып кала иде бит. Без эшкә киткәнче, иртәнге биштә торып кереп җитә иде. Әнәс тә фермада ат җикте.

Ләлә апа башта дүрт кыз алып кайта, бишенчегә малай икәнен белгәч, шатлыктан елап ук җибәрә.

– Ирем өчен куандым, ул бик тә малай көтте, – дип ул чакларны искә алды ана кеше. – Әйе, кызларны да яратты ул. Шулай да ир кешенең уллы буласы килә бит. Улыбыз Илшат була дип алдан әйтеп йөри иде, малайга исем эзләп азапланмадык. Аннары тагын кызыбыз туды. Шуның белән җитәр дип тә уйлаган идем. Туасы тагын бер җан булган икән – төпчек кызыбызны кырык ике яшемдә таптым. Анысын үстерергә бик җайлы булды – олылары

Яшь чак – матур чак.

карашты. Хәер, тегеләрен дә апалары үстереште. Башта туган ике кызым уң кулым булды, Ләйлә 1982 елгы, Диләрә 1983 елда туды. Маллар карашырга, өй эшләрендә дә алар гел беренче иде. Эшкә батырлар.

– Балалар үстергәндә иң авыры нәрсә булды? – дим.

– Иртән балаларны мәктәпкә җыю. Иртә белән алтынчы яртыда фермага чыгып китәбез. Шул вакытка кадәр кызларны уятып, чәчләрен үреп калдырырга кирәк. Әле бит шул арада малларны карарга, сыерларны саварга кирәк. Терлек-туар гомергә күп асрадык. Әле дә сыерыбыз бар. Әйтәм бит, әле ярдәм итәргә әни булды. Без эшкә киткәч бер оя баланы алып калды, мәрхүмкәем.

Ләлә апа бүген үзе дә әнисе кебек – оныкларын карый, әле берсен китерәләр, әле икенчесен. Уртанчы кызы Югары Ослан районы хастаханәсендә эшли, узган ел «кызыл зона»да була. Ләлә апа ике оныгын бер елга якын карый.

– Әнине хәзер бигрәк тә аңлыйм, – диде күп балалы ана. – Онык карау зур җаваплылык сорый. Фермада эшләгәндә кайбер чакта көне буе өйгә кайтмаган вакытлар да була иде, сыер саву белән бергә ферма мөдире вазыйфасын да алып бардым. Хайваннарны үлчәп озатасың, документын тутырасың... Кайткан төшебезгә әни ашарына да пешереп куйган була. Ничек житеште, түзде икән, дим. Алтмышны тутырган иде бит...

ТАТАРСТАНДА 2005 ЕЛДАН БИРЛЕ БИШ ҺӘМ АННАН ДА КҮБРӘК БАЛА ТАПКАН ҺӘМ ТӘРБИЯЛӘГӘН (ТӘРБИЯЛӘҮЧЕ) ХАТЫН-КЫЗГА «АНА ДАНЫ» МЕДАЛЕ БИРЕЛӘ. Закон буенча медаль бирелгән вакытта балигъ булмаган балалар саны бердән дә ким булмаска тиеш (шул ук вакытта бишенче балага өч яшь тулгач кына тапшырыла). «Ана даны» медален бирү турындагы гаризаны оешма коллективы, җәмәгать берләшмәләре, дәүләт органнары, шул исәптән Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының урындагы органнары бирә. Аннан исә Татарстан Президенты Указы нигезендә карала.

МЕДАЛЬСЕЗ АНА

Ләлә апа җиде бала үстергән өчен кош теле кадәр рәхмәт хаты да алган кеше түгел. Әниләр көне уңаеннан авыл җирлегеннән, район администрациясеннән дә беркайчан бәйрәмгә чакырмаганнар. (Мисал өчен, быел 26 ноябрьдә Югары Осланда яшәүче күп балалы аналарны, ихтирамга лаек башка хатын-кызларны район үзәгенә җыеп тәбрикләгәннәр.) Күп бала үстерүче гаиләгә торак шартларын яхшыртуга бирелә торган акчаны да алмаганнар.

– 2000 нче елларда Югары Ослан администрациясеннән килгәннәр иде, йортыбызның зур түгеллеген күрделәр, – диде Ләлә апа. – Йорт салу өчен акча булачак, дип ышандырдылар. Бөтен документларны җыеп та бирдем. Тик шуның белән бетте. «Сезнең йортыгыз яшәрлек», – дип җавап бирделәр. Шуннан бирле бер ишекне дә шакыганым юк. Исәнлек булсын. Беркайчан соранып йөрмәдем, язмасын да. Балаларны үзебез өчен үстердек...

Шулай дисә дә, Ләлә апаның күңелендә үпкә бар. Хәер, гаҗәп түгел: гомер буе шунда яшәп, эшләп, барлыгыңны да белмәсеннәр әле!

«Аны даны» медале дә юк аның. Белгәнебезчә, Татарстанда 2005 елдан бирле биш һәм аннан да күбрәк бала тапкан һәм тәрбияләгән (тәрбияләүче) хатын-кызга «Ана даны» медале бирелә. Ләлә апа ул турыда белә. Ләкин әлеге дә баягы, күләгәдә калган ханымга анысын да бирмәгәннәр. Кызганыч, хәзер инде аның артыннан йөреп тә булмый, чөнки закон буенча медаль бирелгән вакытта балигъ булмаган балалар саны бердән дә ким булмаска тиеш (шул ук вакытта бишенче балага өч яшь тулгач кына тапшырыла). «Ана даны» медален бирү турындагы гаризаны оешма коллективы, җәмәгать берләшмәләре, дәүләт органнары, шул исәптән Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының урындагы органнары бирә. Аннан исә Татарстан Президенты Указы нигезендә карала.

– Ни өчен җиде бала анасы гел күләгәдә калган? – дип, Югары Ослан районының социаль һәм мәдәни мәсьәләләр буенча башкарма комитеты җитәкче ярдәмчесе Гөлфия Абдуллинага мөрәҗәгать иттем.

– Ләлә апа Галләмова турында беренче ишетәм, – диде җитәкче ярдәмчесе. – Ләкин мин аның исем-фамилиясен бүген үк теркәп куям. Кызганыч, районда Әниләр көне узды, чакырган булыр идек. Киләсе елларга чакырырбыз, Аллаһ боерса. Районның социаль яклау идарәсендә эшләүчеләр белән уйлашып бетерербез – ана кешегә нинди ярдәм күрсәтеп була икән? Бик кызганыч, әлбәттә. Хатаны ничек тә төзәтергә кирәк.

...Ләлә апа медаль, башка ярдәм булмауга караганда, бигрәк битарафлыкка аптырый. Җиде бала үстереп (шуның бишесе Югары Ослан районында хезмәт куя, балалар үстерә), бер җылы сүз белән дә телгә алмаслык әниме ул?! Район администрациясендәге җаваплы кешеләр бу мәсьәләне контрольгә алырлар, дип ышанабыз. Һәм алга таба да редакция күп балалы Ләлә Галләмова белән элемтәдә торачак.

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

1942 елның маенда мөфти Габдрахман Рәсүли сугышчыларга **нинди** сүзләр белән мөрәҗәгать иткән

Җамал Вәлиди татар тарихында **нинди** эз калдырган

Яңа Татар бистәсендә Ал мәчет **кайчан** төзелгән

Яңа Иштирәк авылы **ничек** яши

тарихи шәхесләр

ГАБДРАХМАН РӘСҮЛИ. КЫРЫС ЗАМАН МӨФТИЕ

922 2022 Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы

Әхмәт Шакиров

«Аллаһы Тәгаләнең ошбу мөкаддәс аятьләре, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдис шәрифе илә гамәл кылып, кадерле Ватаныбызны... бу залимнарның золымыннан коткарырга сугыш мәйданында тырышыгыз. Сугыш артында куркаклык күрсәтми... бөтен көчегез илә сугыш өчен кирәкле булган әсбапларны хәзерләргә тырышыгыз...» Бу 1942 елның маенда, немецлар Кавказга ыргылып, фронттагы хәлләр бик кискенләшкән мәлдә ил мөселманнарына мөрәҗәгатьтән өзек. Мөрәҗәгатькә мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәте мөфтие Габдрахман Рәсүли кул куйган.

Рәсүли ул вакытта илдә бердәнбер абруйлы мөселман эшлеклесе санала: террор һәм сугышчан атеизм еллары үзенең яман гамәлләрен кылган була. 1927 елда илдә Диния нәзарәтенә караган унбиш меңгә якын мөселман мәхәлләсеннән сугыш башланганда йөзгә якыны гына кала, күпме ислам дин әһеле атып үтерелә, меңләгәне ГУЛАГ лагерьларында җәфа чигә. Ләкин хәзер башка вазгыять: бусага төбендә – дошман. «Ватанны сөю – иманнандыр»...

СУГЫШКА БИШ ЕЛ КАЛА

Төп максат – Кояш нуры кебек яктырта, хәтта тирә-якта дөм караңгы булса да. Кем белә, бәлки, шул максат хакына Рәсүли кырык икенченең май вакыйгаларына алты ел кала, әлеге авыр йөкне үз өстенә алгандыр? Ул вакытта, шомлы 1936 елда, ул Диния нәзарәтенә мөфти итеп билгеләнә. Билгеләнү ни рәвешле булгандыр – монысы тарих чоңгылында яшерелгән сер. Әмма шунысы төгәл билгеле: гәрчә Диния нәзарәте уставында каралган булса да, яңа мөфти сайлау өчен бернинди дә съезд оештырылмый, чөнки хакимияттән рөхсәт бирелми. Шулай ук кандидатларның икәү – Үзәк Диния нәзарәте рәисе урынбасары Кашшаф Тәрҗемани һәм Габдрахман Рәсүли булуы да билгеле.

Бернинди дә иллюзияләр юк: ике кандидат та, әлбәттә, совет хакимиятенә тугры – югыйсә бер генә көн дә иректә булмаслар иде. Тик берсе мөфти булуга ирешә, ә икенчесен, 30 дан артык ислам дин әһеле белән бергә, тиз арада оештырылган эш – Диния нәзарәте җитәкчеләре заговорында катнашуда гаепләп кулга алалар. (Тәрҗеманине ун елга төрмәгә утырталар, һәм ул тоткынлыкта вафат була – ред.иск.)

СУГЫШ. «АЛЛАҺ АРТКА ЧИГЕНҮЧЕЛӘРНЕ ЯРАТМЫЙ»

Рәсүлинең мөселман өммәтенә 1942 елның май аендагы мөрәҗәгате сугыш вакытында икенчесе. «Барлык мөселман мәхәлләләренә» дип аталган беренче мөрәҗәгате әле 1941 елның 2 сентябрендә үк яңгырый. Мөрәҗәгатьтә мөфти мөселманнарны бернинди дә көчне кызганмыйча дошманга каршы көрәшергә өнди. «Билгеле булганча, бу сугыш – Ватан өчен сугыш, шуңа күрә фронтта һәм тылда мөселманнар, дин күзлегеннән караганда, дошманны юк иткәнгә кадәр көрәшергә тиеш. Коръәндә болай диелә: «Дошман каршында чигенмичә, Аллаһ

Фото: islam-today.ru, cdum.ru

исеме белән дошманны юк итегез, Аллаһ артка чигенүчеләрне яратмый». Кремльдә, әлбәттә, бу авыр чорда мөселманнарны басып алучыларга каршы көрәшкә тупларга сәләтле сүзнең никадәр кадерле икәнен яхшы аңлыйлар. Дошман да моны аңларга ярдәм итә: басып алынган территорияләрдә немецлар мәчет һәм чиркәүләр ачарга рөхсәт итә, большевиклар исә динне кысучылар итеп күрсәтелә.

Еллар узгач, Габдрахман Рәсүли тормышын өйрәнүчеләр шуны раслый: мөрәҗәгать бәрабәренә аңа ниндидер вәгъдәләр бирелгән булырга тиеш. Моны раслап, хәтта шул ук 1941 елның сентябрендә пәйда булган мөрәҗәгатьтән өземтәләр дә китерәләр: «Совет хөкүмәте хәзер ислам динен кысрыкламаячак. Мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәте элек ябылган мәчетләрне ачачак». Барысы да мантыйкка ярашлы тоела. Моннан тыш, мөрәҗәгатьнең текстында бернинди дә вәгъдәләр язылмаган. Инициатива үзе дә мөфтидән булмагандыр дип уйларга нигез бар.

Хәер, бу әлеге документның әһәмиятен берничек тә киметми: мөселманнарны уртак дошманга каршы берләштерүдә ул, һичшиксез, үз ролен уйный.

СУГЫШТАН КҮПКӘ АЛДАРАК

Мөселман өммәтен иң авыр вакытта җитәкләгән мөфтинең абруе бер-ике ел эчендә генә формалашмаган. Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәсенә нигез салган шәех Зәйнулла Рәсүлинең улы Габдрахман, әтисенең мәдрәсәсендә белем алганнан соң, Каһирәдәге Әл-Әзһәр университетын тәмамлый һәм бик тиздән, 1903 елда, «Рәсүлия»нең директоры була. Аның җитәкчелегендәге мәдрәсәдә укытуның яңа ысулы кулланыла. Биредә, дини предметлардан тыш, күп кенә дөньяви дисциплиналар да укытыла, ә уку процессын оештыру Европа үрнәге буенча реформалаштырыла. «Монда, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендәге кебек, татар, башкорт һәм казахларны берләштерүче Оренбург Мәхкамәи шәргыя этноконфессиональ җәмгыяте өчен элита әзерләнә»*. Бирегә Идел-Урал төбәгеннән генә түгел, Казахстан, Себер, Урта Азиядән дә укырга киләләр.

Габдрахман Рәсүлинең хезмәтләре исемлегендә – III Бөтенроссия мөселман съездында катнашу (1906), ул 1917 елның июнендә фәтвага кул куйган, мәгариф һәм фәнгә чыгымнарны сәдакага һәм Аллаһка яраклы гамәлләргә тиң дип таныган дини җитәкчеләр арасында була. Инде совет чорында (1923) мөфти Ризаэтдин Фәхретдин Рәсүлине хәзерге Чиләбе, Свердловск, Курган, Төмән өлкәләре, Пермь крае, шулай ук Ханты-Манси һәм Ямал-Ненец автономияле округлары территорияләрен үз эченә алган Зур Урал өлкәсе буенча мөхтәсиб итеп билгели. Рәсүли голәмәләр һәм мөтәвәллиләрнең II һәм III бөтенроссия съездларында Голәмәләр шурасы әгъзасы итеп сайлана, бу тагын бер кат аның ислам теориясе һәм практикасы буенча танылган һәм абруйлы белгеч булуын раслый.

Ләкин мөселман дөньясында исем дә, абруй да 30 нчы еллардагы репрессияләрдән саклый алмый, бәлки, киресенчәдер. Ихтимал, Рәсүли, күп кенә коллегаларыннан аермалы буларак, революция һәм Гражданнар сугышы елларында тормышның яңа хуҗалары алдында үзен гаепле алырлык эшләр эшләмичә, бик сак эш иткәнгә генә исән калгандыр. Өстәвенә, ул яңа хакимияткә ярдәм итәргә әзер. Һәрхәлдә, 1926 елның 27 октябрендә голәмәләр һәм мөтәвәллиләр съездыннан Хиҗаз короле Согуд исеменә җибәрелгән сәламләү телеграммасын нәкъ менә Рәсүли имзалый (ул бу съездда рәислек итә – ред. иск.). Телеграммада съезд «Көнчыгыш һәм мөселманнарның азатлык эшләрендә Аллаһтан уңышлар тели». Мәскәү ислам дәүләтләре башлыкларын – Әфганстан патшасы Аманулла ханны һәм Төркия Президенты Мостафа Кемаль Ататөркне кабул иткәндә дә мөфти файдалы һәм кирәк була...

Совет хакимиятенә халыкара аренада диннәрне, аерым алганда, исламны кысрыклый дигән ат бернинди файда да китермәве аңлашыла.

СУГЫШ. СТАЛИН ТЕЛЕГРАММАСЫ

1942 елның май ае, Габдрахман Рәсүли мөрәҗәгате ашыгыч рәвештә казах, кыргыз, үзбәк, таҗик, төрекмән һәм башка телләргә тәрҗемә ителә, текстлы листовкалар традицион рәвештә ислам динен тоткан урыннарда меңләгән тираж белән таратыла. «Без, Советлар Союзындагы ислам галимнәре, дин һадимнәре, мөкаддәс Ватаныбызны, ислам галәмен саклау юлында залим герман фашистларына һәм аларның иярченнәренә каршы иттифак кылып көрәшкә бөтен мөселманнарны дәгъват кылабыз», – дигән сүзләр гади һәм аңлаешлы була, бер максатка юнәлдерелә. Фронтта, тылда дин тотучылар элекке ватаннарын онытып, яңасы хакына үз бурычларын үтиләр. Соңгы тамчы канга кадәр көрәшәләр һәм һәлак булалар.

1943 елның 5 мартында «Известия» газетасы Габдрахман Рәсүли телеграммасын бастыра. Ул мөселманнарның танк колоннасы төзелешенә акча җыелачагы турында хәбәр итә, бу саваплы гамәлгә үзеннән дә 50 мең сум акча кертелүен әйтә. Үзәк Диния нәзарәте бу эшкә барлыгы 10 миллион сумга якын акча җыя. Моңа җавап итеп Рәсүли Иосиф Сталиннан җавап телеграммасы ала: «Кызыл Армиянең бронетанк көчләренә кайгырту-

* А. Ю. Хабетдиновның «Лидеры российских мусульман и мусульманок в Российской империи и СССР (XIX-XX вв.)» хезмәтен кара.

СССР мөселманнарының рухи лидерлары: Үзәк Диния нәзарәте мөфтие Г. Рәсүли, Урта Азия мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие Э. Бабахан, Төньяк Кавказ мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие Х.-Г. Гебеков, Кавказ арьягы мөселманнары Диния нәзарәте шәехе Әхмәт-ага Али-задә.

чанлык күрсәтүегез өчен Сезгә рәхмәт. Минем сәламемне һәм Кызыл Армия исеменнән рәхмәтемне кабул итегез. И. Сталин». Мөфти өчен бу телеграмма саклау грамотасына тиң була дияргә мөмкин.

Сугыш – кискен чор. Дәүләт динне тиз арада юк итү планнарыннан баш тарта, киресенчә, дини тормышта яңарыш күзәтелә кебек. Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен.

СУГЫШКА БИШ ЕЛ КАЛА

Ни өчен нәкъ менә Рәсүлинең Үзәк Диния нәзарәтенә мөфти итеп билгеләнүен һәм руханиларны максатчан юк итү чорында исән калуын аңлатучы тагын бер фараз бар. Аның кызы Сафуат Рахманкулованың истәлекләрендә болай диелгән: «Июнь башында (1936 ел – ред. иск.) әти Уфадан телеграмма алды. Аны мөхтәсибләр киңәшмәсенә чакырдылар, чөнки Советлар Союзы мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтен ябарга җыеналар иде. Һәр мөхтәсибтән мөселманнарның Диния нәзарәте кирәкме, әллә аны ябаргамы дип сораганнар. Барлык мөхтәсибләр дә: «Хакимият карар иткәнчә эшләргә кирәк», – дип җавап биргән. Бу сорау әтигә бирелгәч, ул чыгыш ясарга булган. «Россия патшабикәсе мөселманнарның Диния нәзарәтен кирәк дип ачты, – дигән ул. – Сез аны кирәксез дип санап, ябарга телисез. Биш елдан соң ул кирәк булачак, ләкин аны ачу авырга төшәчәк – кирәкле кешеләр калмаячак».

Хакимият вәкилләрен әтинең чыгышы гаҗәпләндергән. Араларыннан берсе әтидән: «Фамилияң ничек, кайда яшисең һәм революциягә кадәр нәрсә белән шөгыльләндең?» – дип сораган. Әти үзе турында кыскача гына сөйләп биргән. Шул вакытта бу кеше әтигә: «Әгәр шулай икән, син, хәзрәт, мөфти булып эшлә һәм мөселманнарның Диния нәзарәтен сакларга тырыш», – дигән».

Әлбәттә, Рәсүлинең кызы сөйләгән сүзләр вакыйганың документаль дәлиле булып санала алмый, ләкин ул шул заман күзлегеннән караганда шактый реалистик булып күренә. Эш шунда ки, Уфа мөфтиләре киңәшмәсенә кадәр Таврия мөфтие Ибраһим Тарпи Бахчисарайдагы Кырым мөселманнары Диния нәзарәтен яба һәм «СССР мөселманнары диния нәзарәтләренең турыдан-туры үз вазифаларын башкару мөмкинлекләре юк, алар дөнья җәмәгатьчелеге каршында совет хакимияте өчен вөҗдан иреге символы булып хезмәт итә, большевикларның дингә каршы сәясәтен каплап тора», дип ачыктан-ачык белдерә.

Хакимиятләр Үзәк Диния нәзарәтендә дә Кырым сценарие кабатлану ихтималын аңлый (уйлап чыгарылган «Диния нәзарәте турындагы» эштә кайбер Үзәк Диния нәзарәте әгъзаларының Кырым сценариен кабатларга теләве искә алына). 1935 елда мәчетләрне күпләп ябу һәм дин әһелләрен кулга алу сәбәпле, Үзәк Диния нәзарәтен ябуны Кашшаф Тәрҗемани дә тәкъдим итә. Большевиклар дөнья җәмәгатьчелеге каршында

вөждан ireген буучы булып күренергә теләми: яшь дәүләткә тулы изоляция, гражданнарын ээзәрлекләү иле имиджы түгел, союзник һәм партнерлар кирәк була.

СУГЫШ. БАРЫСЫ ДА ҖИҢҮ ӨЧЕН ҺӘМ ДИН ӨЧЕН ФОРСАТ

Мөфти Габдрахман Рәсүли хакимият һәм дин арасындагы мөнәсәбәтләрнең берникадәр җылынуына ничек карый? Француз киңәшчесе һәм ислам белгече Александр Беннигсен болай дип раслый: «1942 елның июлендә Россиянең Европа өлеше мөфтие Габдрахман Рәсүлев Сталин белән элемтәләрне яңартуны үз өстенә ала. Мөселманнарның фашистларга каршы сугышта ярдәм күрсәтү вәгъдәсе бәрабәренә дингә каршы пропаганда бөтенләй юкка чыгарылмаса да, һәрхәлдә, беразга туктап тора, Совет дәүләте белән рәсми ислам арасындагы мөнәсәбәтләр нормальләшә».

Әлбәттә, совет чынбарлыгында «Сталин белән элемтәләрне яңартуны» да бары тик маршал Жуков кына үз өстенә ала алгандыр (Сугыш вакытында төзелгән СССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы Дини культлар эше буенча совет – илдә хөкүмәт белән дин әһелләре арасында элемтә урнаштыруның бердәнбер каналы була – ред.иск.). Шулай да мөфти Рәсүлинең килеп туган форсаттан файдаланырга тырышуы – бәхәссез. Әлбәттә, рөхсәт ителгән, юл куелган чикләрдә. Бернинди дә күпләп яңа мәхәлләләр ачу һәм элек тартып алынган мәчетләрне кире кайтарулар булмый.

Әмма Габдрахман Рәсүли Үзәк Диния нәзарәтендә репрессия елларында җимерелгән идарә вертикален казый һәм мөхтәсибләр аша, өлешчә генә булса да, торгызуга ирешә. Икенче яктан караганда, нәкъ менә сугыш вакытында Диния нәзарәте үзәк функцияләрен югалта – 1943 елда Кавказ арьягында, Урта Азиядә, Кавказда диния нәзарәтләре төзелә. Ташкент совет мөселманнары үзәгенә әйләнә.

Хәер, иң мөһиме оештыру моментлары түгел. Иң мөһиме – барлык дин вәкилләре өметләнгәнчә, илдә вөждан, дин ирекен кайтарачак җиңүгә ирешү.

СУГЫШТАН СОҢ. ҮЛЕП БАРУЧЫ КАРТЛАР КОЛЛЕКТИВЫМЫ?

Көтелгән өметләр акланмый. Дингә каршы сәясәтнең кырыслануы 1948 елның апрелендә үк башлана. Ул чакта Дини культлар эше буенча совет урыннарда үз вәкаләтендәге оешмаларга инструкция юллый. Анда Совет «дини мәхәлләләрне теркәүне катгый рәвештә тыюны тәкъдим итә». Шул ук елда МҮДН СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәте итеп үзгәртелә һәм яңа мәхәлләләр ачу, руханиларга матди яктан булышу, дини мәктәпләр һәм курслар оештыру хокукыннан мәхрүм ителә... «Ул бары тик дини-догматик мәсьәләләрне хәл итү, дин әһелләрен эшкә билгеләү, мәчетләрне һәм намаз йортларын исәпкә алып бару хокукын гына саклап кала. Фактта бу җәмгыять белән араларны өзүне һәм мәхәлләләрнең үлеп баручы картлар коллективына әйләнә баруын аңлата»**.

Рәсүлигә тиешле бәяне бирергә кирәк: хәтта шундый кырыс шартларда да ул үзендә иманны һәм дин тотучыларның мәнфәгатьләрен якларга көч таба. Гомерен куркыныч астына куеп, ул шәһәдәтнамә – мәхәлләнең булу-булмавына бәйсез рәвештә йола башкару хокукын бирүче таныклыклар (мондый документны рәсми рәвештә теркәлгән мәхәллә җитәкчеләре генә ала алган) тапшыра. Шундый 917 таныклык бирелә. БАССРда Дини культлар эше буенча совет вәкиле җитәкчелеккә болай дип хәбәр итә: «Рәсүлев үзенең гамәлләре белән теркәлмәгән дини җәмгыять һәм төркемнәрнең күбәеп китүенә ирек бирә, ул мөселман халкы арасында кичектергесез башкарылырга тиешле дини йолаларны үтәү хокукы бирә торган таныклыкларны бернинди тикшерүләрсез тарата, бөтен дини төркемнәрне еллык календарьлар белән тәэмин итә».

СУГЫШТАН СОҢ. ТЫЕП БУЛМЫЙ ТОРГАН ИМАН

1940 нчы еллар азагында Татарстанда кирәкле дини йолаларны үти торган биш йөзгә якын санитар мулла булачак (шул ук вакытта нибары 16 мәчет эшли). Ә Казанда гамәлдәге бердәнбер Мәрҗани мәчетендә «касса» – муллаларга «хезмәт хакы» түләү һәм мохтаҗларга ярдәм итү өчен үзара ярдәм төркеме эшли. Мөфти Рәсүли теркәлмәгән мәхәллә җитәкчеләре белән дә элемтәдә тора, алардан кертемнәр җыя һәм, хәленнән килгәнчә, традицион йолаларны үтәүдә дин тотучыларның хокукларын якларга тырыша.

Мәгълүм ведомство кураторлары мөфтинең һәр адымы турында, әлбәттә, белеп тора. Ләкин аның күп инициативаларына бармак аша гына карый, күрәсең, аларда социалистик җәмгыять өчен куркыныч күрмиләр. Өстәвенә, Рәсүлинең авыр сугыш чорында ил каршындагы хезмәте, абруе аның мөстәкыйль гамәлләр кылу хокукын чикләргә мөмкинлек бирми. Хәер, бу хакимияткә дингә каршы катгый сәясәт алып барырга комачауламый. Мөфтинең Диния нәзарәте каршында дин курсларын ачу турындагы үтенечен колак салмыйлар, органнар диндарларның мәчет ачу турындагы бер генә мөрәҗәгатен дә канәгатьләндерми...

Әмма 1948 елда Казанда Ураза бәйрәме намазына Мәрҗани мәчетенә һәм тагын биш урынга 23 меңнән артык кеше килә. Ислам дине яшәвен дәвам итә.

Габдрахман Рәсүли моның өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли.

** А. Ю. Хәбетдиновның «Лидеры российских мусульман и мусульманок в Российской империи и СССР (XIX–XX вв.)» хезмәтен кара.

ХАКИМИЯТНЕ ТӘНКЫЙТЬЛӘГӘН ГАЛИМ



Илдус Заһидуллин

Беренче рус инкыйлабыннан соң яңа татар әдәбияты белән янәшә формалашкан әдәби тәнкыйть фәне нигезләрен энциклопедик белемгә ия булган фәлсәфәче, әдәбиятчы, тел белгече, тарихчы һәм журналист Җамал Вәлиди эшләп чыга. Галим санап үтелгән һәр өлкәдә үзенең җуелмас эзен калдыра.

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы
922 2022

ИЖ-БУБЫЙ МӘДРӘСӘСЕ ШӘКЕРТЕ

Җамал (Җамалетдин) Вәлиди 1887 елның 12 октябрендә Казан губернасының Тәтеш өязендә урнашкан Апас авылында Җәлалетдин мулла гаиләсендә дөньяга килә.

Бер яшь чагында әтисе үлеп китә, малайны әнисе тәрбияли. Ун яшькәчә Җамал туган авылында укый. Кечкенәдән кызыксынучан, китап укырга һәвәс булып үсә. Соңрак 8-9 яшьлек чагында Фатыйх Халидинең «Рәдде бичара кыз» пьесасын кат-кат укыганын искә ала. Аннары Иж-Бубый авылы мәдрәсәсендә укый. Ул Иж-Бубыйга баруының сәбәбен, Бәйрут университетының фәлсәфә факультетын тәмамлап, туган авылында ирләр һәм кызлар мәдрәсәләренә нигез салган мәшһүр мөгаллим Габдулла Бубыйның «Хакыйкать» исемле хезмәтен укып, андагы фикерләрне иясенең үз авызыннан ишетергә теләве белән аңлата. Вәлиди татар зыялылары әзерләү максатында төзелгән укыту программасын үзләштерә, илнең төрле почмакларыннан Иж-Бубыйга килгән яшүсмерләр һәм мәсләктәшләре белән аралаша.

Мәдрәсә тәртибе буенча, укып бетергән гыйлемле егетләр өч елга биредә укытырга калдырылган. Җамал да, укуын тәмамлагач, мәдрәсәдә укытучы һәм эчке эшләр мөдире вазифаларын башкара. Ул бу уку йортының башка җәдид мәдрәсәләрдән үзенең хөрлеге, дөньявилыгы, мөстәкыйльлеге белән аерылуын, хәтта башкаларда мөдәррисләр белән шәкертләр арасында аңлашылмаучылыклар килеп чыгып, забастовкалар ясалып торганда да мәдрәсәнең тыныч кына тәрәккый итүен дә искә ала.

1909 елдан кадимчеләр язган шикаятьләр аркасында мәдрәсәгә полициянең игътибары арта. Җамал Вәлиди үзе эшләгән елларда, полиция бәреп кереп мөгаллимнәрне кулга алмасын өчен, сакта торганы турында искә ала.

Иж-Бубый мәдрәсәсендә укыганда үзе төзегән тормыш программасы хакында Вәлиди остазы вафаты уңаеннан язган мәкаләсендә болай дип шәрехли: «Вятка губернасының караңгы бер почмагында чирмешләр вә арлар арасында утырган уртача гына бер авылны бервакыт Русия мөселманнарының мөһим бер гыйлем мәркәзе хәлено китергән, саф вә пакь булган хәлдә дөньядан үткән Габдулла Бубыйның рухы алдында, аның бер шәкерте булу сыйфаты белән түгел, бәлки татар дөньясын каплап алган калын караңгылык эчендә беренче шәмне күтәреп чыккан Бубыйларның артыннан баручы бер кеше булуым сыйфаты белән баш иям».

ЖУРНАЛИСТ ҺӘМ ПУБЛИЦИСТ КАЛӘМЕ

Вәлиди тиздән туган авылы кызы Ләйләҗиһанга өйләнеп башлы-күзле була һәм Оренбургка күченә. Биредә «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. Татар фикри мәркәзенә әверелгән шәһәрдәге татар җәмгыятендә сөргән күтәренке рухи атмосфера яшь егетнең иҗтимагый активлыгына уңай йогынты ясый. Биредә «Хөсәения»гә укытырга килгән татар җәмагать эшлеклеләре, иҗат әһелләре белән таныша. Шулай ук шәһәрдә нәшер ителә торган «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы мөхәррирләре Фатыйх Кәрими һәм Риза Фәхретдин, редак-

Фотолар автордан алынды

цияләрдә эшләүчеләр белән якыннан аралаша. Татар вакытлы матбугаты битләрендә йөзләрчә мәкалә бастыра. Кызганычка, Җамалның журналистлык мирасы әлегәчә өйрәнелмәгән диярлек, шул сәбәпле аның бу өлкәдәге эшчәнлеген тулысынча күзаллап бетереп булмый. Шулай да билгеле булганнары буенча берничә юнәлеш анык күренеп тора.

Ул яңа басылган әдәби әсәрләр, шул исәптән Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев һ.б. иҗат әһелләре турында күләмле мәкаләләр язып, татар профессиональ тәнкыйтенә нигез сала. Вәлидинең интеллектуаль потенциалын күргән җитәкчеләр егетне 1915 елда «Вакыт» һәм «Шура» редакцияләренә хезмәткәр итеп чакыра. Соңрак ул «Вакыт» газетасында мөхәррир вазифасын да башкара. Өлкән каләмдәшләре Вәлидигә киләчәктә дә тәнкыйть мәкаләләрен язарга тәкъдим итә. Аның каләменә әсәрнең яңалыгын билгеләү, башка хезмәтләр белән чагыштыру, гомумиләштерүләр, шулай ук авторларга карата уңай мөгамәлә хас. Журналист шулай ук татар матбугаты турында күзәтүләр дә бастыра. Вәлидинең тагын еш мөрәҗәгать иткән темалары – татар теле, иҗтимагый фикер, милли мәгарифнең һәм милләтнең киләчәге.

ТАТАР МИЛЛӘТЕНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ

Татар вакытлы матбугатында милләтнең алгарышын тәэмин итү һәм аның киләчәге турындагы фикер алышуда Җамал Вәлиди махсус хезмәтләр язып та катнаша.

«Татар әдәбиятының барышы» исемле 1912 елда язылган китабында автор туган халкының киләчәген тәэмин итү өчен дини схоластикадан котылып, фән һәм әдәбият дөньясына йөз белән борылырга кирәклек, шулай ук иҗтимагый һәм мәдәни тормышны европалаштыру турында сүз алып бара.

Вәлиди 1914 елда, моңарчы матбугатта бастырган мәкаләләрен гомумиләштереп һәм фикерен тагын да тирәнәйтеп, «Милләт һәм миллият» исемле китап нәшер итә, бу гыйльми хезмәтендә теоретик буларак та, фәлсәфәче буларак та ачыла.

Вәлиди милләт оешуны закончалыклы күренеш дип бәяли. Милләтнең бердәмлеген тәэмин итә торган мөһим сыйфатлар дип тел һәм дин берлеген, кардәшлек һәм уртак традицияләрне (гадәт, милли риваять, хорафатлар, тарихи хатирәләр) һәм уртак Ватан булуны атый. Аларның милли бердәмлеккә төрле дәрәҗәдә тәэсир иткәнлекләрен дә әйтергә онытмый. Аныңча, милли берләшү өчен кардәшлек, тел факторы белән чагыштырганда, ул кадәр мөһим түгел, шулай ук дини институтлар да милли оешмаларны алыштыра алмый. Милләтнең мөһим сыйфатлары буларак галим туган тел һәм бигрәк тә милли әдәбиятны билгеләп үтә. Чөнки нәкъ менә әдәбият халыкның фәлсәфи, иҗтимагый, фәнни һәм әдәби фикерен үзендә туплый.

«Хөсәения» мәдрәсәсе укытучылары. Җамал Вәлиди – басып торучылар арасында сулдан өченче. Оренбург, 1913 ел.

Җамал Вәлиди хатыны Ләйләҗиһан ханым белән.

Галим беренче рус инкыйлабы һәм аннан соңгы елларда татар җәмгыятендә иҗтимагый барышны күзәтүне «Нур» газетасында куелган «Нинди телдә язарга?» дигән бәхәстән башлый. Исмәгыйль Гаспралы тарафдарлары булган бер төркем җәдидчеләр, барлык Россия мөселманнары өчен уртак язма тел кирәк, ди. Ә Вәлиди һәм аның яклылар, басмалар Казан шивәсендә, гади халык аңлый торган телдә нәшер ителергә тиеш, дигән фикерне алга сөрә. «Казан шивәсе» дигәндә, Казан арты төбәгендә яшәгән халыкның сөйләм теле түгел, Урта Иделнең уң һәм сул ярларында яшәгән татарларның туган теле күздә тотылган.

Тел бәхәсенең милли мәсьәләләргә күчүен һәм фикерләрнең төрлелеген автор Риза Фәхретдин һәм Фатыйх Кәриминең туган телне «төрки тел» дип атау ягында булалары, Әхмәтһади Максудиның, татар телен мөстәкыйль тел дип таныган хәлдә, «татар» этнонимын кулланмавы мисалында сурәтли.

XX гасыр башында башкортларның татар әдәби теленнән файдалануын һәм грамматикалары булмавын күздә тотып, Вәлиди татар милләте составына Идел буенда яшәгән татарлар, мишәрләр һәм башкортлар керәчәк, дип яза. Алар шәһәргә килгәч, ягъни мәдәниләшкәч, телдәге вак аерымлыклар тәмам бетәчәк, дип фаразлый.

Милләт булып оешу юлында татарлар алдында торган мөһим бурычларга тукталып, галим ике юнәлештә тырышырга кирәклеген искәртә. Беренчесе – милләтне саклау өчен заманга ярашлы милли мәктәп, әдәбият һәм сәнгатьне үстерергә кирәк. Икенчесе – Русия мәмләкәтенең чын гражданы булу өчен рус мәктәбе, аның әдәбияты белән азыкланырга кирәк.

Сүзен дәвам итеп, хөкүмәтнең, безнеkеннән аермалы буларак, бер генә максаты бар, ди: илнең бөтенлеген, куәтен тәэмин итү. Хакимият рус булмаган халыкларның милли теләкләрен санга сукмаган шартларда гамәлдәге кануннар мөмкинлек биргән кадәр милли, иҗтимагый һәм мәдәни хәрәкәтләр оештырырга, инициатива күрсәтеп, үзебез өчен эшләргә һәм үз-үзебезне алдынгы итәргә кирәк, дигән фикерне җиткерә.

Вәлиди милли үсеш юнәлешендә диннән киңрәк файдалану кирәклегенә басым ясый. Дин вөҗдан эше булганлыктан, хөкүмәт һәм хаким милләтләр аңа ул кадәр зур киртәләр куя алмый. Мәхкүм милләтләр, бу мөмкинлектән файдаланып, дин күләгәсендә мәктәпләр, әдәбиятлар, һәртөрле җәмгыятьләр торгыза, шул рәвешле динне милли үсеш юлына хезмәт иттерә ала, дигән фикерне әйтә. Татарлар әлегә кадәр диннең иҗтимагый халәтеннән аз файдаланды, дип тә искәртә.

Вәлиди үзенең 1916 елда язылган «Шәрыктан Гаребкә» исемле күләмле мәкаләсендә татар мәдәниятенең төп үсеш юнәлеше дип Көнчыгыш цивилизациясе белән хезмәттәшлекне атый. Биредә сүз алдынгы фән казанышларын, җитештерү һәм хуҗалык итү алымнарын үзләштерү юлы белән алдынгы мәдәниятле милләт төзү турында бара.

СОВЕТ ИЛЕНДӘ ГЫЙЛЬМИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Вәлиди 1918 елның 15 гыйнварына кадәр Оренбургта мөгаллимлек һәм редакторлык эше белән шөгыльләнә. Аннан соң Казанга килә һәм «Корылтай» газетасы редакциясендә эшли.

Казан каласы Гражданнар сугышы аренасына әверелгәч, 1918 елның декабреннән

Арча кантонының Кышкар мәктәбендә укыта, киләсе уку елында Тәтеш шәһәрендә мәктәптә эшли. 1921 елның сентябреннән Казанда ачылган Шәрык академиясендә (1922 елдан – Көнчыгыш педагогика институты) – мөгаллим һәм аның каршында эшләгән рабфакта укыту бүлеге мөдире булып тора. 1923–1924 елларда Җамал Вәлиди ТАССР Җир эшләре халык комиссариатында нәшрият бүлеге мөдире ярдәмчесе һәм Терминология комиссиясе рәисе дә була, биредә китап-белешмәлекләр тәрҗемә итә.

Бу елларда да Вәлиди әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүен дәвам итә, әмма саллы фәнни хезмәтләрен татар иҗтимагый тарихы һәм тел гыйлеме буенча яза.

1923 елда Мәскәүдә дөнья күргән «Очерки по истории образованности и литературы поволжских татар (до революции 1917 года)» исемле хезмәтендә татар иҗтимагый фикере үсешенең төп этапларын билгели. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында аның үсешенә зур өлеш керткән шәхесләргә кыскача бәяләмәләр бирә.

Оренбургта яшәгәндә тел буенча башлаган эзләнүләрен дәвам итеп, галим яңа фәнни үрләр яулый. 1919 елда «Татар теле грамматикасы» китабын бастыра. Үзенең Нократ, Глазов, Карин татарлары диалектларына багышланган хезмәтләре белән татар диалектологиясенә нигез сала. Аның лингвистик эзләнүләре үзәгендә әдәби тел мәсьәләсе, аны эшләү, үстерү турында кайгырту тора. Шушы мөһим проблемага багышлап, ул «Татар телен эшләү мәсьәләсе», «Телебезнең үсү тарихыннан», «Төрек-татар телләренең язмышлары», «Галимҗан Ибраһимовның тел мәйданындагы хезмәтләре» кебек махсус теоретик хезмәтләр яза.

Җамал Вәлиди «Татар теленең тулы сүзлеген» эшләп чыга. Аның сүз башында әдәби телнең үсеше, формалашуы мәсьәләсен яктырта.

1927 елны ТАССРның ВКП(б) Өлкә комитетының III пленумына адресланган татар зыялыларының мөрәҗәгатенә кул куя. 82 кеше имзалаган бу күмәк протест хатында латин шрифтын кертүне административ юл белән түгел, ә милли интеллигенция фикерен исәпкә алып эш итү хакында язылган була.

«СОВЕТ ХАКИМИЯТЕНЕҢ СӘЯСӘТЕ... БЕЛӘН КАРШЫЛЫКЛАРЫМ БАР»

Җамал Вәлиди, 17 татар язучысы, галиме, журналисты һәм мөхәррире белән бергә, 1931 елның 6 маенда кулга алына. Алар революциягә каршы фикер тудыру максатыннан солтангалиевчеләр белән элемтә урнаштырган төркем оештыруда гаепләнә.

Төрмәдә вакытта тикшерүчеләр Вәлидигә үзенең сәяси карашларын кәгазьгә төшерергә һәм кайбер коллегаларына характеристика язарга тәкъдим итә. Күрәсең, баштарак аңа карата җәза кулланылмаган. Әйтергә кирәк, Вәлидинең Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Габделбари Баттал, Ибраһим Биккулов, Галимҗан Шәрәф турында язган бәяләмәләре «Очерки по истории образованности...» китабының дәвамы сыман кабул ителә. Вәлиди аларның берсе турында да совет хакимияте бәйләнерлек сүзләр язмый. Шул ук вакытта бу текстлар бүгенге галимнәргә XX йөз башы татар мәдәни тормышы барышын өйрәнүдә искиткеч кыйммәтле чыганак булып тора.

Җамал Вәлиди төрмәдә язылган «Минем совет хакимиятенең хуҗалык-сәяси мәсьәләләр буенча сәясәте белән аңлашылмаучылыгым һәм каршылыкларым бар» дигән язмасында большевиклар хакимиятен тәнкыйтьли.

Галим кайбер катлам гражданнарга шикләнеп карау, кирәкмәгән кулга алулар, артык репрессияләргә үзенең тискәре мөнәсәбәтен белдерә. Шушы уңайдан, хакимияткә лояль булган интеллигенцияне илгә зыян китерүчеләрдән аера белергә кирәк, дип басым ясый.

Галим колхозлар оештыру кампаниясенә, кулакларны сыйныф буларак юкка чыгару сәясәтенә дә тәнкыйди карашын җиткерә. Күмәкләшүне аерым төбәкләрдә уткәрергә, кулакларны читкә сөрүдән бигрәк, колхозга җәлеп итәргә кирәклеге, дошмани мөнәсәбәттә булганнарын гына сөрү хакында искәртә.

Шулай ук дингә каршы кысулар булырга тиеш түгел, солтангалиевчелек – утопия, төрки халыкларны бер дәүләткә берләштерү мөмкин эш түгел, дип белдерә.

Әдәби яктан яхшы эшләнгән һәм элекке тормыш турында язылган әсәрләрнең нәшер ителергә тиешлеген әйтеп, махсус оешмаларның фәнни хезмәт һәм әдәби әсәрләрдә артык күп контрреволюция табуына һәм иҗат әһелләрен җәберләүләренә каршы чыга.

Җамал Вәлидинең тезислар рәвешендәрәк язылган бу җөмләләре гражданлык батырлыгы буларак кабул ителә.

Әйтергә кирәк, кулга алынган кешеләрнең берсе дә гаебен танымый, ләкин һәрберсенә карата 1932 елның 11 маенда хөкем карары чыгарыла. Вәлиди 5 елга хөкем ителә. Ул туктаусыз сорау алулар, кыйнауларга, мыскыл итүләргә чик кую өчен, төрмәнең өченче катындагы тәрәзәдән сикерә. Каты имгәнә, кулаякларын сындыра, ләкин исән кала. Тоткын төрмә хастаханәсенә күчерелә. 1932 елның 30 ноябрендә 45 яшендә Җамал Вәлидинең гомере өзелә. Җирләнгән урыны билгесез.

КАЗАНДАГЫ АЛ МӘЧЕТ

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы
922 2022

Нәфис Көнчыгыш бизәкләре, манара тирәли тимердән ясалган купшы челтәр рәшәткә һәм төрле архитектура өслүбләренең бер-берсенә ярашуы... 1906 ел башында Яңа Татар бистәсендә мөселманнар өчен әнә шундый затлы мәчет ачыла. Халык аны Ал мәчет дип атый башлый. Ә империянең рәсми кәгазьләрендә 10 нчы җәмигъ мәчете дип теркәп куела.

Фото: Әскәр Сабиров

Татарстан башкаласының әлеге тыйнак почмагына килеп эләккән сирәк туристларга беренче гильдия сәүдәгәре Муса Апанаевның, яраткан кызы Зөбәйдәне югалтканнан соң, аның мирас акчасына мәчет төзетергә сүз бирүе турындагы сагышлы да, матур да риватьне еш сөйлиләр. Сәүдәгәр сүзендә торган, Казанда өченче таш мәчет пәйда булган. Риваять дөрес, тик сүз Ал мәчет турында түгел, ә 19 нчы гасыр башында ук булган Тәбәнәк Бохара мәчете – Тәбәнәк мәчет турында бара. Дөрес, борынгы иман йортын бөтенләй сүтеп ташламаганнар, бәлки бик нык үзгәртеп корганнар гына, дигән фикер дә бар.

ТӘБӘНӘК БОХАРА МӘЧЕТЕ УРЫНЫНДАГЫ МАНАРА

Ал мәчетне үз хисабына беренче гильдия сәүдәгәр Мөхәммәтсадыйк Галикәев төзеткән. Ул үзенең капиталы белән (аның Кунак сараендагы бер кибетенең генә дә еллык товар әйләнеше бер миллион сумнан артык саналган) генә түгел, хәйрия эшчәнлеге белән дә таныла. «Ярлы мөселманнарга ярдәм итү җәмгыяте»нең мактаулы әгъзасы, рус-татар училищесының попечителе була, үз гомерендә дистәдән артык мәчет төзелешенә акчалата ярдәм күрсәтә. Мөхәммәтсадыйк Шиһабетдин Мәрҗанинең дусты, аңа «Мәрҗания» мәдрәсәсен төзергә акча белән ярдәм иткән этисе Мөхәммәтсафа юлын дәвам итә.

Күрәсең, архитектор Яңа Татар бистәсендә яңа гыйбадәтханәне проектлаганда алдагысының сыйфатларын да саклап калган. Һәрхәлдә, Ал мәчет йөзендә Урта Азия архитектура мотивлары шәйләнә, һәм ул шулай ук зурлыгы белән дә шаккатырмый, шуңа күрә дә элеккеге мәчет Тәбәнәк Бохара мәчете дип аталган.

Гади кеше өчен тагын бер сер – Ал мәчет исеме. Ләкин монда барысы да бик гади. Мәчет төзелгәннән соң, аны алсу төскә буяганнар. Йөз елдан артык вакыт эчендә гыйбадәтханәне берничә тапкыр башка төсләргә буясалар да, беренче елларда мәхәллә кешеләре биргән мәчет исеме кала биргән. Бүген дә диварлары һәм манарасы кызыл кирпечтән булуга карамастан, элеккеге Ал мәчет исеме шактый еш кулланыла.

ИМПЕРИЯ БАСЫМЫ АСТЫНДАГЫ ҖӘДИДЧЕЛЕК САБАКЛАРЫ

10 нчы Җәмигъ мәчете һәм аның каршында ачылган мәдрәсәдә баштан ук яңа ысул белән укыталар. Шәкертләр биредә Коръән, дин фәннәрен генә түгел, мантыйк, арифметика, грамматика, канун белеме, гарәп грамматикасы тарихын да өйрәнә. Ал мәчетнең татарлар өчен танылган рухи үсеш үзәгенә әверелүе җәдидчелек тарафдары – мулла Салихҗан Галиевның* казанышы була. Мәдрәсә үзе дә Салихҗанның этисе – бай сәүдәгәр акчасына төзелә. Мәчетне салдырган Мөхәммәдсадыйк Галикәев тә Галиевның туганы, ә иң мөһиме фикердәше була.

Белем, акча һәм карашлар берлеге искиткеч нәтиҗәләр бирә. Бирегә Казан, Түбән Новгород, Сембер, Пенза губерналарыннан белем алырга киләләр. Әмма халыкка мәгърифәт нурын тараткан мәчет һәм мәдрәсә хакимиятләргә берничек тә ошый алмый. Алар җәдидчелекне хөрлек тәрбияли, ә бу халыкны империягә каршы берләштерә ала, дигән фикергә килә. Галиев үзенең агарту эшчәнлеге өчен җәзасын ала – 1908 елда, Җәмигъ мәчете мәхәлләсендә яңа ысул белән укыту курслары оештырганга, аны Вологда губернасына сөрәләр. 19 нчы гасыр азагына караган полиция документларының берсендә: «Галиевлар гаиләсеннән, аларның фикер сөрешен истә тотканда, татар халкын ассимиляцияләү юнәлешендә зур тырышлык көтәргә ярамый», – дип билгеләп үтелә.

Бәхеткә, Ал мәчеттә җәдидчелекне юкка чыгара алмыйлар. Салихҗан Галиев эшен мулла Мөхәммәтгабдулла Абдулбадыйков дәвам итә. 1910 елда ук мәчет каршындагы мәдрәсә шәһәрдәге иң зур уку йортларының берсе санала: биредә дүрт губернадан 90 шәкерт белем ала. Мәхәллә кешеләре саны да артуга бара. Октябрь революциясе алдыннан 10 нчы җәмигъ мәхәлләсендә 500 ир-ат һәм 474 хатын-кыз санала.

ЯҢАРЫШ ЯРЫМАЕ

Барысы да совет чорында – 1931 елның 22 июлендә тәмамлана. Бу көнне Татарстан ҮБК Президиумы карары белән Ал мәчет ябыла. Бинасын мех заводына бирәләр, монда берникадәр вакытка профилакторий урнаша. Яңа хакимияткә, әлбәттә, манара кирәкми. Әмма аны шартлатмыйлар, ләкин чатырын җимерәләр, аның иң матур өске өлешен сүтәләр...

Алтмыш биш елдан соң мәчетне дин тотучыларга кире кайтаралар. Бераз алдарак, совет хакимиятенең соңгы елында, Ал мәчетне республика әһәмиятендәге архитектура һәйкәле дип табалар. Ләкин манара өстендә яңадан ярымай балкыганчы әле тагын дистә елдан артык вакыт узачак.

Бүген Ал мәчет каршында, узган гасыр башындагы кебек үк, мәдрәсә (Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге Югары мөселман мәдрәсәсе) эшли. Бу Казанда советлардан соңгы чорда ачылган беренче мәдрәсә**. Аны тәмамлаучылар арасында Вәлиулла хәзрәт Якупов, Чувашия, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе мөфтиләре, Ханты-Манси автономияле округы, Самара өлкәсе, Татарстан һәм Россиянең башка танылган мөселман лидерлары бар.

Адрес: Казан, Мәҗит Гафури ур., 67.

Ал мәчетнең татарлар өчен танылган рухи үсеш үзәгенә әверелүе җәдидчелек тарафдары – мулла Салихҗан Галиевның казанышы була.

** Салихҗан Галиевның бертуганы Галимҗан Баруди (Галиев) соңрак Россиядә бөтен халык тарафыннан сайлап куелган беренче мөфти була – ред. иск.*

*** Беренче елларда Кабан арты мәчетендә урнашкан була.*

ЯҢА ИШТИРӘКНЕҢ ЯҢА ЮЛЫ



Фото: Александр Ефремов

ИШТИРӘК

Егерме дүрт градус суыкта сәфәргә кузгалдык. Юл озын – Лениногорск районының Яңа Иштирәк авылына кадәр Казаннан 300 чакрым тирәсе. Башта икеләнеп тә калган идек, әллә бармаска инде? Ләкин бер җыенгач тәвәккәлләдек. Авыл халкы да киләсебезне белеп, көтеп тора. Вәгъдә – иман бит.

Руфия Фазылова

ИҢ ЗУР КУАНЫЧ – БАЛАЛАР

Казаннан килгәндә башта Иске Иштирәк кала. Ул данлыклы «Бәкер» шифаханәсе белән тоташкан. Ә Яңа Иштирәк аннан өч чакрым ераклыкта урнашкан. Карлы-бозлы юл аша авылга килеп җиттек. Ялтырап кояш чыккан иде. Иң беренче шуңа игътибар иттек: биредә урамнар киң, гомумән, авыл җәелеп урнашкан. Яңа Иштирәк белән танышуны мәдәният йортыннан башладык. 2000 елда салынган бина ул. Бик кызганыч, шуннан бирле бер тапкыр да ремонт күрмәгән. Нәтиҗәдә, тәрәзәләрдән җил уйный, стеналарның буяулары купкан... Югыйсә хуҗа кулы да күренеп тора – гөлләр үсеп утыра, фойеның бер ягында музей почмагы ясалган. Тик бинаның таушалган булуы бу матурлыкны боза.

Башта игътибар итмәгән идем – мәдәният йортының ишегеннән кергәч тә бер почмакта балалар аяк киемнәре тезелеп киткән. Авыллар буенча күпме йөреп, мондый хәлне күргән юк иде.

– Әллә балалар биредә укыймы? – дип куркып кына сорадым.

– Укымый. Алар монда көн саен килеп бию, кул эшләре белән шөгыльләнә, – диде мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Ландыш Шәйхетдинова. – Әле менә кечә балалар белән мәдәният йортын бизәдек. Яңа ел концертына әзерләнә башладык, яңа биюләр өйрәнәбез. Балалар бик теләп йөри. «Өй эшләрегезне карарга вакытыгыз калмый», – дип, еш кына үзебез кайтарып җибәрәбез.

Яңа Иштирәктә бүген 217 хуҗалык бар, 563 кеше яши. 18 нче гасырның икенче яртысында оешкан әлеге авылның тарихы, үткән юлы шактый кызыклы. Миллионер колхоз да була ул, урта мәктәп

тә салына, урамы-урамы белән яңа йортлар калка. Шунысы аяныч: авыл бүген үсүеннән туктаган. Урта мәктәптән башлангыч мәктәп калган, ә миллионер колхоз җирләре хәзер «Август» ҖЧҖ кулында. Шулай да Яңа Иштирәкне бетеп баручы авыллар рәтенә кертеп булмый: яшь гаиләләр шактый. Балалар бакчасына унике бала йөри. Ә башлангыч мәктәптә унике укучы белем ала.

Кайчандыр урта мәктәп булган белем йортына без дә бардык. 1961 елда төзелә башлап, 1968 елда гына сафка баскан мәктәп тыштан караганда бер дә тәэсирләндерми. Әмма эчкә узгач, фикер тулысынча үзгәрә: якты коридорлар, иркен сыйныфлар, биек түшәмнәр, зур тәрәзәләр... Күңелгә рәхәтлек бирә торган бер җылылык бар биредә.

– Өч ел элек белем йортыбыз тугызъеллыктан башлангыч мәктәпкә калды, – диде директор Алия Галимова. – Ул елны күрше Зеленая Роща авылы урта мәктәбенә кырык ике укучыбыз китте. Әлбәттә, бала саны җитә иде әле. Тик ике авылда да зур мәктәп калдырмаска хәл иттеләр. Балалар белән укытучылар да Зеленая Рощага күченде. Хәзер инде ияләндек, башта авыр булды. 2004 елда мәктәпкә зур капиталь төзекләндерү үткәрелгән иде. Ул чактагы директор Вәгыйзь Сәнатуллинга рәхмәт, компьютерлар да юнәтте. Шуның өчен дә белем йортыбыз сафтан чыкмады. Районда безнекеннән дә иртәрәк салынган мәктәп юк.

Әлбәттә, илледән артык бала укый торган төп белем бирү мәктәбен шулай башлангычка калдырулары кызганыч. Әле бу бинада рәхәтләнеп тагын дистә еллар белем алырга мөмкин. Ләкин бүген вазгыять шундый: яңарак салынган бинага өстенлек бирелә. Хәер, башлангычка калгач та, укытучылар төшенкелеккә бирелмәгән: сыйныфларны бикләп куймаганнар. Берсендә – шахмат сыйныфы, икенчесендә – балалар өчен ял бүлмәсе, өченчесендә актлар залы булдырганнар. Дүрт сыйныфка өч укытучы. Беренче, икенчеләр – бергә, өченче, дүртенчеләр дә бергә.

1
– Әле менә кечә балалар белән мәдәният йортын бизәдек, – диде мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Ландыш Шәйхетдинова.

2
1968 елда сафка баскан мәктәп тыштан караганда бер дә тәэсирләндерми. Әмма эчкә узгач, фикер тулысынча үзгәрә.

Алия Галимова исә дүрт сыйныфны да инглиз теленнән укыта.

Мәктәптә урнашкан музей аерым игътибарга лаек. Патриотик тәрбиягә йөз тоткан, шактый бай экспонатлы музей ул. Аның җитәкчесе – башлангыч сыйныфлар укытучысы Гөлфия Зәйниева.

– Мәктәптә «Туган якны өйрәнү» исемле түгәрәк тә эшли, – диде Гөлфия ханым. – Балалар авыл тарихын бик теләп өйрәнә. Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларыбызның язмышларын барлыйбыз. Сугыштан исән кайтучыларга да аерым почмак бар.

Гөлфия Зәйниева Бөек Ватан сугышында һәлак булган бабасы Зиннәт Гаффановның каберен эзләп тапкан. Бабасы 1942 елның 21 декабрендә Калинин өлкәсендә батырларча һәлак була. Шунда ук җирләнеп тә кала. Сугыш тәмамлангач, бу каберләрне Мәскәү өлкәсендәге туганнар каберлегенә күчерәләр.

– Бабай турында бер мәгълүматыбыз да юк иде, – диде Гөлфия Зәйниева. – Оборона министрлыгының Үзәк архивы мәгълүматлары «Халык хәтере» сайтына элента кенә бабайны эзләп таптык. Туганнар каберлегенә барып, туфрак та алып кайттык. Ул туфрак бүген мәктәп музеенда саклана. «Халык хәтере» сайты буенча тагын берничә шундый авылдашыбызның язмышын ачыкладык. Берсенең якыны табылгач, икенчесендә дә кызыксыну уянды. Әнә шулай итеп авылыбыз белән документлар өйрәндек. Моңа балалар да кушылды.

Авылда чынлап та патриотлар яши: музейда дистәләгән кешенең орден-медальләре, фронттан кайткан киемнәре саклана. Авыл кешеләре аларны үзләре бирегә алып килеп биргән.

КИЛЕН-КАЕНАНАЛЫ ЙОРТ

Авылларга баргач, матур гаиләләр белән танышасың да ихластан сөенәсең – традицияләрне саклаучы, үрнәк гаиләләр бар бит әле! Яңа Иштирәктә яшәүче Гыйбадуллиннар белән танышкач та шулай булды.

Бер түбә астында өч буын яши. Иң өлкән кеше Хатыйп абый сиксән өч яшен тутырган, хәләл җефете Әнисә апага җитмеш дүрт тулган, аларның уллары Ильяс, җәмәгате Миләүшә һәм өч малай. Малайларның икесе Чирмешән район үзәгендәге кадетлар мәктәбендә белем ала, төпчекләре Яңа Иштирәк балалар бакчасына йөри.

– Каенанам белән егерме дүрт ел яшәдем, – диде Әнисә апа. – Ә киленем белән уналты ел гомер итәбез. Әйтмәгәнем булсын, тату яшибез. Өлкәннәр яшьләр эшенә кысылмаса, яшьләр сабыр булса, бергә яшәү рәхәт ул.

– Аш бүлмәсендә кем хуҗа? – дим.

– Кемнең вакыты бар, шул хуҗа. Каенанам белән яшәгәндә аш-су әзерләү аның өстендә булды, чөнки без колхоз эшеннән кайтып кермәдек. Хәзер рольләр алышынды – яшьләр эштә, бабай белән без өйдә. Хәлдән килгәнчә тырмашабыз шулай.

3

Сыйныфларны бикләп куймаганнар. Берсендә – шахмат сыйныфы, икенчесендә – балалар өчен ял бүлмәсе, өченчесендә актлар залы булдырганнар.

4

– Мәктәптә «Туган якны өйрәнү» түгәрәге дә эшли, – диде Гөлфия Зәйниева.

5
Бер түбә астында өч буын булып яшәүче Гыйбадуллиннар гаиләсе.

6
Матурлык яратучы Гөлсинә Әхмәтова.

7
Авылның балалар бакчасы Яңа елга әзер.

Хатыйп абый белән Әнисә апа биш бала – дүрт кыз, бер малай тәрбияләп үстергән. Кызларның дүртесе дә гаиләләре белән Яр Чаллы шәһәрендә яши. Уллары Ильяс исә авылда, төп йортта калган.

– Традицияне бозмадым, татарларда төпчек малай әти-әни нигезен ташламаган, – диде Ильяс. – Кайчагында уйлап куям: шәһәрдә дә югалмаган булыр идек. Ләкин авылда калганга үкенмим – үзебез теләгәнчә яшибез. Каралты тулы мал-туар, эшкәртер өчен җирләребез бар. Йортыбыз иркен, әти-әни исән-сау, әлхәмдүлилләһ, бер дә зарланырлык түгел!

Гыйбадуллиннар күп итеп мал-туар асрый. Бүген хуҗалыкларында егерме мөгезле эре терлек бар. Фермерлык эшенә 2015 елда керешкәннәр.

– Тормыш алып барырга кирәк бит, – дип сүзен дәвам итте Ильяс. – Ул чакта дәүләт сыер терлеге алу өчен кайтарылмый торган субсидия бирде, аның суммасы 200 мең сум иде. Без менә шул акчаны алдык. Башта биш сыер булды, аннан сигезгә әйләндердек. Әни белән Миләүшә чиратлашып сыерларны сауды. Озакламый саву аппараты алдык. Шуннан эшләр җайланды инде. Терлек санын киметмәскә тырышабыз.

Ильяс – район янгын сүндерү оешмасы хезмәткәре, ә Миләүшә – Зеленая Роща урта мәктәбендә пешекче. Иртән эшкә киткәнче малларны карап, сыерларны савып китәләр. Үзләре әйткәнчә, хуҗалар әлегә «ял итә», ә кызу эш иртә яздан башлана.

– Утыз гектарлап җиребез бар, – диде Ильяс. – Үзебезнең ике пай җирен һәм берничә авылдашның пай җирен арендага алдык. Анда печән, иген чәчәбез. Үзебездән калган иген, печәнне аз булса да сатабыз. Җир эшкәртү өчен барлык техниканы да юнәттек. Рәсми рәвештә без фермер түгел, ә шәхси ярдәмче хуҗалык булып теркәлдек. 200 мең сум акчаны санамаганда, дәүләттән башка ярдәм алмадык. Үзебезгә үзебез хуҗа, бер оешма алдында да хисап тотасы юк.

Гыйбадуллиннар сөтне хуҗалыкларга сата. Авылдашлары да ала, шәһәргә дә илтеп бирәләр. Сөтләтә генә түгел, сораган кешегә катык, каймак, эремчек, корт та ясыйлар. Боларын яшь хуҗабикә Миләүшә эшли икән.

– Мин авыл кызы, – дип тыйнак кына елмайды Миләүшә. – Бөтен эшне беләм. Эремчек, кортны элек каенанам ясый иде. Хәзер аның рецепты буенча үзем эшлим. Безнең гаиләдә бөтен кешегә эш җитә. Ике улыбыз да зур ярдәмчеләр. Җәй көне әтиләре янынннан кайтып та кермиләр.

Чынлап та, әти кеше улларын кечкенәдән эшкә өйрәткән. Ундүрт, уналты яшендә генә булсалар да, үсмер малайлар трактор, комбайн йөртә белә, печән, салам җыюны да булдыралар. Уникe яшьләреннән өйдән чыгып киткәнгәме, өс-башларын карауда да мөстәкыйльләр икән.

– Авылда башлангыч мәктәп кенә калгач, улларыбызны укырга Зеленая Рощага йөртергә кирәк иде, – диде Ильяс. – Барыбер йөрисе булгач, кадетлар мәктәбенә бирергә кирәк, дип уйлаштык. Чирмешән район үзәгендәге әлеге белем йорты бик яхшы, бөтен мөмкинлекләр дә бар. Төп укыту программасы белән бергә, хәрби юнәлештә дә белем, тәрбия алалар. Бу бер дә начар түгел, чын ир-егет булып үсәләр. Малайларны дүшәмбе илтеп куям, шимбә барып алам.

– Улларыгызны бик иртә өйдән чыгарып җибәрү авыр булмадымы? – дим.

– Ничек кенә әле! Йортның бер ягында әни, икенчесендә хатын елады. Мин исә каралтыга чыгып күз яшьләрен сөрттем. Берәр айлап шулай елаштык. Аннан күндек инде. Хәзер исә икәү укыйлар, өйдән елмаеп озатабыз.

«НАЧАР УЙЛАРДАН КОТКАРА»

Алда әйтелгәнчә, Яңа Иштирәк 2000 нче елларга кадәр зур авыл булган. Бүген аның кайбер урамнары бөтенләй бушап калган. Гөлсинә апа Әхмәтова нәк шундый урамнарның берсендә яши. Каршыда – ярым ишелгән йорт, артта – болын, таулар, янда тагын буш йорт тора. Кышын буран дулаганда бигрәк күңелсездер монда...

Әбекәйнең ишегeн ачып кергәндә күңелгә нәк шундый уйлар килде. Тик Гөлсинә апа моңа бер дә аптырамый икән:

– Кем йөрсен монда, иптәшкә маэмаем бар, – диде ул.

Хуҗабикә мәрхүм җәмагате белән дүрт бала – өч кыз, бер малай үстергән. Ике кызы авылда икән, бер кызы шәһәрдә, ә бердәнбер улын җиде ай элек җирләгән.

– Улым кинәт үлде – йөрәге тотты, – диде әле җан ярасы төзәлмәгән ана. – Ирем дә шулай унбиш ел элек йөрәк белән китеп барды.

Күрәчәктер... Авыр уйлардан кул эшләре коткара. Иртәдән кичкә кадәр шулар белән утырам...

Гөлсинә апа алдынгы сыер савучы булган. Җиденче сыйныфны тәмамлагач, ундүрт яшеннән фермага төшкән ул. Шул вакытта ук кул белән унөч-ундүрт сыер сауган.

– Әле аппаратлар кайткач та, шактый еллар сыерларны кул белән саудым, – диде ул. – Аппаратны яратмадым. Тиз эшли идем, шуның өчен аппарат көйләп утырасым килмәде. Аннары инде механик мәҗбүриләп диярлек машина белән саварга өйрәтте.

Гомер буе эшләп, Гөлсинә апага «Хезмәт ветераны», бүтән исем дә бирмәгәннәр. Бөтен дан – колхоз җыелышларында мактау булган. (Әбекәй аны зарланып түгел, ә мин төпченгәнгә күрә әйтте.)

Гөлсинә апаның өе бик матур: стенага сәйләннән үрелгән картиналар эленгән, диван өстендә чигүле мендәрләр, урындыкта бәйләнгән япмалар... Һәм ул аларның барысын да үз куллары белән эшләгән. Бәйләү, чигүне кечкенәдән белсә, сәйләннән картиналар ясарга берничә ел элек өйрәнгән.

– Матурлык яратам, – диде Гөлсинә апа. – Һәм тик утыра белмим. Кулым бер дә буш торырга тиеш түгел. Бер-ике сәгать бәйлим дә картина ясарга утырам. Гел бер эш кенә туйдыра бит. Картинаны кызлар, оныклар сатып алып кайтып бирә. Эшләп бетергәч алып китәләр.

– Сәйләннән ничә картина ясадыгыз әле? – дим.

– И, санаганым юк, күп инде. Бер атна эчендә бер картинаны тәгәллим. Шул арада бәйлим дә бит. Ә менә чигү чиккәнем юк. Аңа күз кирәк. Чиккән әйберләрем бик күп, балаларга, оныкларга да бирдем. Әнә музейга да тапшырырмын әле, истәлек булсын.

Гөлсинә апа телевизор карарга бик яратмый. Ә менә газеталар укый. Ул үз дөньясында яши. Улын җирләгәнгәме, соңгы вакытта кул эшләрсез бер дә тормый икән. Әле мунчала да бәйли.

– Хәсрәтеңне бөтен кешегә кычкырып йөреп булмый, – диде ана кеше. – Шуның өчен дә үз дөньяма чумам: кул эшләре тынычландыра. Кызларыма, оныкларыма рәхмәт, ташламыйлар. Кызлар гел үзләренә чакыра. Аякта йөргәндә төп йортны ташлыйммы соң?! Монда гомер иттек, балалар үстердек. Өйнең һәр бүрәнәсе якын...

Саулык, озын гомер теләп саубуллаштык әбекәй белән. Сиздермәскә тырышса да, күңеле нечкә Гөлсинә апаның. Кызганыч, озак аралашып булмады аның белән. Караңгы төшеп килә иде, димәк, кайтыр юлга кузгалыр вакыт. Әллә ничек күңелгә якын булып калды.

...Әйе, бик суык көн иде. Әмма җирле халыкның тәмле теле, матур күңеле безне җылытты. Бу авылның иң зур байлыгы – аның кешеләре. Ерак сәфәрдән әнә шулай дип кайттык.

6

7

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Мәшһүр галимебез Ризаэтдин Фәхретдин бу якларны яхшы өйрәнгән. Ул Яңа Иштирәк авылына нигез салучы беренче кешеләр Иске Иштирәктән күчеп утырган дип саный. Һәм аның белән килешми мөмкин түгел.

1730–1760 нчы елларда Идел буенда халыкларны көчләп чукындыруның иң кызган чагы була. Менә шул чорда берничә гаилә монда килеп утырган булырга тиеш. Яңа Иштирәк авылы архив документларында беренче тапкыр 1785 елда телгә алына.

Тирәк – тупыл яисә биек үскән агач, ә инде иштирәк – пар тирәк, ягъни парлы тупылны аңлата.

Рәсим Хәбибуллинның «Яңа Иштирәк авылы тарихы» китабыннан.

ЭГОИСТ МӘХӘББӘТЕ (16+)

«Тугызынчы майда иртәнге якта Зөфәр Сабитов гаҗәеп төш күрә: ул япа-ялгыз ниндидер бөтенләй таныш булмаган дала буйлап бара. Япан кыр, такта кебек тип-тигез, иксез-чиксез...» Әмирхан Еникинең 1962 елда язылган «Рәшә» повесте әнә шулай башлана. Әсәрдә 1940 нчы еллар сурәтләнә. Төп герой – Зөфәр – совет сәүдәсе хезмәткәре, үзе турында гына уйлаучы эгоист зат. Ул хөр, җитеш һәм бай киләчәк турында хыяллана. Ләкин бервакыт Зөфәр дөньяга бөтенләй башка күзлектән караучы бер ханымны очрата... 1960 нчы елларда Еники тарафыннан иҗат ителгән образлар, җәмгыятьнең киләчәге турындагы фаразлар соцреализм тарафдарларының күңеленә хуш килеп бетми. Повесть зур бәхәсләр уята, әмма барыбер дөнья күрә һәм татар әдәбиятында мөһим әсәрләрнең берсенә әверелә.

Декабрь аенда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры сәхнәсендә «Рәшә» повесте буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы көтелә. Театр тарихында Еники әсәре буенча эшләнгән беренче спектакльне проза әсәрләрен үзенең оригиналь укуы белән аерылып торган режиссёр Айрат Җәббаров сәхнәләштерә.

23 декабрь 19:00, 24 декабрь 18:00
Г.Камал исем. ТДАТ, Казан, Татарстан ур, 1

ҮТӘЛГӘН ВӘГЪДӘ (12+)

Язучы Ромен Гари (Роман Кацев) тормышында барысы да була: хәрби очучы булып хезмәт итү, дипломат булып эшләү, башны югалтырлык романнар, әдәби уңыш һәм танылу, үз-үзеңә кул салу. Ләкин аның белән нәрсә генә булмасын, барысы да Гари өчен йолдыз саналган әнисе – актриса Мина Кацева яктылыгында уза. Язучының «Таң аткандагы вәгъдә» романы буенча Вахтангов исемендәге театрда куелган спектакль – ул белән ана мөнәсәбәтләре тарихы, үзәк өзгеч моңсу, мәхәббәт тулы тарих. Төп рольләрдә – Анна Дубровская һәм Григорий Антипенко.

29 ноябрь 19:00
«УНИКС» МСК
Казан,
Профессор
Нужин ур., 2/27

СЛАВИК ТОРМЫШЫННАН (18+)

Патриарший буаларының һавасын саткан Славик безнең бүгенге сатирик прозаның иң танылган персонажыдыр. «Беспринципные» сериалында Славик ролен актер Павел Деревянко уйный. Ә сценарием «БеспринцЫпные чтения» проекты авторы Александр Цыпкин (фотода) язган. Декабрь аенда Цыпкин һәм Деревянконың Казанга килүе көтелә, максатлары – тамашачыга «Чтения» дип аталган яңа программа тәкъдим итү. Оештыручылар вәгъдә иткәнчә, программага инде дөнья күргән популяр бестселлерлар да, әле басылмаган тарихлар да керәчәк. «Шунысын гына әйтәм: һичшиксез мажаралы драматик «Мадо» хикәясен, тамашачылар ярата торган Славик турындагы мәзәк хәлләрне һәм гадәттәгечә күптән түгел генә язылган кайбер хикәяләрне укыячакмын», – дип, Казанда үтәчәк «Чтения» программасының эчтәлеге белән таныштырды Александр Цыпкин.

12 декабрь 19:00
КРК «Пирамида» Мәдәни-күңел ачу комплексы, Казан, Мәскәү ур., 3

Фото: kamalteatr.ru, afisher.info, kazan-tuz.ru, meloman.ru, vakhtangov.ru

КАЗАНДА БАХ ТАВЫШЫ (6+)

«Үз тавышымны мин ирләр тавышы итеп тоям, ләкин, әлбәттә, бик югары, ачык һәм иркен итеп», – диде үзенең бер әңгәмәсендә «Москонцерт» солисты, Россия Дәүләт академия Зур театрының чакырылган солисты, контратенор тавышка ия Рөстәм Яваев. Солистның тавышы бүген бик сирәк очрый. Андый тавыш XVI–XVII гасырларда модада була. Ул чакларда Европа музыкасы югары регистрларда – контратенор һәм җырчы-кастратлар башкаруы өчен языла. La Primavera оркестрының С.Сәйдәшев исем. Зур концертлар залында оештырыла торган традицион Раштуа концертында Яваев Бахның берничә әсәрен башкарачак. Концертта Татарстан Республикасының атказанган артисткасы Гөлнара Мурзиева (сопрано, Казан), солисткалар Анастасия Селиванова, Алия Шакирова да катнашачак. Дирижёрлар – яшь композитор, М.Җәлил исем. Республика премиясе лауреаты Ильяс Камал һәм La Primavera Казан камера оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижёры Рөстәм Абязов.

21 декабрь, 18:30

ТРның С. Сәйдәшев исем. ДЗКЗ, Казан, Ирек мәйданы, 3

ТОРМЫШКА ТИҢ ӘКИЯТ (14+)

Евгений Шварцның көндәлегенә караганда, булачак күренекле язучы һәм драматург бала вакытыннан ук һәр вакыйганың начар тәмамлануыннан бик курыккан. Нинди генә шомлы вакытта һәм урында туган-яшәгән булмасын, ул үзенең һәр героена усал язмыштан, һәлакәттән котылу чарасы бирергә тырыша. Казанда туып үскән язучының юбилее хөрмәтенә Казан ТЮЗы коллективы, Петербург режиссёры Дмитрий Егоров белән бергә, Маргарита Кадацкаяның «Шварц, человек, тень» пьесасы буенча спектакль әзерләгән. Театр тәнкыйтьчесе Екатерина Кострикова сүзләренә караганда, пьесаның төп идеясе «шундый җиңеллек һәм җылылык белән тормышка ашырылган ки, үзең дә сизмәстән уйга каласың: язучының биографиясен, көндәлекләрен һәм әсәрләрен берләштерү ничек моңа кадәр беркемнең дә башына килмәгән икән, ә бит аның тормышы чын әкиятнең үзе».

16 декабрь, 19:00

Казан дәүләт Яшь тамашачы театры, Казан, Островский ур., 10

«ӘГӘР МИН БЕРӘР НӘРСӘНЕ ОНЫТАМ ИКӘН, ЙОЛДЫЗЛАР КАБУЛ ИТМӘСТЕР...» (12+)

Иртәме-соңмы кешелек дөньясына Җир планетасыннан читтә яңа йорт салырга туры киләчәк. Без анда үзебез белән нәрсә алырбыз соң? Әлеге яңа урын ниндирәк булыр, җирдәге калалардан, иҗтимагый һәм шәхси мохиттән нәрсәләр калыр? Мәскәү ГрОМ иҗат коллективында катнашучылар – фоторәссам Ольга Мичи, фотография тарихчысы Алексей Логинов һәм сәнгать белгече Артем Логинов әнә шул турыда уйлана. Аларның уйфикерләре 20 эштә чагылыш тапкан. Бу – һәрберсендә футуристик интерьер сурәтләнгән цифрлаштырылган картиналар күргәзмәсе. «Аларның функцияләре, мәдәни һәм стилитик үзгәлекләренә, шулай ук алардан читтәге киңлекләрдә аерма булуына карамастан, картиналарны һәрберсендә булган бер объект берләштерә», – диелә күргәзмәнең анонсында. Әлеге объектны табыгыз һәм, рәссамнар фикеренчә, кешелекне чиксез билгесезлектән нәрсә саклавын белерсез.

2023 елның 26 февраленә кадәр

ТР ДССМ ның Заманча сәнгать галереясы, Казан, К.Маркс ур., 57

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

shop.tatmedia.ru

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АҖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама

ТӨЗЕЛЕШ – ЯЗМЫШ ЭШЕ

Декабрь аенда Россия Федерациясе Хөкүмәтендәге төп фигураларның берсе - илнең төзелеш һәм ТКХ министры Ирек Фәйзуллин юбилеен билгеләп үтә. Корыч холыклы һәм югары дәрәҗәдәге профессиональлеккә ия шәхес буларак, ул үзенең тормыш юлын бер тапкыр һәм мәңгегә сайлаган, бүген дә шул юлына тугры кала.

Фоат Вәлиев,
«Алексеевск-дорстрой» ААҖ директорлар советы рәисе, ТР Дәүләт Советы депутаты

Ирек Әнвәр улы белән 25 ел элек, ул «Татавтодор» проектлау, ремонтлау һәм төзелеш берләшмәсе башлыгының беренче урынбасары булып эшләргә килгәч таныштык. Ул елларны без барыбыз да акчасызлык, бартерлы килешүләр һәм нинди генә чималны алма, аны табуда, алып кайтуда кыенлыклар чоры буларак хәтерлибез. Вазгыятьне җайга салу өчен зур тырышлык таләп ителде. Юл төзүчеләргә вак таш, битум, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары һәм башка бик күп нәрсәләр вакытында һәм кирәкле күләмдә килеп торсын өчен, тәэминатчы һәм сатып алучы оешмалар белән элемтәләр корырга кирәк иде, чөнки 90 нчы елларда андый материалларны табу үзе бер батырлыкка тиң саналды. Ирек Әнвәр улы «Татавтодор» системасына килгәч, бүлекчәләрне юллар төзү өчен кирәкле материаллар белән тәэмин итү җайга салынды, бу исә республикабызның юл тармагындагы потенциалын саклап калырга мөмкинлек бирде.

Аннан соңгы елларда, Ирек Әнвәр улы «Татинвестгражданпроект» ДУП һәм Татарстанның Төзелеш министрлыгында эшләгәндә, безгә проектлаштыру мәсьәләләренә бәйле рәвештә берничә тапкыр хезмәттәшлек итәргә туры килде, чөнки «Алексеевскдорстрой» үз хезмәткәрләре өчен торак төзү белән актив шөгыльләнде. Ирек Әнвәр улы һәрчак хәлгә керә белде һәм булышлык күрсәтте, чөнки аның өчен социаль мәсьәләләр һәрвакыт өстенлекле булды. Без үзара яхшы мөнәсәбәтләребезне югары бәялибез һәм бергә эшләү мөмкинлеге өчен рәхмәт белдерәбез. Шул вакыттан алып бүгенге көнгә кадәр минем өчен бик кадерле җылы мөнәсәбәтләр саклана.

Ирек Әнвәр улы – Татарстан Республикасының төзелеш тармагында иң күренекле затларның берсе, башкалардан аерылып торган, зыялы, бик гыйлемле шәхес. Үзен тулысынча эшкә багышлап, куелган максатларына һәрвакыт ирешә торган кеше ул. Ирек Әнвәр улын күп еллар белгән кеше буларак, шуны да искә алып үтәсем килә: республикабызда, илебездә төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүенә карамастан, ул гаҗәеп тыйнак шәхес.

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович! Без, хезмәттәшләрегез, фикердәшләрегез, бу гомер бәйрәмен Сезгә карата ихлас хөрмәтебезне белдерү өчен тагын бер яхшы форсат дип кабул итәбез! Сезне күркәм юбилеегыз белән котлап, әлбәттә, сәламәтлек һәм хезмәтегезнең һәрвакыт канәгатьлек китерүен телибез. Уңышлы һәм бәхетле кешеләрне күрүдән дә күңеллерәк нәрсә юк. Бәйрәмнәрдә дә, эш көннәрендә дә әнә шундый булуыгызны телибез!

Фото: «Татарстан» журналы архивыннан, tatar-inform.ru. РЕКЛАМА

МОГҖИЗАЛЫ КЫШ БИЗӘКЛӘРЕ

Быел кыш иртә килде. Ябалак-ябалак яуган беренче кар җирне каплады да эремәде. Әйтерсең табигать-ана, җиргә тизрәк ак юрган ябып, аның тыныч йоклавын теләде. Агачларга да ап-ак кар бөртекләре кунды. Яхшыга юрыйк без бу хәлне. Ак төс тынычлык, чисталык, сафлык, камиллекне аңлата. Киләсе ел нәкъ менә шуларны алып килсен иде. Ыгы-зыгылы дөньяда иминлек урнашсын, җаннарыбызга тынычлык иңсен.

Сезнең хозурыгызга фотохәбәрчеләребез тотып алган кышкы табигать күренешләрен тәкъдим итәбез.

Фотолар: Александр Ефремов, Алсу Шакирова, tatar-inform.ru




Премиальные обеденные группы
с итальянской керамикой
CARIN
CASA
Мебель из массива и металла
с использованием керамики
по итальянским технологиям
Собственное производство в Казани.
Доставка по всей России
Казань, ул. Дзержинского, 6Б
Тел. 8 804 700 70 71
https://mia-casa.ru
info@mia-casa.ru
Реклама